ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№09 (392)
СЕНТЯБРЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

▼ 46 бит

ГАДИ ОСТАХАНӘДӘН – ИҢ ЗАТЛЫ ҖИҺАЗЛАРГА КАДӘР

4 612750 670011

№09 (392)
СЕНТЯБРЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Әдәби мөхәррир: Луиза Шарова
Авторлар: Оксана Бирюкова, Сафа Гәраев, Әхмәт Шакиров
Фотограф: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Карина Пикулева, CARIN CASA брендына нигез салучы. Ната Смирнова фотосы.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-1917
Басарга кул куелды: 18.09.2024
Чыгу көне: 24.09.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ҖӘЙНЕ ТӘМАМЛАП...

«Татарстан»ның бу саны күңелле һәм бәйрәмчә килеп чыкты. Чөнки әлеге саныбыз җәй азагында әзерләнеп, безгә Республика көне белән Шәһәр көнен генә түгел, Татарстан фольклор ансамбльләре конкурсын да бүләк итте. Редакциябез ике ай дәвамында республика кала-салалары буйлап йөреп, иң яхшы җырчыларны барлады һәм protatarstan.ru сайтында тавыш бирү йомгаклары буенча яхшылардан яхшыларын ачыклады. Нәтиҗәдә Сарман, Чистай, Кама Тамагы, Кайбыч, Чирмешән районнарыннан фольклор ансамбльләре Казанга чакырылды. Җиңүче дип табылган ансамбльләр катнашында «Татмедиа» каршындагы скверда бик күңелле тамаша оештырылды. Бу журналда сез ансамбльләрнең QR-код буенча чыгышын күреп кенә калмыйча, тыңлый да алачаксыз.

Рәхәтләнеп укыгыз һәм тыңлагыз! Безнең белән җәегез дәвам итсен!

Сезнең җәйге редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 103 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары ТИК ТАТАРСТАНДА

BRICS ДИГӘН ГАЛӘМ

Мәскәүдән – Казанга. Санкт-Петербург, Рио-де-Жанейро, Каргополь, Пекин, Түбән Новгород, Ульяновск, Һиндстан Мумбае һәм Кейптаун (КАР). «BRICS галәме» фотокүргәзмәсенең уникаль маршруты әнә шундый. Анда BRICS илләренең иҗади шәһәрләре* сурәтләрдә тәкъдим ителгән: бөтен җете төсләре, бездә уята торган тойгы-кичерешләре, серләре, вакыйгалары, мирасы белән.

Экспозициянең аерым үзенчәлеге – космонавтлар Сергей Кудь-Сверчков белән Иван Вагнер орбитадан төшергән фотографияләр. «Әлеге күргәзмә ярдәмендә без кешеләргә БРИКС илләренең төрлелеге һәм матурлыгы турында сөйләргә телибез, – ди Сергей Кудь-Сверчков. – Шул исәптән безнең бик гади бурычыбыз да бар – дөньяга Россияне күрсәтәсебез килә, ә Россия халкына – башка илләрне. Бер-беребезне ныграк һәм яхшырак аңлар өчен».

Проектта БРИКС илләреннән 48 Россия һәм 41 чит ил фотографы катнаша. 1 февральдә Мәскәүдә ачылып, сентябрьдә күргәзмә инде Ульяновскига барып җитте. Чиратта – Мумбай һәм Кейптаун. Ә БРИКС саммиты көннәрендә аны кабат Казанда көтәбез.

© «Татарстан» журналы

* ЮНЕСКО программасының «Иҗади шәһәрләр челтәре»нә дүрт Россия шәһәре керә – Казан, Каргополь, Санкт-Петербург, Ульяновск.

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Республикам, синең бәйрәм!
30 августны Татарстанда ничек билгеләп үттеләр

15. Формасы белән дә, асылы белән дә хәләл
Гадел юл белән ничек акча эшләргә

22. Хезмәттәшлек кыры
БРИКС саннарда һәм фактларда

24. Үзенчәлекне саклап, яңалык кертү
БРИКС илләре вәкилләре Татарстан һәм үзләре турында

42. Виртуаль чынбарлык архитектурасы
БРИКС шәһәрләрен ничек төзибез

игелекле эшләр

52. «Цифр»лы мәдәният дөньясы
Ул нинди яңалыклар китерә

56. Лоренцо Куинн могҗизасы
Атаклы скульпторны Казан кай ягы белән әсир итә

58. «Идел сукмагы»ннан җәяүләп
Җирле матурлыклар ни белән гаҗәпләндерә

62. Авылча ял
Иң яхшы ял кайда

мәңгелек кыйммәтләр

66. Кешелекне саклап калу ысулы
Гаилә көче нәрсәдә

68. Еракка яшерелгән травмалар
Курку һәм үзеңне гаепле сизү тойгысыннан ничек арынырга

70. Китап киштәсе
Милли әдәби премия исемлегенә нинди китаплар кергән

76. Татарстан авыллары
Шәмәк авылы нинди уй-ниятләр белән яши

84. Афиша
Якын араларда нинди тамашалар карарга була

86. Ай кәефе
Иң яхшы фольклор ансамбльләрен кайдан табарга

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: admgor.nnov.ru

Акыллы гамәлләр

15.08

Илсур Һадиуллин, ТР мәгариф министры, – Татарстан мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август киңәшмәсендә:

– Узган елда безнең профессиональ белем бирү учреждениеләрен 22 меңнән артык кеше тәмамлап чыкты. Алган һөнәри белеме буенча шуларның 68% ы эшкә урнаштырылды. Тулаем алганда, республикада урта һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны хезмәт белән тәэмин итү гомумроссия күрсәткеченнән 10% ка артыграк. Дөрес, һөнәре буенча эшкә урнаштыру ягыннан 50, хәтта 40% тан да кимрәк күрсәткечле белем бирү оешмалары барлыгы да ачыкланды.

Игелекле эшләр

26.08

Оксана Лут, РФ авыл хуҗалыгы министры, – Казанда узган «Русское поле-2024» Бөтенроссия форумында:

– Татарстан – Идел буе федераль округының гына түгел, бөтен Россиянең дә авыл хуҗалыгы Мәккәсе ул. Бездә соңгы еллар эчендә барлык юнәлешләр буенча да җитештерү күләмнәре үсә бара.

Мәңгелек кыйммәтләр

11.08

Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Казан җырчысы, Үзбәкстанда узган Ovoz («Голос») музыкаль шоу катнашучысы, ярымфиналга чыгучы:

– Үзбәкстанда күпләр безнең җырларның ничек яңгыраганын белми булып чыкты. Алар татарларның кем икәнен белә, әмма ул белү нигездә чәкчәк, «Бас, кызым Әпипә!» белән түгәрәкләнеп куя. Хәзер алар татарның «Гөлҗамал»ы да булуын белә. Мин алга атлыйм, татар мәдәниятен халыкара аренада танытам. Аны торган саен күбрәк кеше белә бара. Үзбәкстанда үз җанатарларым барлыкка килде. Мәдәниятем дә үзем белән бергә алга атлый.

Фото: duma.gov.ru, tatar-inform.ru, tatar-congress.org

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда ислам банкингының перспективалары **нинди**

БРИКС илләре вәкилләре Россия турында **нәрсә** ди

Татарстан БРИКС илләре шәһәрләрен **ничек** төзи

Премиум-класслы йорт җиһазлары **нәрсәдән** башлана

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ:

«Ике кремль» мотофестивале, «Милли кием» халык костюмнары фестивале, ачык һавада «Казан күзе» опера фестивале, халык бәйрәмнәре, «Казан» гаилә үзәге янындагы мәйданда «Братья Гримм» төркеме һәм Дима Билан чыгышы – 30 августта Казанда Республика көне һәм Шәһәр көне уңаеннан оештырылган киң колачлы бәйрәмнең кайбер мизгелләре генә. Бәйрәм кәефе фотохәбәрчеләребез Александр Ефремов, Ксения Богодвид, Виктория Тютюник һәм Нурислам Исмәгыйлев фотоларында да чагылыш тапкан.

«ИКЕ КРЕМЛЬ 2024» МОТОФЕСТИВАЛЕ

Алтынчы халыкара мотофестивальдә үзебезнең илдән, шулай ук чит илләрдән килгән 1000 гә якын мотоциклчы катнашты. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашкан шәһәр мотопарады әлеге чараның бер өлеше булды.

«ИКЕ КРЕМЛЬ», «ЕЛМАЙ», «ТЫН БАКЧА», «МИЛЛИ КИЕМ», «БРАТЬЯ ГРИММ», ДИМА БИЛАН...



Фото: rais.tatarstan.ru

«МИЛЛИ КИЕМ»

Түбән Кабан күле буенда традицион «Милли кием» фестивале үтте. Катнашучылар Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен ел саен әнә шундый матур милли киемнәрдә каршы ала.

Фото: Виктория Тютюник

КАЗАНЛЫЛАР ҺӘМ БАШКАЛА КУНАКЛАРЫ ШӘҺӘР УРАМНАРЫНДА РӘХӘТЛӘНЕП ЯЛ ИТТЕ.

Фото: Ксения Богодвид

ГАИЛӘ ҮЗӘГЕ БУЕНДАГЫ БӘЙРӘМ КОНЦЕРТЫ

Тамашаның хедлайнерлары – «Братья Грим» төркеме һәм Дима Билан.

Фото: Александр Ефремов

ГАИЛӘ ЕЛЫНЫҢ МАТУР БИЗӘГЕ

Шәһәр көнендә һәм Татарстан Республикасы көнендә «Казан» гаилә үзәге янында бер үк вакытта 45 пар никахлашты. Чара ТР Министрлар Кабинеты каршындагы ЗАГС Идарәсе тарафыннан оештырылды.

Фото: Нурислам Исмәгыйлев

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU



ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАВЫ: ИКЕ ЕЛЛЫКНЫ – БЕР ЕЛДА

Әхмәт Шакиров

Хәләл дебет карталары, ислам лизингы, торак сатып алгач, аның өчен хәләл өлешләп түләү һәм хәтта ислам факторингы... Илнең дүрт төбәгендә партнёрлык финанславын кертү буенча эксперимент башланганнан соң бер ел узды. Бүген бу продуктлар инде экзотика тоелмый. Эксперимент уңышка ирештеме соң?

Һәрхәлдә, бүген тәкъдим ителгән ислам финанс продуктлары санына карарганда, нәтиҗәләр сизелерлек. Әле берничә ел элек кенә бездә хәләл кыйммәтле кәгазьләр идентификаторы буларак мобиль кушымта пәйда булыр, ә автотранспорт, төзелеш материаллары сатып алганда хәләл өлешләп түләү дә, хәләл инвестфондлар да көндәлек инструментка әйләнер дип, уйлау да мөмкин түгел иде. Рөстәм хәзрәт Нургалиев (ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы составындагы гыйльми секретарь, базарга хәләл продуктлар чыгара торган компанияләрне сертификацияләүдә турыдан-туры катнаша – ред. иск.) билгеләп үткәнчә, беренче яртыеллыкта ук финанс продуктының ислам кануннарына туры килүен сертификацияләүне сорап язган гаризалар саны сизелерлек арткан. Бу, аның фикеренчә, ислам финанслары белән кызыксынуның артуын раслый торган күрсәткеч.

ФОРМАСЫ БЕЛӘН ДӘ, АСЫЛЫ БЕЛӘН ДӘ ХӘЛӘЛ

Әмма рәсми рәвештә эксперимент үткәрелә торган барлык дүрт республикада да катнашучыларның кинәт артып китүе турында сөйләргә иртәрәк. Үзәк банк реестрында, мәсәлән, бүген Чечен Республикасыннан – бер компания, Башкортстаннан – дүрт, Дагыстаннан бер компания бар. Алар фонында унике катнашучысы, шул исәптән бер банкы булган Татарстан берсүзсез лидер. Бу ни өчен шулай? Бәлки, бу лидерлык әле эксперимент башланганчы күпкә иртәрәк Татарстанда кайбер хәләл финанс

Фото: tatar-inform.ru

продуктларының базарга чыгарылуына бәйледер?

Хәер, сентябрь башында егерме ике компания булган Үзәк банк реестры экспериментның реаль масштаблары турында тулы күзаллау тудыра алмый. Шуны аңларга кирәк: реестрга кертү компания базарга чыннан да хәләл продуктлар тәкъдим итәчәк дигәнне аңлатмый. Һәм, киресенчә, компаниянең реестрда булмавы аның клиентларга реаль партнёрлык финанс инструментларын тәкъдим итә алуын кире какмый (әлбәттә, гамәлдәге закон кысаларында). Берәү дә реестрга керергә гариза тапшырырга мәҗбүриләми. Бу реестр, мөгаен, потенциаль клиент өчен мәгълүмат чыганагы, үзенә күрә ышаныч сертификатыдыр, гәрчә соңгысы турында шик туса да. Чөнки, мәсәлән, күптән түгел генә банкларның берсе, реестрга кертелгәннән соң, лицензиясеннән мәхрүм ителде...

АНКЕТА БӘЯЛӘҮ ЫСУЛЫМЫ?

Килешүләр саны, акча агымнарының күләме исәпкә алынган финанс статистикасы партнёрлык (ислам) финанславы инструментларына ихтыяҗның булу-булмавы, аларны файдалануның чын масштаблары турында тулырак күзалларга булышыр иде. Әмма монда, кызганычка, мәгълүмат әлегә бик аз. «Без 2023 ел нәтиҗәләре буенча сораштыру уздырдык. <...> Бу раундта безнең 17 оешма катнашты. Һәм, әлбәттә, катнашучылар даирәсе киңәйтеләчәк, – дип хәбәр итте Россия Банкы финанс базарының Стратегик үсеш департаменты директоры Екатерина Лозгачева 2024 елгы KazanForumда. – Бу сораштыру кысаларында бәяләнгән килешүләр портфеленә килгәндә, тулаем алганда, ул җәлеп ителгән акчалар буенча да, урнаштырылган акчалар буенча да 1,8 миллиард сумга якынны тәшкил итте».

17 оешма буенча үткәрелгән анкеталау нигезендә алынган мәгълүмат картинаның бөтен тулылыгын бирергә сәләтле түгелдер. Шулай да экспериментның гомуми нәтиҗәләре якын араларда игълан ителер дип ышанырга гына кала, ул, Екатерина Лозгачева фаразлавынча, 2024 елның көзенә пәйда булырга тиеш.

Татарстан буенча статистика төгәлрәк тә, яңарак та. 2024 елның беренче 6 аенда республикада 2,8 млрд сумлык 1 255 килешү теркәлгән, ә ислам финанслары буенча килешүләрнең гомуми саны 2 тапкырга арткан. Гаҗәп түгел: партнёрлык финанславы базарында тәкъдимнәрнең саны һәм төрлелеге буенча республикага тиңнәр юк. Моны август аенда Әлмәттә узган партнёрлык (ислам) финанслары күргәзмәсе дә расслады. Күргәзмәдә, аерым алганда, «АК БАРС» Банк» ГАҖ, «АК БАРС КАПИТАЛ» ИК ҖЧҖ, Татарстан Республикасы Гарантия фонды, Татарстан Республикасы Эшкуарлыкны яклау фонды, Төбәк лизинг компаниясе, Татарстан Республикасы Дәүләт заказы агентлыгы, «Амаль» ФЙ, Halal Card Хәләл карары, «Саклык банкы» ГАҖ үз продуктларын тәкъдим итте.

ГАДЕЛ АКЧА ЭШЛӘҮ ЫСУЛЫ

ТР һәм Россиядә ислам банкингы пионерлары шикләнми: эксперимент нәтиҗәләре һичшиксез уңышлы булачак. Чиста һәм намуслы финанслар, гомумән, «пычрак» табышка юл калдырмый – мөгаен, бу сәламәт җәмгыять омтылырга тиешле әйбердер. «Гадәти банкингта акчадан файдаланган өчен алдан билгеләп куелган процент алуны ислам дине риба дип аңлата, ислам хокукы аны 1400 ел элек үк законсыз акча эшләү ысулына керткән иде, – дип искә төшерә Рөстәм хәзрәт Нургалиев. – Ислам исә банкларга табышны һәм финанс куркынычын бү-

– Без 2023 ел нәтиҗәләре буенча сораштыру уздырдык. Бу раундта безнең 17 оешма катнашты. Һәм, әлбәттә, катнашучылар даирәсе киңәйтеләчәк, – дип хәбәр итте Россия Банкы финанс базарының Стратегик үсеш департаменты директоры Екатерина Лозгачева 2024 елгы KazanForumда.

лүнең гадел контракты аша акча эшләү мөмкинлеген тәкъдим итә. Банкирлар бу очракта акча өчен акча гына биреп калмый, теге яисә бу проектта партнёр буларак катнаша».

Әмма җәмгыять финанс һәм проектларның намуслы һәм чиста булуын беренче урынга куярлык дәрәҗәгә җиттеме, процент аша акча эшләүгә, теләсә кайсы юл белән табышка ирешергә, файдалырак ипотека алуга караганда әлеге гаделлекне өстен куя аламы – монысы икенче мәсьәлә. Тарихта банклар перспективалы проектны зур процентларга кредитлап, ә аннары бу проектны аны гамәлгә ашыручылардан тартып алуга мисаллар җитәрлек, чөнки кредит алучылар кинәт күтәрелгән валюта курсы аркасында түли алмый башлыйлар. Һәм, әйтик, берәр зур проектны тормышка ашырганда банкның кредитор түгел, бәлки, партнёр буларак катнашып, ислам банкингындагы кебек куркынычны да уртаклашуга берәр мисал китерә аласызмы? Юктыр...

Аңлашыла ки, ислам финанс продуктларына ихтыяҗ аларның базарда ни дәрәҗәдә көндәшлеккә сәләтле булуына да, тәкъдимнәрнең төрлелегенә дә, кешеләрнең ислам банкингын ни дәрәҗәдә белүенә дә бәйле. Тәкъдимнәрнең артуы, ислам финанс продуктларының өстенлекләрен халыкка аңлата алырлык белгечләр саны кебек үк, аермачык күренеп тора, әмма аларның конкурентлык куәтенә хилафлык китерә торган проблемалар да күз алдында. Экспертлар, мәсәлән, мондый фактка игътибар итә: партнёрлык финанславы кысаларында фатир сатып алганда дәүләт пошлинасы башка очракларга караганда берничә тапкырга зуррак. Кайбер традицион һәм партнёрлык продуктларын чагыштырсак, салым диспаритеты да күзәтелә. Нәтиҗәдә соңгылары кыйбатрак булып чыга.

АНГЛИЯДӘ ЭШЛИ, Ә РОССИЯДӘ ЭШЛИ АЛМЫЙМЫ?

Дини инанулары традицион банкингтан файдаланырга мөмкинлек бирми торган кешеләр өчен бу киртәләр партнёрлык (ислам) финанс инструментларына юлны яба алмый, әлбәттә. Ләкин монда башка каршылык бар. Сүз бездә бердәм бәяләү стандартының булмавы турында бара. Бу вакытта бер үк продукт кемдәдер рөхсәт ителгән, кемдәдер рөхсәт ителмәгән булырга мөмкин. Компаниянең ислам финанславы буенча экспериментта катнашучылар реестрына кертелгән булуы Голәмәләр шурасы сертификатына ия булуны аңлатмый.

Мондый каршылыкның сәбәбе аңлашыла. Катнашучылар реестрын Үзәк банк формалаштыра, ә сертификатларны ислам дини институтлары бирә. Белгечләр раславынча,

бердәм бәяләү стандарты эшләнә. Ләкин эшнең нәтиҗәсе кайчан булыр, һәм ул үзебезнең түрәләрне һәм потенциаль кулланучыларны гына түгел, бәлки, без җитди хезмәттәшлеккә исәп тоткан ислам дөньясы финанс институтларын ни дәрәҗәдә канәгатьләндерер?

Бу хакта, сүз уңаеннан, 2024 елгы KazanForumда безнең потенциаль партнёрларыбыз да сөйләде. «Иң мөһиме – аңлаешлы, үтә күренмәле стандарт булдыру. Бу башка илләр базарында үсәргә мөмкинлек бирәчәк шарт санала. Экспериментны эшләтеп җибәрүгә, без Россиядәге хезмәттәшләребезгә бердәм стандартның киләчәктә бөтен тормышыгызны җиңеләйтергә, партнёрларыгыз белән элемтәне гадиләштерергә мөмкинлек бирергә тиешле шарт булуы турында әйттек», – дип сөйләде Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Үзәк банкы каршындагы Югары шәригать идарәсе җитәкчесе Саад Баккали.

Ниндидер аңлашылмаган сәбәпләр аркасында ислам финанславының исеме үк куркыта, дөньяви дәүләттә аларны үстерү идеясенә шикләнеп караучыларга килгәндә, аларга 2024 елгы KazanForumда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйткән сүзләргә колак салырга киңәш итәбез: «Чынлыкта без моңа күптән һәм системалы рәвештә бардык. <...> Һәм иң мөһиме, эксперимент башлануга ук уңай нәтиҗәләр бирде. 1290 килешү. Яңа продуктлар. <...> Бу беркемгә дә куркыныч тудырмаган өстәмә инструментлар. Әгәр бу Англиядә эшли икән, ни өчен Россиядә эшли алмаска тиеш? <...> Ислам хезмәттәшлеге оешмасында 57 ил санала. Бу дәүләтләрнең Россиягә мөнәсәбәте Көнбатышныкы кебек түгел. Һәм аларның Россиядә яшәүче 15 миллионнан артык мөселманның шундый ук шартларга ия булуын күрүе безнең илгә файда гына китерәчәк».

БЕХНАМА ГУРБАН-ЗАДЕ:
ТӨП МАКСАТ – КЛИЕНТКА ИСЛАМ ФИНАНСЛАВЫН АҢЛАЕШЛЫ ИТЕП ҖИТКЕРҮ

«Татарстан» биргән сорауларга Саклык банкы Партнёрлык финанславы һәм махсус проектлар үзәгенең Идарәче директоры-башлыгы җавап бирә.

– Саклык банкы үзенең партнёрлык финанславы буенча беренче офисын Татарстанда ачты. Офисның концепциясе турында сөйләгезче: ул банкның башка бүлекләреннән аерыламы?

– Безнең офис килгән теләсә кайсы кеше дә Көнчыгыш аурасын тоя алырдай, ислам финанславы бирә алган мөмкинлекләрне сынап карардай итеп, махсус концепциягә нигезләнеп корылган. Игътибар итегез: балалар өчен аерым урыннар, намаз уку бүлмәсе, тарих турында сөйли торган почмак бар. Без бу офисны клиентка түгел, ә кешегә йөз тотып әзерләдек. Чөнки безнең концепция нигезендә дә эшне кешегә йөз тотып алып бару ята.

Алай гына да түгел, бу офис барлык клиентлар өчен эшләнгән: анда мөселманнарга гына түгел, ә һәркемгә хезмәт күрсәтелә Мондый концепция кешеләр офиста үзләрен уңайлы хис итсен, тәкъдим ителгән хезмәт белән продуктларны ышанып, шикләнмичә куллана алсын өчен уйлап табылды һәм тормышка ашырылды.

– Партнёрлык финанславында продуктларның шәригать нормаларына туры килүенә зур игътибар бирелә. Бу юнәлештә эшегез ничек оештырылган, ТР Диния нәзарәте белән сез ничек хезмәттәшлек итәсез?

– Бер ел элек Саклык банкы Россия Федерациясе Диния нәзарәте белән берлектә хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куйды, шулай ук Ислам финанс оешмаларының бухгалтерлык хисабы белән аудиты оешмасы составына (AAOIFI) керде. Татарстан Республикасы Диния нәзарәте белән шулай ук хезмәттәшлек турындагы килешү бар, аның кысаларында без инде продуктларга беренчел анализ уздырдык. Алар асылда Россия Федерациясе Диния нәзарәте карашына каршы килми.

Фотолар «Саклык банкы» ГАЖ тарафыннан биреле. Реклама

Хәзерге көндә продуктларны һәм сервисларны популярлаштыру юнәлешендә уртак эшебезгә керешәбез, сату буенча яңа операцион модельләр, технологияләр һәм стратегияләр уйлап табу буенча эш башлыйбыз. Әйе, дискуссия барышында кайбер фикер каршылыклары да килеп туарга мөмкин, әмма бу, иң беренче чиратта, профессионаллар аралашуы. Шуның нәтиҗәсендә без илебездә ислам финанславы моделен тагын да яхшыртуга ирешәчәкбез.

– Кайсы продуктларга ихтыяҗ аеруча зур?

– Бер дә арттырусыз, ваклап сату белән корпоратив сегмент өчен әзерләнгән продуктларга актив ихтыяҗ бар, дия алабыз. Хәзерге вакытта безнең «Адафа» дебет карталары тәкъдим ителә, «Амана» счётлар теркәү системасы, «Мурабаха» ипотекасы, шулай ук кулланылышта «Хәләл инвестицияләр» БПИФ кебек продуктлар бар, аларны без Мәскәү биржасы белән гамәлгә куйдык. Корпоратив клиентлар өчен, мәсәлән, ислам исәп-хисап-касса хезмәте, эш хакы проектлары, «Мурабаха» факторинг финанславы, «Иджара» лизинг рәсмиләштерүе каралган. Клиентларда «Кард әл-Хәсән» әйләнештә кредитлау кысаларындагы финанслау зур кызыксындыру уята. Без төзелеш базары тарафыннан зур кызыксыну барлыгын тоябыз: алардан килгән сорауларны эшкәртеп, күпмедер күләмдә проектлы финанслауга гаризалар алабыз.

– Татарстанда партнёрлык финанславын үстерү буенча планнарыгыз нинди?

– Без базарны клиентларның ихтыяҗына җайларга омтылабыз. Элегрәк ислам финанславының мөмкин булган барлык сервис белән хезмәтләрен әйләнешкә кертеп җибәрә алырлык тулы канлы моделе юк иде. Хәзер, федераль закон булгач, базарда кызыксыну тудырган аерым продуктларны тест режимында сынап карый алабыз. Ваклап сатучылар белән корпоратив клиентларны җентекләп өйрәнгәннән соң, Татарстанда зур потенциал барлыгын күрәбез. Төзелешне, ипотека бирүне, ваклап сату продуктларын финанслау юнәлешләрен үстерүдә реаль кызыксыну бар.

Без Татарстан Республикасын пилот төбәк буларак карыйбыз, монда үзебезнең продуктларны тәүге мәртәбә тест режимында сыныйбыз, коллегалар белән бергә тикшерәбез һәм базарга чыгарабыз. Шуның белән бергә һәрдаим республика җитәкчелеге – ТР Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, икътисад министры Рифкать Мидхәт улы Шаһиәхмәтовның ярдәмен тоеп эш итәбез. Татарстан Республикасы Диния нәзарәте белән мөнәсәбәтләребез җылы, дустанә – алар һәрчак безнең продуктлар турында фикер алышырга әзер, безнең белән бергә продуктларны камилләштерүдә катнаша. Дәүләт органнары, мөселманнарның диния назарәтләре белән тыгыз элемтәдә эшләү нәтиҗәсендә моңарчы әле дөнья күләмендә бер җирдә һәм беркайчан да булмаган ислам финанслау моделен булдыруга ирешә алдык.

Ул роман-герман системасы кысаларында гамәлгә куелган Россия хокук кануннары буенча тормышка ашырыла. Анда без ислам финанславы продуктларын һәм сервисларын интеграцияләп кенә калмыйбыз, бәлки, төп мәсьәлә – исәпкә алу буенча нәтиҗәле карар кабул итүгә ирешәбез. Әйтик, аны ничек җайга салырга, алып барырга, маркетинг кампанияләрендә ничек катнашырга, бу эшне ничек көйләргә, клиентларны ничек дөрес итеп җәлеп итәргә.

– Сезнең карашка, әлеге юнәлеш Россиядә уңышлы үссен өчен, эксперимент күзлегеннән караганда, ислам банкингы буенча нинди яңалыклар кертү сорала?

– Хәзер сатуның яңа технологияләрен эшлибез, продуктларны цифрлы каналларга чыгарабыз. Төрле механизмнар кулланып, продуктларны алга этәрү һәм популярлаштыруның яңа вариантларын һәм мөмкинлекләрен эшлибез.

Мисал өчен, безнең «Мурабаха» ипотекасын «Домклик» сайты аша алып була. Ислам финанславы буенча цифрлы аңлату-өйрәтү материаллары булдырылды, шуның ярдәмендә кешеләр бушлай укый һәм өйрәнә, үз фикерен булдыра ала. Стандартларга туры килә торган продуктлар аша чит ил инвестицияләрен җәлеп итүнең яңа юлларын эзлибез: алда ике зур проект тора, шуларны җиренә җиткереп башкарып чыгарга тырышабыз.

– Партнёрлык финанславы продуктларын республика халкына ничек җиткерәсез?

– Ел саен «Россия – партнёрлык гаранты» Россия ислам икътисади форумы уздырабыз, ул ислам икътисады һәм финанслары мәсьәләләре буенча фикер алышуга корылган. Быелгы форум 16 октябрьдә Мәскәүдә узачак. Коллегалар белән тәҗрибә уртаклашабыз, әлеге юнәлеш буенча көн кадагында торган мәсьәләләргә тукталабыз, халыкара тармак тенденцияләренә анализ ясыйбыз, аларны үз эшебезгә кертү ысулларын карыйбыз. Моннан тыш, Саклык банкы ел саен «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисади форумы партнёры буларак билгеле. Аның кысаларында да тәҗрибә уртаклашабыз, форумда катнашучыларга үзебезнең ирешкән уңышларыбызны күрсәтәбез, фикер алышабыз.

Төп максат – клиентларга ислам финанславының бөтен кыйммәтен дөрес, аңлаешлы итеп җиткерү: сөйләү, күрсәтү, җирле халыкның финанс буенча грамоталылыгына таяну, традицион банк тәкъдим иткән модель белән чагыштырып, аерманы аңлату. Алга таба инде кешегә үзенә хәл итәргә генә кала: җанына ни якынрак, ул шуны сайларга хокуклы.

ТАТАРСТАН – ПАРТНЁРЛЫК (ИСЛАМ) ФИНАНСЛАВЫ ТАРМАГЫНДА ҮРНӘК ТӨБӘК

Соңгы елда Татарстанда партнёрлык (ислам) финанславы яңа баскычка күтәрелде, алай гына да түгел, республика Россиядә ислам банкингы үсешенә лаеклы мисал булып тора. Моңа бигрәк тә партнёрлык финанславы буенча 2023 елның сентябрендә башланган эксперимент уңай йогынты ясады. Әлеге сынауда Көнчыгыш илләре белән якынаю һәм Фарсы култыгы, Азия белән икътисади һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен көйләү юнәлешенә аеруча игътибар бирелә. Ә эчке базарда эшләр ничек соң? Татарстанда хәләл индустрия ничек үзгәрә? Экспериментка нәтиҗәләр ясыйбыз.

БАСЫМСЫЗ КОНТРОЛЬ

Эксперимент кысаларында бер ел эчендә ислам продуктларын Россиядәге хокук һәм икътисад мохитенә яраклаштыру буенча актив карарлар кабул ителде. Шәригать кануннары белән дә, гамәлдәге закон һәм нормативлар белән дә яраша алган, ил өчен өр-яңа булган финанслау моделен эшләү һәм кертү – катлаулы бурыч. Башта Россия Банкы ел дәвамында ислам финанс компанияләрен актив рәвештә тикшерде һәм РФ ҮБ реестрына кертте. Әлеге рәсми реестр шиге булган гражданнарга Үзәк банкның әлеге компанияләргә ышанычын исбатлау өчен кирәк. Хәзер аккредитация алучылар исемлегендә 22 компания бар, шулардан 12се – Татарстаннан. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: эксперимент барышында ҮБ тәкъдим иткән исемлектән 4 компания чыгарылды.

КАДРЛАР ҺӘМ ЛИКБЕЗ: ЧЫЛБЫРДАГЫ ИҢ МӨҺИМ БУЫННАР

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» Татарстанның Россиядәге ислам финанслары үзәге статусын тагын бер кат дәлилләде. Форумның стратегик сессияләре ислам икътисады һәм финанслары үсеше проблемаларына багышланды. Аларның берсен ТР Рәисе үзе әйтте: ислам финансларын яхшы белгән белгечләргә зур кытлык. Әлеге проблема хәл ителә инде: Россия ислам институты һәм КФУ базасында кадрлар әзерләнә башлады.

Халыкның альтернатив инвестицияләр, өлешләп хәләл түләү мөмкинлекләрен начар белүе дә экспертлар игътибарыннан читтә калмады. Әмма хәзер бу проблема да хәл ителгән – ислам финанслары бердәм республика порталы булдырылган, анда барлык кирәкле аңлатма материаллар да тупланган, ислам нормалары буенча эшли торган оешма һәм продуктларның исемлеге эленгән. Порталның «Уңыш тарихлары» бүлегендә «Амаль» Финанслар Йорты тәҗрибәсенә махсус урын бирелгән, һәм бу, әлбәттә инде, һич тә очраклы түгел.

ЭКСПЕРИМЕНТ. ПРОБЛЕМАЛАР ҺӘМ НӘТИҖӘЛӘР

«Амаль» Финанслар Йорты, генераль директоры Рөстәм Сәгъдиев әйтүенчә, 2010 елдан бирле эшли. Компания ислам финанславы буенча эксперимент башлаганчы күпкә иртәрәк, тармакта беренчеләрдән булып бу эшкә керешкән. Шунлыктан «Амаль» Финанслар Йортының топ-менеджеры KazanForum сессиясенә спикер сыйфатында чакырылган бердәнбер коммерция компаниясе булуы бер дә очраклы түгел.

– Эксперимент башланганнан бирле берничә уңай нәтиҗәгә ирештек, – дип йомгак ясый Рөстәм Сәгъдиев. – Халыкның һәм оешмаларның, гаммәви мәгълүмат чараларының ислам финанслары белән кызыксынуы артты. Телевидение, шул исәптән чит илләрнеке дә, кәгазь һәм интернет басмалар тәҗрибә уртаклашуыбызны сорап безгә даими мөрәҗәгать итә, безнең икътисади кризисларны дәүләт ярдәменнән башка ничек уңышлы үтүебез һәм һаман лидерлар арасында калуыбыз белән кызыксына. Экспериментның мөһим нәтиҗәсе – компаниянең инвестицияләр һәм финанслау буенча портфеле зураю. Әмма барысы да ал да гөл түгел, без үзебезне борчыган проблемаларны Дәүләт Думасы депутатларына җиткергән идек. Аерым алганда, бу безнеке кебек оешмаларның ташламалы дәүләт программаларында, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләрен ташламалы финанслауда һ.б. катнашу өлешендә партнёрлык һәм традицион финанслар өчен шартларны тигезләү зарурлыгы. Ана капиталыннан банк булмаган структураларда, ягъни безнеке кебек компанияләрдә файдалану мөмкинлеге каралуга да өметләнәбез.

ПЕРСПЕКТИВАЛАР ҺӘМ ПЛАННАР

Проблемалар булуга карамастан, Татарстанда ислам финанслары үсеше перспективалары өметле. Киләчәктә ислам финанс продуктлары ассортиментын тагын да киңәйтү, шулай ук халыкара партнёрлар белән үзара хезмәттәшлекне көчәйтү планлаштырыла. Моннан тыш, Россиянең башка төбәкләренең дә Татарстан тәҗрибәсеннән файдалануы көтелә. Чувашия һәм Ингушетия компанияләренең кызыксынуы исә партнёрлык (ислам) финанславы буенча экспериментның бөтен илгә таралуына өметләнергә мөмкинлек бирә.

Фото «Амаль» КҖ. РЕКЛАМА. «Амаль» КҖ

* Юридик атамасы – «Амаль» КҖ.

СКАНДИНАВИЯ
дикъкатьле медицина клиникасы

«Скандинавия» клиникасында 1 көн эчендә сәламәтлекне тикшертә аласыз!

Сәламәтлекне кайгырту, иң беренче чиратта, дөрес диагноз куюдан башлана. «Скандинавия» клиникасы, сәламәтлегегез торышын сыйфатлы итеп тиз арада ачыклау өчен, модульле чекаплар узу мөмкинлеген бирә.

Нәрсә соң ул модульле чекап?

Диагноз куюга персональ якын килү дигәнне аңлата ул! Беренче этапта сез тиешле тикшеренүләр аша төп чекапны узасыз. Өстәмә тикшерүләр кирәк булган очракта, сезгә артык чыгымнар таләп итми торган, бары тик кирәкле модульләрне генә тәкъдим итәчәкләр.

Әгәр сез:	Төп чекап белән бергә тикшереп һәм белеп була:
• еш арыйсыз • гәүдә авырлыгы кинәт үзгәрүдән интегәсез • еш суык тиеп чирлисез һәм авыртулар тоясыз икән	• кан әйләнеше системасы эшчәнлеген • үпкә-бавыр һәм бөерләрнең хәлен • йөрәк-кан тамырлары системасының торышын • ашказаны системасы эшчәнлеген • организмда ялкынсыну бармы-юкмы икәнен • организмда патологик процессларның булу-булмавын

Өстенлекләре:

Индивидуаль якын килү: бары сезгә кирәкле булган анализлар һәм һәр пациент өчен махсус сәламәтлек картасы.
Барлык тикшерүләр – бер көндә!
Чиратның булмавы, көтеп зарыгырга туры килмәве дә – мөһим шарт.

Сәламәтлекнең үзе турында искә төшергәнен көтмәгез! «Скандинавия» клиникасына төп чекапка языгыз һәм бүген үк сәламәтлекне саклауга, актив тормышка таба әһәмиятле адым ясагыз. Тикшеренү өчен:

200-10-65 телефоны буенча;
t.me/scandinavia_chat каналында язылырга мөмкин.

Профсоюз урамы, 19/15 нче йорт

Реклама

ЧИКЛӘҮЛӘР БАР, БЕЛГЕЧ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ КИРӘК

Лицензия белән ava-kazan.ru сайтында танышырга мөмкин

BRICS – тугыз дәүләтне берләштерә торган оешма:

Бразилия

Россия

Һиндстан

Кытай

КАР

БГӘ

Согуд Гарәбстаны

Иран

Мисыр

Эфиопия

Бразилия, **Р**оссия, һиндстан (русчадан – **И**ндия), **К**ытай икътисад министрлары катнашында 2006 елның июнендә узган Петербург икътисади форумы кысаларында **БРИК** (латинчадан **BRIC**) буларак оеша.

2010 елга оешмага Көньяк Африка Республикасы кушыла, һәм оешма бүгенге атамасын ала – **БРИКС** (латинчадан **BRICS** – **B**razil, **R**ussia, **I**ndia, **C**hina, **S**outh Africa атамаларыннан кыскартылган).

4 БРИКС иле –

Россия, Кытай, Һиндстан һәм Бразилия

халык саны, мәйданы һәм эчке тулай продукты буенча дөньяның иң зур ун дәүләте исәбенә керә.

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

БРИКС илләренең гомуми мәйданы

**45 726 508 м², **

ягъни коры җир өслегенең

26,7%ы

БРИКС илләрендәге халык саны

3,53 млрд кеше,

ягъни җир шарындагы халыкның

43,5%ы

Дөнья эчке тулай продуктының

27%ы

Дөньядагы сөрүлек җирләренең

32%ы

BRICS оешмасына керергә гариза биргән илләр арасында:

Азәрбайҗан

Малайзия

Таиланд

«Татарстан» журналының махсус проекты

ТАТАРСТАННЫ

Казан БРИКС саммитында катнашучыларны каршы алырга әзерләнә – Татарстан башкаласына 22–24 октябрьдә 20 мең абруйлы кунак киләчәк. БРИКС илләреннән генә түгел, берләшмәгә керергә җыенучыларның да килүе көтелә. Моннан тыш, бик күп журналист, эксперт, волонтёр, хокук саклаучы да киләчәк. Казан, Универсиаданы көткән чактагыдай, көннән-көн үзгәрә, матурлана бара.

Башкалабыз кунак каршыларга әзерләнгән арада «Татарстан» хәбәрчеләре Казаныбызда яшәүче, үз якташлары белән очрашуга әзерләнүче БРИКС илләре вәкилләре белән очрашты. Алар барысы да «Татарстан» журналы сорауларына бик теләп җавап бирде.

1 **– Мин Татарстанга ник килдем?**

2 **– Татарстаннан үз илемә нәрсә алып китәр идем?**

3 **– Үз илемнән Россиягә нәрсә алып килер идем?**

4 **– Татарстанга ничек ияләштем, нинди уңышларга ирештем?**



BRICS вәкилләре ничек күрә

ПРОЕКТ АВТОРЛАРЫ:
Николай Крушинин,
Евгения Чеснокова,
Дмитрий Сивков,
Руфия Фазылова.



Фото Юй Чунь архивыннан

ЮЙ ЧУНЬ, КЫТАЙ:

– МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН САКЛАП КАЛЫП, ЗАМАНЧА ЯҢАЛЫК КЕРТӘ БЕЛҮ – ТАТАРСТАННЫҢ ТИҢДӘШСЕЗ СӘЛӘТЕ

1

– Татарстанда этием эшләде, башта мин аның янына килә идем. 2015 елда эш сәфәре белән Казанга килгәч, булачак хатыным белән таныштым һәм монда калдым. Хәзер ресторан бизнесы белән шөгыльләнәм, кытай ризыклары әзерли торган берничә ноктам бар.

2

– Минемчә, Татарстанның төбәк буларак тиңдәшсез сәләте шунда: ул, милли үзенчәлеген саклап калып, гореф-гадәтләрне бүгенге көн стандартларына туры китерерлек итеп заманчалаштыра, яңалыкларны кертә белә. Кытайда тормышны катлауландыра торган традицияләр һәм йолалар хәзергә кадәр бик күп. Мәсәлән, гаилә кору өчен кәләшнең ата-анасының бик күп таләбен үтәргә кирәк, кайвакыт үз парыңны табу бик кыен.

3

– Безнең илләр кайсы тармакларда бер-берсен үзара баета алыр иде икән? Минемчә, теләсә нинди бизнес җәмгыятьнең гөрләп үсүенә ачкыч булып тора. Бу нәкъ менә ике якны да хезмәттәшлек кысаларында куәтләндерә торган даирә. Мәдәни аспект та мөһим: мәдәни элемтәләр күбрәк булган саен, җәмгыятьнең аң-белем дәрәҗәсе югарырак була бара.

4

– Башка илгә күченгән теләсә кайсы кеше кебек үк, миңа да башта бик авыр булды. Бөтенләй икенче мәдәният, чит тел. Русча өйрәнү өчен күп тырышырга туры килде. Казан – бик кунакчыл шәһәр, һәм бу буш сүзләр генә түгел. Мин Россиянең башка шәһәрләрендә дә яшәдем, тик монда гына үзем өчен уңайлы, имин, рәхәт мохит таптым. Биредә этник кытайлар шактый. Шулай әкренләп ияләштем, беренче кытай ресторанын ачтым, аннары башкаларына да чират җитте. Әлегә шушы бизнесымны үстерүне планлаштырам, киләчәкне исә язмыш күрсәтер. Без, кытайлар, аңа ышанабыз!



Фото М.Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театры матбугат хезмәтеннән алынды.

АМАНДА ГОМЕС, БРАЗИЛИЯ:

– ТАТАРСТАН БРАЗИЛИЯ КЫЗЫНЫҢ ХЫЯЛЫН ТОРМЫШКА АШЫРДЫ

1

– Мин бала чагымнан ук Россиядә бию хакында хыялландым. Һәм менә 2014 елда бу тормышка ашты: Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры чакыруы буенча беренче солистка сыйфатында балет труппасына килеп кушылдым. Шул рәвешле Татарстан Бразилия кызының хыялын тормышка ашырды.

2

– Миңа биредә күп нәрсә – табигать, мәдәният, архитектура, иминлек ошый. Әмма безнең театрны Бразилиягә күчерү һәм океанга якынрак яшәү мөмкинлеге булса, тагын да яхшырак булыр иде.

3

– Бразилиядән мин күбрәк кочаклашу һәм елмаюларны, шулай ук тагын бер-ике айга җылырак һава торышын алып китәр идем. Татарстанда җәй искиткеч матур, аны бераз озынайтасы килә. **Әмма иң мөһиме – мин монда әти-әниемне һәм апамны яшәргә алып килер идем.**

4

– Казанга 19 яшемдә килдем һәм шуннан бирле яшим. Театрыбызның прима-балеринасына әйләндем, яраткан партияләремне биим: Жизель, Одетта-Одиллия һәм Эсмеральда. Биредә Бразилия Тышкы эшләр министрлыгының иң югары бүләге – Риу-Бранку орденына лаек булдым, халыкара конкурсларда җиңдем, «Тантана» һәм «БраVo» премияләрен алдым. **Тагын әле биредә мәхәббәтемне очраттым һәм гаилә кордым. Татарстан минем өемә әйләнде.**

Фото: Анастасия Хатыйпова

САИФ АЛИ ӘЛ-АСРИ, БЕРЛӘШКӘН ГАРӘП ӘМИРЛЕКЛӘРЕ:

– ТАТАРСТАН – ЯШӘР ӨЧЕН ИҢ РӘХӘТ ТӨБӘК!

1

– 2019 елның беренче сентябреннән Болгар Ислам академиясендә эшли башладым. Моңа кадәр гаиләм белән Чечняда яшәгән идек. Бер елдан Салмачи бистәсеннән зур йорт алып, гаиләмне дә бирегә алып килдем. Гаиләм ишле – җәмәгатем белән җиде бала үстерәбез. Олы улыбыз белән кызыбызның үз гаиләләре бар. Мин инде дәү әти, алты оныгым да бар.

2

– Толерантлык. Гаиләм белән күп илләрдә яшәп карадык, Россиянең башка төбәкләрендә дә булган бар. Минемчә, шулар арасында яшәр өчен иң рәхәте – Татарстан. Биредә башка милләт вәкилләре үзләрен ят тоймый, чөнки монда төрле халыклар үзара дус-тату яши. Дин күзлегеннән караганда да, Татарстанда бик тыныч. Ә бу бүгенге көндә бик мөһим, башка илләрдә нәрсә барганлыгын күреп торабыз бит.

3

– Мөмкин булса, туган ягымнан кояшлы җылы көннәрне алып килер идем. Татарстанда кышлар би-и-к озак, алты-җиде айга сузыла. Башта без, бигрәк тә балалар, моңа авыр ияләнде. Бездә ел әйләнәсе җәй. Ләкин тора-бара карлы кышка да күнегәсең икән, хәзер балалар да беренче еллардагы кебек зарланмый. (*Елмая.*)

4

– Беренче тапкыр Казанны 2016 елда күрдем. Шул чакта ук Татарстанның ачык, кунакчыл халкына бик шаккаттым. 2017 елда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов чакыруы буенча Болгар Ислам академиясе ачылышына килдем. Аннан соң мине Болгар Ислам академиясендә укытырга чакырдылар. Бүгенге көндә төп эш урыным шунда. Мин шәкертләргә ислам мәзһәбләрен, аларның хокукый үзенчәлекләрен аңлатам, фәнни эшләр язам. Һәм эшчәнлегемнең тагын бер юнәлеше – татар мәгърифәтчеләрнең иҗатын, алар калдырган мирасны өйрәнү, барлау. Габделҗәббар Кандалый, Шиһабетдин Мәрҗани кебек мәгърифәтчеләр татарлар арасында исламны тарата, бөтен мөселман илләренә Хәнәфи мәзһәбенең асылын аңлата.



Фото Иштиак Әхмәд Гилкарнең шәхси архивыннан

ИШТИАК ӘХМӘД ГИЛКӘР, ҺИНДСТАН:

– ТАТАРСТАННАН МИЛЛИ СӘЯСӘТ НЕЧКӘЛӘРЕНӘ ӨЙРӘНЕП БУЛА

1

– Белемем буенча мин – инженер-технолог. Университеттан соң медицина техникасы һәм технологияләре белән шөгыльләнә торган зур компаниядә эшләдем. Безнең офисыбыз Мәскәүдә, филиалларыбыз исә бөтен Россиядә урнашкан иде, шул исәптән Казанда да: медицина инструментлары заводы белән хезмәттәшлек иттек. 1994 елда мин бирегә эшкә килдем. Һиндстанның төньягындагы Кашмир шәһәрендә туып үскәнгәдер, Казандагы һава торышына тиз ияләштем: Кашмирда да шулай ук кыш та була, кар да ява. Тик анда кояшлы көннәр Татарстандагыдан барыбер күбрәк.

2

– Һиндстан белән Татарстан охшаш – минем ватаныма да мультимәдәнилек, күптеллелек, күпконфессияләлек хас. Әмма, минемчә, милли сәясәттә Һиндстан сездән күп нәрсәгә өйрәнә алыр иде. Халыклар дуслыгы йорты платформасында без бик бердәм, чыннан да дус яшибез. Барлык милли бәйрәмнәрне бергәләп билгеләп үтәбез, биредә үз мәдәниятебезне, үз телебезне саклар өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Татарстан халыклары ассамблеясы оештырган якшәмбе мәктәбендә шул исәптән һинд телен дә өйрәнергә мөмкин. Бүген дөньяда барган милләтара һәм динара каршылыклар фонында республика әлеге мәсьәләләрне ничек хәл итеп булуын үз мисалында бөтен җиһанга күрсәтә.

3

– Һиндстан икътисадының көчле тармаклары – мәгълүмати технологияләр һәм фармация. Татарстанда да IT тармагы үстерелә, Иннополис бар, IT-парклар эшли. Биредә шулай ук фармацевтика җитештерүләре дә үсеш алган. Минемчә, әлеге тармакларда Татарстан белән уртаклаша алырлык тәҗрибәбез бар. Гомумән, безгә фән, мәгълүмати технологияләр һәм мәгариф тармакларында ике якка да файдалы үзара хезмәттәшлекне арттырырга кирәк.

4

– Баштан ук үземнең фирмамда эшләдем (хәзер дә шунда эшлим). Әмма, моннан тыш, инде 15 елдан артык Татарстан халыклары ассамблеясындагы Татарстан белән Һиндстан арасындагы мәдәни элемтәләрне үстерү үзәген дә җитәклим. Без Татарстанда укучы һинд студентларына (күбесе медуниверситетта укый) ярдәм итәбез. Төрле мәдәни чаралар оештырабыз. Мәсәлән, Казанда һинд бию коллективлары күп, аларга булышабыз. «Татарстан балалары Һиндстанны ничек күрә» дигән темага рәсем конкурслары үткәрәбез.

Казан федераль университеты базасында, Россиядә беренче булып, Һиндстанны өйрәнү үзәген ачтык. Халык Һиндстан хакында күбрәк белсен өчен, портал булдырдык. Безнең илебез бик зур һәм кызыклы.

Казанда мин өйләндем, улым һәм кызым туды. Балаларымның без үткәргән чараларда катнашуына бик сөенәм. Казанда Һиндстан консуллыгы ачылуын зарыгып көтәбез – бу турыда күптән түгел Мәскәүдәге чыгышында Һиндстан Премьер-министры Нарендра Моди да сөйләде.



Фото «Алабуга» МИЗ матбугат хезмәтеннән алынды

ЙЕРУСАЛЕМ САМСОН, ЭФИОПИЯ:

– ДУСЛАРЫМ МИН ПЕШЕРГӘН ӨЧПОЧМАКНЫ МАКТАП АШЫЙ

1

– Миңа Татарстанга килергә «Алабуга Старт» халыкара программасы булышты. Аның турында Эфиопия Мәгариф министрлыгы аша белдем. Бик әйбәт шартлар тәкъдим иттеләр: самолетка бушлай билет, 40 мең сум хезмәт хакы, тулай торакта сигез кешелек бүлмә һәм рус теленә өйрәтү курслары.
Элегрәк хәтта күрше шәһәргә дә бер көннән артыкка барганым булмаганга, мөстәкыйль яшәп карыйсым килде. Катнашуга гариза биргәч, «Алабуга» белгечләре минем белән элемтәгә керде һәм барлык сорауларымны да хәл итәргә булышты. Һәм менә мин биредә.

2

– Җирле аш-суны бик яратам. Биредә ризыклар бик тәмле. Баштарак мин борщ, кара ипине бөтенләй аңламый идем – минем илемдә аларның берсе дә юк бит. Хәзер исә рус һәм татар халык ашларын бик теләп әзерлим. Дусларым мин пешергән өчпочмакларны мактап-мактап ашый. Татар халык ашлары – сәнгатьнең аерым бер төре ул.

3

– Мин Эфиопияне бик яратам, чөнки ул – минем туган илем. Аңа да Россиядәге кебек сәяси тотрыклылык телим. Тагын бездә дә милләтләрнең үзара килешеп, биредәге кебек дус-тату яшәвен теләр идем. Минем илемдә дә күп телдә сөйләшәләр, шулардан икесен белгәнгә, миңа рус телен өйрәнү Африка һәм Азиянең башка илләреннән килгән дусларыма караганда җиңелрәк бирелде. Хәзер, туган телемнән тыш, мин рус, инглиз һәм бераз испан телен беләм.

4

– Мин Татарстанга Яңа елдан соң, гыйнварда килдем. Бик суык булса да, тиз ияләштем. Җирле кыш өчен кирәкле җылы киемнәрне сатып алырга рус теле укытучыбыз һәм Алабугадагы остазыбыз булышты. Коллектив та мине яхшы каршы алды: коллегаларым эштә дә, рус телен өйрәнүдә дә ярдәм итте. Россиягә ничек ияләшүем, нәрсә уйлавым хакында гел сораштырып тордылар.

Биредә җиде ай эшләү дәверендә мин инде эшемдә дә уңышларга ирештем, Россиядән генә түгел, дөньяның башка илләреннән дә дуслар таптым.

Фото «Стрела – Ак Барс» клубы матбугат хезмәтеннән алынды

ДЖЕЙПИ НИЛ, КӨНЬЯК АФРИКА РЕСПУБЛИКАСЫ:

–– РЕГБИНЫҢ ТАТАРСТАНДА ТУЛЫ ТРИБУНАЛАР ҖЫЮЫН ТЕЛИМ

1

– Бу – бик кызыклы тарих. Мин Казанны түгел, ә ул мине сайлады. Бервакыт Намибия җыелма командасы тренеры сыйфатында Краснодарга иптәшләрчә матчка килдем. Нәкъ шул вакытта Казанда регби командасы булдыру хакында уйлашканнар. Матчтан соң регби буенча Россия җыелма командасының элеккеге тренеры Линн Джонс мине Казан клубын оештыру өчен җаваплы кешеләр белән таныштырды.
Бу 2018 ел иде.

2

– Татарстанда бик күп милләт халкы һәм төрле дин вәкилләре үзара гармониядә, дус-тату яши. Көньяк Африка да әлеге юнәлештә хәрәкәт итә, тик без әле бу юлга чыктык кына. Биредәге тормышның менә шушы үзенчәлеген үзебезгә күчерә алсак, бик яхшы булыр иде.

3

– Көньяк Африка Республикасында регбины бик яраталар, аңа дингә табынгандай табыналар дияргә дә була. Һәм минем иң зур теләгем – Татарстанда да шулай булсын иде. Себердәге командалар уйнаганны карарга ике мең ярым-өчәр мең җанатар килгән кебек, безнең трибуналар да шыплап тулсын. Спортның әлеге төрен Татарстанда да шулай яратсыннар иде.

4

– 2019 елның гыйнварында, Казанга килеп төшкәч, беренче күргән нәрсәм кар булды. Шулкадәр күп карны минем беркайда да күргәнем юк иде, Африкада без аңа бөтенләй күнекмәгән. Шулай булса да, мин үземнең Казанга бик тиз ияләшәчәгемне аңладым. Бу шәһәр – алтын урталык: ул Мәскәү кебек артык зур да түгел, кечкенә шәһәрләр кебек артык күңелсез дә түгел. Биредә бик рәхәт һәм уңайлы. Мин дә, гаиләм дә Казандагы тормышка җиңел ияләште. Ихтимал, бу башка шәһәр булса, мин инде кире әйләнеп кайтып киткән булыр идем.
Бүген мин баш тренеры булган «Стрела – Ак Барс» командасына килгәндә, ул әле шактый яшь клуб. Безне кайвакыт Красноярскиның «Енисей-СТМ» һәм «Красный Яр» командалары, яки «ВВА-Подмосковье» кебек команда белән чагыштыралар. Әмма болар бит – Россия чемпионатында күптән һәм уңышлы уйный торган клублар.
Шулай да, Россия премьер-лигасында нибары дүрт ел уйнау дәверендә никадәр уңышка ирешүебезне исәпкә алсак, бу бик рухландыра. Һәм без киләчәктә зур җиңүләргә өметләнәбез.



Фото Араш Таҗикның шәхси архивыннан алынды

АРАШ ТАҖИК, ИРАН:

– КАЗАНДА ҮЗЕМНЕ ӨЕМДӘ КЕБЕК ХИС ИТӘМ, ЧӨНКИ БЕЗНЕҢ ТЕЛЛӘРЕБЕЗ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ОХШАШ

1

– Казанда 2018 елдан бирле яшим. Казан федераль университетының Геология һәм нефть-газ технологияләре институтына аспирантурага укырга килдем. Хәзер авыр нефть темасы буенча кандидатлык диссертациясе якларга җыенам.

2

– Иранлыларга биредә күп нәрсә ошар иде, дип уйлыйм: кредит һәм ипотеканы бик җиңел алу мөмкинлеге дә; бензинның сыйфаты да (бездә А-95 бөтен ягулык салу станцияләрендә дә юк, нигездә А-92 генә, анысы да начар сыйфатлы); юл полициясенең машина йөртүчеләргә мөнәсәбәте дә... Биредә алар үзләре килә, таныклык күрсәтә. Иранда исә машиналарында утыралар, туктатсалар, яннарына барып, гафу үтенергә кирәк, ә анда бөтен кеше кагыйдә боза, бөтенләй диярлек йөреп булмый.

3

– Татарстанда, гомумән Россиядә, теләсә кайсы банкоматтан теләсә кайсы карта белән акчаны комиссиясез алып булмый. Онлайн-түләүләр белән дә шул ук хәл. Ә бездә банкинг бөтен җирдә комиссиясез. Җәмәгать транспортында кондиционерлар урнаштыру яхшы булыр иде. Шәһәрара транспортны да яхшыртырга кирәк. Иран шәһәрләрендә зур автобус терминаллары төзиләр, рейслар бик күп. Салонда исә утыргычлар бер генә кешелек, күрше комачауламый, рәхәтләнеп аяк сузып утырып була. Һәм нигәдер сезнең күп йорт янында җир асты парковкалары юк. Кышын кар күп, машинаны казып алырга да туры килә. Тагын мәдәни аспект та мөһим: мәдәни багланышлар көчлерәк булган саен, җәмгыятьнең аң-белем дәрәҗәсе югарырак була бара бит.

4

– Күптән түгел өйләндем, хатыным татар, Лениногорскидан, ТР Спорт министрлыгында эшли. Казанда озаграк яшәгән саен, биредә төпләнергә дигән фикерем көчәя генә бара. Чөнки яраткан эшем дә бар – мин һәрвакыт фән белән шөгыльләнергә хыялландым, Татарстанда үземне өйдәге кебек хис тә итәм, чөнки мәдәниятебез дә, телебез дә охшаш. Менә минем лабораториямнең тәрәзәсенә генә күз салыгыз әле – шәһәр үзәгенә, Кремльгә искиткеч манзара ачыла... Моннан ничек китәсе килсен инде!



Фото: Александр Ефремов

ПИТЕР СӘЕД, МИСЫР:

–– МОНДА ҮЗЕМНЕ КАҺИРӘДӘГЕ КЕБЕК ХИС ИТӘМ

1

– Мин Грузия медицина университеты интернатурасында укыдым. Тбилисида булачак җәмәгатем белән таныштым. Дарья – Казан кызы. Ул анда ял итәргә килгән иде. Мин аңа бер күрүдә гашыйк булдым, танышкан көнне үк: «Мин сиңа өйләнәм», – дидем. Күргәнегезчә, сүземдә тордым. **Без Россиядә яшәү перспективалырак дип таптык, шул исәптән табиблар өчен дә. Әти-әни фатыйхасын алып, Татарстанга күчендек. Монда мин үземне Каһирәдәге кебек хис итәм.** Бездә дә шулай мәчет белән чиркәүләр янәшә тора. Ике диндәге кешеләр бер-берсенә хөрмәт белән карый, ә бу – бик мөһим.

2

– **Һичшиксез, туган җиремдә дә мондагы кебек ял итү урыннарын булдырыр идем.** Парк, скверлар турында сүз бара. Менә Казанның кайсы гына почмагына барма, рәхәтләнеп ял итәр, спорт белән шөгыльләнер өчен урын табасың. Ә Мисырда андый җирләр күп түгел. Әйе, бездә кафелар күп. Тик бит ашагач ул калорияләрне кайда да булса яндырырга да кирәк. (*Көлә.*) Аннары күңелгә ятышлы тагын бер әйбер – электрон хезмәтләр бер дигән эшли. Мәсәлән, күптән түгел өйдә утырып кына чит ил паспортына документлар тапшырдым. Ә Мисырда Россиядәге кебек дәүләт порталлары эшләми. Берәр документ кирәк булса, дәүләт оешмасына барып, фәлән сәгать чират торасың. Онлайн язылу, документлар тапшыру дигән әйберне халык бөтенләй белми.

3

– **Мисыр ризыкларын сагынам. Шашлык, кәбаб кебек ит ризыклары бездә бөтенләй икенче төрле, тәмлерәк. Шул ук дөгене дә бездә биш төрле әзерлиләр. Ә биредә аны бары пешерәләр. Мисырда балык белән ашау өчен бер төрле дөге, ит өчен – икенче төрле... Аны суган, помидор, башка яшелчәләр белән әзерләп, телне йотарлык итеп пешереп була.** Ә менә бәрәңгене Россиядә әллә ничә төрле итеп әзерлиләр. Мисырда исә бәрәңге ике генә төрле: кыздырылган һәм боламык итеп ясалган була. Халыклар төрле булган кебек, ризыклар, ашау культурасы да төрле шул. Акрынлап мондагы ризыкларга ияләнәм. Татар халык ашлары бик ошый. Төрле тәмләткечләр белән пешерелгән сарык итен яратам, өчпочмак, бәлеш – барысын да авыз иттем. Һәм алар миңа туган ягымдагы ризыкларны хәтерләтә.

4

– **Казанга килгәч, аккредитация уздым. Васильево бистәсендә участок терапевты булып эшлим.** Район администрациясе торак белән тәэмин итте. «Земство докторы» программасы шартлары нигезендә миллион сум акча бирделәр, хезмәт хакым да яхшы, өстәмә түләүләр дә каралган. Шәһәрдәге участок терапевтларыныкы белән чагыштырганда бермә-бер артык дисәм дә була. Ачык, гади халык яши монда. Васильевога килгәч, коллектив яхшы каршы алды, халык белән дә уртак телне тиз таптык. Ә иң мөһиме – табибларга хөрмәт белән карыйлар.

Васильевода миңа ошый. Эш урыным белән яшәгән фатир күршедә генә. Җәмәгатем дә якындагы урта мәктәптә инглиз теле укыта. Кызыбыз Паула балалар бакчасына йөри. Казандагы кебек бөкеләрдә утырырга кирәкми, бик рәхәт. Ә Казан терәлеп тора, ял итәр өчен атнасына ике-өч тапкыр барып кайтабыз. Шулай булгач, Васильеводан китәргә дигән теләк тә, ният тә юк. Әле менә яңадан КДМУга укырга кердем, кардиология юнәлешен өйрәнәсем килә.

ШӘҺӘРЛЕ УЙНЫЙБЫЗМЫ?

Виртуаль төзүчеләрнең турниры «Татарстан БРИКС шәһәрләрен төзи» дигән исем астында уза. Шулай итеп, ул халыкара хезмәттәшлекне тагын да ныгыта.

Фото: kazan-news.net

КУБЛЫ ДӨНЬЯДА

Майнкрафт галәмендә виртуаль «төзелеш»не «Миллиард.татар» интернет-порталы оештырды. Анда Майнкрафт уены дөньясында иң үзенчәлекле һәм шәп архитектура корылмаларын параллель яссылыкта торгызу буенча «Таткрафт» бәйгесе инде бишенче мәртәбә уздырыла. Быелгы бәйге Казанда үтә торган БРИКС саммитына нисбәтле, исеме дә шуннан – «Татарстан БРИКС шәһәрләрен төзи».

– Турнир кысаларында без БРИКС шәһәрләрен төзибез. Бәйгедә Кытай, Бразилия, Африка, Көньяк Азия һәм Якын Көнчыгыш командалары катнаша, – дип сөйли проектның катнашучысы Илгизәр Вахитов, безне инде торгызылган истәлекле урыннар буйлап сәяхәткә чакырып.

Ә алар чыннан да бәйгегә старт бирелгән 12 август датасыннан башлап, инде шактый җыелып өлгергән: Бразилиядә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Көньяк Африкада, Иранда һәм Кытайда йөреп кайтырга мөмкинлек бар.

ИКЕ МӘМЛӘКӘТНЕҢ МӘДӘНИ АЛМАШУ ӨЛЕШЕ

Татарстанда яши торган кытайлыларны Кытай парламентының монументаль бинасы – Халык җыены йорты бик нык шаккатырды.

– Соңгы елларда Россия һәм Кытай арасындагы хезмәттәшлек торган саен ныгый бара, шул исәптән мәдәният өлкәсендә дә. Гуманитар өлкәләргә килсәк, алар да күзгә күренеп төрлеләнә, – дип бәя бирде уенчыларның архитектура үрнәгенә Кытайның Казандагы генераль консулы урынбасары Цао Лунцюань. – Оештыручысы Татарстан Республикасы булган әлеге турнир ике мәмләкәт арасындагы мәдәни алмашуның бер өлеше. Россия Президенты Владимир Путин һәм КХР Рәисе Си Цзиньпин карарлары буенча 2024–2025 еллар ике илдә дә Мәдәният елы дип игълан ителде.

Лунцюань шулай ук бәйгедә 30 Кытай киберспортчысы катнашуы хакында да хәбәр итә.

АКЧА ҺӘМ ЭКСКЛЮЗИВ МЕРЧ

Ә барлыгы бәйгедә бөтен дөньядан ике йөзгә якын кеше җәлеп ителгән. Бәйгедә катнашучыларны бүләкләр көтә: приз фонды 85 мең сумны тәшкил итә.

Моннан тыш, проектның партнёры, ягъни «ТН-Наследие» АКБҖ махсус приз да әзерләгән: Габдулла Тукай исемендәге «Казан» Халыкара аэропорты белән «Казан Экспо» Халыкара күргәзмәләр үзәген «төзүчеләргә» – эксклюзив мерч.

Шулай да проектта катнашучыларны призлар гына кызыктырмый:

– Уен бүгенге көндә бик тә кирәкле булган сыйфатларны үстерергә ярдәм итә, болар – креативлык, аралаша белү, командада эшләү осталыгы, – ди КФУның ХМИ халыкара эшчәнлек буенча директор урынбасары Светлана Тахтарова. – Әле тагын проект берләштерү көченә дә ия. Мин бу турыда ишетеп кенә түгел, ә эченнән күреп беләм: өч оныгым да уенны мавыгып һәм яратып уйный.

9 сентябрьдә, бәйгенең нәтиҗәләре игълан ителгәндә, кублы дөнья инде БРИКС шәһәрләре белән бөтенләй тулылана. Ә аларны «Татарстан төзи». Димәк, халыкара элемтәләр тагын да ныгыйрак төшә, дигән сүз.



Иран, Тәһран
Азади манарасы
Төзүче: EpDan

Кытай, Пекин
Халык каһарманнарына монумент
Төзүче: КОРО4КА_МАЕНЕЗА





БГӘ, Дубай
Бастакия районы
Төзүче: Reysun



Бразилия, Рио-Де-Жанейро
Тарих музее
Төзүчесе: ElKukui


Һиндстан, Дәһли
Хумаюн төрбәсе
Төзүчесе: Vladislav_BEL

Мисыр
Хефрен пирамидасы
Төзүчесе: КОРО4КА_МАЕНЕЗА

Россия, Казан
Аэропорт
Төзүче: Rimap_

Иран, Исфахан
Шәех Лотфулла мәчете
Төзүчесе: КОРО4КА_МАЕНЕЗА

КАР, Претория
Гадел хөкем академиясе
Төзүчесе: vlad2kk

БАР ДА ӨСТӘЛДӘН БАШЛАНДЫ...

Хатын-кыз барысын да булдыра. «Чабып барган атны да туктата, янган ызбага да барып керә...», – дип язган бит Некрасов та. Әмма алай ук кирәкми. Тирә-ягыбызда күпкә тынычрак, тормышчанрак мисаллар бар бит.
Мәсәлән, Карина Пикулева очрагы. Матур кухня өстәле ясау турындагы хыялын чынга ашырып кына калмый ул, аны үстереп, премиум-класслы мебель җитештерү бизнесына да нигез сала! Моңарчы бу юнәлештә Италия җитештерүчеләре беренчелекне тотса да, Карина аларга Казанның нәрсәгә сәләтле булуын күрсәтә. Хәзер инде CARIN CASA мебеленә заказлар бөтен Россиядән килә. Ә тәрҗемәдә брендның исеме «Ягымлы өй» дигәнне аңлата.

ЯГЫМЛЫ ӨЙГӘ – ЯГЫМЛЫ ӨСТӘЛ

– Мин, мөгаен, перфекционисттыр, – дип башлый сүзен Карина. – Фатирымда ремонт ясый башлаганнан бирле бу темага баштанаяк чумдым. Бигрәк тә – кухня мәсьәләсендә. Төрле дизайнерларга язылдым, трендларны өйрәндем. Шулай итеп, нәрсә телләгәнемә бәйле рәвештә, күз алдымда бөтен бер сурәт пәйда булды. Итальян мебеле теләвемне аңладым, ул минем рухыма туры килә. Фатирымны нәкъ менә шул стильдә күзаллый идем. Әлбәттә, андагы бәяләр шактый ук «тешләшә»... Өстәл сайлый башлагач, бөтен сайтларны актарып чыктым, һәм аны таптым да. Италия стилендәге бу керамик өстәлнең бәясе дә гаҗәеп иде – миллион +. Бер өстәл өчен – миллион! Бу инде галәми акчалар, билгеле! Һәм мин шундый өстәлне үзем ясап карарга булдым. Шушы темага кереп чумдым. Баштарак безнең кухняга корпуслы мебель ясаган осталарга заказ бирергәме әллә, дигән идем. Әмма алар керамика белән бөтенләй эш итмәүләре турында әйтте, алынмады...

Шул мизгелдә башымда бер идея туды! Ул әле Россиядә берәүнең дә башында тумаган булып чыкты. Димәк, бу эшне башкарып чыгарга ният кордым. Мин бит, иртәме-соңмы, эшмәкәр буласымны беләидем, моңарчы бары тик төп идеямне генә тапмый йөрдем. Һәм менә, ниһаять, йолдызлар кухня өстендә бер бөтенгә җыелды – идея дә балкып кабынып китте!

«БУ – МЕБЕЛЬ. МИН АНЫ ЯРАТАМ»

– Идея, билгеле, искиткеч. Әмма аны тормышка ашырыр өчен, ким дигәндә, агач остасы булыр-

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

га кирәктер. Әллә юкмы? Әллә бәлки, сез укыган Казан дәүләт финанс-икътисад институтында «Салымнар һәм салым салу» бүлегендә агач эшен, яшерен рәвештә генә булса да, өйрәтәләрдер?

– Юк, билгеле, – дип елмая Карина. – Әмма җитештерү өлкәсендә мин инде дүрт ел диярлек яшим. Һәр елы ике елга торырлык. Практикада өйрәнәм ягъни. Бик күп укыйм. Өч мәртәбә Италиядә булдым, Миландагы iSaloni күргәзмәсен карадым. Итальян белгечләренең тәҗрибәсен туктаусыз үзләштерәм: карыйм, өйрәнәм, анализлыйм. Техник документацияне дә бер олау актарып, өйрәнеп чыктым...

– Ягъни сезне, мәсәлән, космик кораблар чыгарырга кирәк, дигән идея йолып алса, сез аны да булдырачаксызмы? Бары өйрәнергә генә кирәкме?

– Юк, анысы булмас! – дип көлә Карина. – Бу очракта сүз бит мебель турында бара, ә мебельне мин яратам. Менә шулай, кызык кына итеп, минем иң яраткан эшем агач эшкәртү булып чыкты. Бәлки, эш геннарда, нәселдәдер. Әтием – подполковник, ул банкның сак хезмәте директоры вазыйфасыннан пенсиягә китте. Сүз уңаеннан, әни белән икесе дә минем банкта эшләвемне бик теләделәр. Әтием үз куллары белән менә дигән итеп мебель ясый белә. Мин аның бу осталыгына сокланам. Шуңа да бу эшкә тулаем үземне багышлаганмындыр, бәлки. Ул миңа өйрәнер өчен көч һәм энергия бирә. Әгәр кызыксыну, омтылыш булмаса, бернинди нәтиҗәләргә дә килеп булмас иде, дип уйлыйм. Ә хәзерге вакытта без, җитештерүнең бишенче елында, премиум-класслы мебель әзерлибез һәм еллык керемебез 250 миллион сумны тәшкил итә. Әле бу – алты ел элек билгеләнгән бәяләр буенча.

– Димәк, мебель белән сезнең мәхәббәтегез берьяклы гына түгел, дип, ышанып әйтергә мөмкин.

КАРИНАНЫҢ ӨЕ

– Ни өчен сез үз оешмагызны «Ягымлы өй» дип кенә атамадыгыз, итальянчага тәрҗемә иттегез?

– Баштарак безнең компания MIA CASA дип атала иде, ягъни «Минем өем». Барысы да, чыннан да, минем үз өемнән башланды бит. Итальянча аталыш үзе минем итальян җиһазларына мәхәббәтемнән килеп чыкты. Югыйсә, төрле стильләр бар – Скандинавия стиле, Америка неоклассикасы һ.б. Алар минеке түгел. Минеке – Италия рухы.

Ел ярым без MIA CASA исеме белән яшәдек. Шуннан соң мин аны теркәргә киттем. Белмим, ни өчен Роспатентка шунда ук мөрәҗәгать итмәгәнмендер... Барсам, нәрсә ачыкланды: бу исемне ярты ел элек башка бер компания үзләштергән дә теркәп үк куйган булып чыкты. Әлбәттә, судлашырга була иде, без бит бу атама белән алданрак эш итә башладык. Әмма вакытны моңа сарыф итәсе килмәде, брендның исемен алыштыруны кулайрак күрдем.

Озак уйлап йөрдем, аннары иремә әйтәм: «Ә ник әле үз исемем белән атамаска – «Карина өе» дип? Бу бит – минем өем. Тәрҗемә итә торган кушымтада атаманы кертеп карасам, «ягымлы өй» килеп чыга – CARIN CASA. Тагын йолдызлар барысын да килештереп китереп куйгандай! Җитмәсә, ул чакта мин декретта утыра идем, буш вакытым – җитәрлек. Өзлексез социаль челтәрләргә чыгып, безнең мебель турында сөйлим. Компания минем исемем белән ассоциация тудыра. Шуңа да яңа атама – CARIN CASA – үзеннән-үзе килешеп, урынына утырды да куйды.

«Ягымлы өем» нәкъ менә без башлап сөйләгән өстәлдән башланды. Хәзерге вакытта комодлар белән стеллажлар җитештерүне дә үзләштерәбез. Кешеләр мебельне бер стилистикада заказ биреп алырга ярата – бу бик уңайлы, гармония дә, тәңгәллек тә дигән сүз.

ПРЕМИУМ-КЛАСС ӨЧЕН – ПРЕМИУМ-БЕЛГЕЧЛӘР

– Премиум-класс дәрәҗәсендәге мебельне җитештерү өчен белгечләрне каян аласыз?

– Белгечләр – бу иң кыен мәсьәлә. Даими эзлибез. Минем хәзер иң башымны авырттырган сорау – Наполеон планнары кордык-коруын, аларны тормышка ашырырдай осталарны ничек табарбыз? Һәр елны үзебезгә «үсеш планы» куябыз. Шул планга туры килердәй итеп җитештерү куәтен исәплибез, бездә булмаган, әмма кирәкле җайланмаларны сатып алабыз, персонал туплыйбыз. Төбәкләрдән дә эзләргә туры килә. Мәсәлән, җитештерү башлыгын мин Ульяновск өлкәсеннән табып алып кайттым. Без аның белән бик озак сөйләшүләр алып бардык. Нәтиҗәдә, ул зур мебель фабрикасын калдырып, безгә эшләргә күчте.

Куллары белән мебель җыя торган хезмәткәрләрнең эш хакы – эш күләменә карап. Административ персоналныкы – катнаш: оклад һәм айлык сату куәтенә бәйле, премия өлеше дә бар.

Агач эшкәртү һәм металл цехында бәяләр әйбәт безнең. Мин берөзлексез Казандагы хезмәт базарына мониторинг ясап торам. Бу бик мөһим, чөнки без иң яхшы хезмәткәрләрне җәлеп итәбез. Әлбәттә, аларга куйган таләпләребез дә бик югары.

ӨЛГЕРЛЕК БУЕНЧА ОСТАЛЫК ДӘРЕСЕ

– Мебель җитештерүче Казан осталарын белүем буенча, аларның иң «асыл» сыйфатлары – мөмкин булган барлык срокларны тагын да озаккарак сузу. Ягъни беркем дә беркайчан да заказны тиешле вакытында тапшырмый. Сез үз хезмәткәрләрегезне бу яктан ничек тәрбиялисез, заказларны вакытында өлгертүгә ничек ирешәсез? Бу өлкәдә осталык дәресләре комачауламас иде, билгеле.

– Теләсә кайсы заказга алынмыйбыз. Кайбер заказлар безнең тарафтан сайлауны нәкъ менә сез әйткән сәбәп буенча да узмый, башка күп сәбәпләре дә бар. Ә инде заказ алынган икән, аны көн дә үтәргә, эшләргә кирәк. Минем моңа кадәрге консалтингта эшләгән тәҗрибәм бик кулай булып, ярап куйды. Мәсәлән, шул ук «ЛУКОЙЛ», Gazprom оешмаларында. Аларда – бик анык, җайга салынган система. Безнең эштә дә мин һәр агач остасының графигын бик төгәл системага салырга тырышам, һәр заказны этапларга бүләргә. Әзерләү, җитештерү, шомарту, буяу, төрү, тикшерү – бу процессларның барысын да тиешле эзлеклелеккә салсаң, срокларны үтәсәң, һәр хезмәткәрне шул көйгә көйләсәң, барысы да мөмкин. Шартлы рәвештә әйткәндә, әгәр хезмәткәр берничә заказ ала һәм аны этаплап үти икән, димәк,

графигын да тиешенчә итеп төзергә тиеш була. График аның эшләү рәвешеннән һәм өлгерү мөмкинлекләреннән исәпләнеп тә төзелә, ул – реаль эш сызымы. Аерым бер эшләнмәне эшләп чыгу өчен билгеләнгән вакыт бар. Безнең җитештерүдә бөтен нәрсә дә төгәл системага салынган.

Билгеле инде, көн дә сыйфат ягыннан тикшерү каралган. Әгәр мин җитештерү цехында нинди дә булса брак күрәм икән – әйтик, шпон тиешенчә ябыштырылмаган яки өстәлнең аскы ягында берәр җөй, ботак урыны калган – кабат эшләргә җибәрәм. Андый очраклар эшкә яңа килгән хезмәткәрләр белән булгалый. Шпонны, мәсәлән, ярыйсы гына ябыштыралар, әмма безнеңчә, «карин-касача түгел», дибез андый чакта. Үзгәртеп эшлиләр, үз ялгышларында өйрәнәләр, алга таба андыйны кабатламый башлыйлар. Бездә яңа килгәннәргә баштарак игътибар бик зур, аларны күзәтәбез. Беренче өстәлләре гадәттә – сынау өстәле, шуннан барысы да күренә.

дек: беренчесе – без Россиядә иң сыйфатлы мебель җитештерәбез, икенчесе – беркайчан да срокларны кичектермибез, өченчесе – үз абруебызның да, һәрбер клиент белән мөнәсәбәтләребезнең дә кадерен беләбез. Шуңа да карамастан, уңайсыз хәл килеп чыкты, яшереп тормыйм. Хәл ачыклануга, хезмәткәрләр белән бергә түгәрәк өстәлгә җыелдык та анык бер карарга килдек: җитештерү срокларын арттырабыз һәм клиентларга бу хакта ачыктан-ачык аңлатабыз. Элек безнең җитештерү вакыты 45 календарь көнне тәшкил итсә, хәзер бу – 45 эш көне. Һәр атнада без җитештерү графигын яңадан күздән кичереп барабыз. Әгәр җитештерүчеләрнең вакыты һәм мөмкинлеге 100 %ка сарыф ителгән икән, димәк, срокларны озайтабыз, йә булмаса, башка бер генә заказ да алмыйбыз. Клиентка алдан үк әйтеп кую зарур: мәсәлән, ноябрь инде буш түгел, сезнең заказны бары тик киләсе айда, декабрьдә генә эшләргә ала алабыз. Бу 45 көн эчендә җитештерәбез,

> CARIN CASA – РОССИЯДӘ КЕРАМИКАДАН ӨСТӘЛЛӘР ЯСАУ БУЕНЧА ИҢ ЭРЕ ҖИТЕШТЕРҮЧЕ. УЛ 2019 ЕЛДА АГАЧ ОСТАХАНӘСЕ НИГЕЗЕНДӘ ОЕША ҺӘМ ҮСЕП КИТӘ.

Гадәттә, ул әллә ни әйбәт килеп чыкмый. Икенчесе дә әле – ярап торырлык кына. Ә менә өченчесе инде, гадәттә, шәп дип тел шартлатырлык була!

Срокларга килгәндә... Бездә июнь аенда шундый бер очрак булды. Күпсанлы күргәзмәләрдә катнашканнан соң, килгән сорауга җавап бирердәй итеп җитештерә алмаячагыбызны исәпләмәгәнбез булып чыкты. Берничә заказчыга мебельне ике-өч атнага соңарып тапшырырга туры килде. Алар алдында үзебезне бик уңайсыз хис иттек, чөнки төп принципларыбызны үтәмә-

дип ышандырып, заказны 60 көннән соң бирүгә караганда гаделрәк.

Әйткәнемчә, июнь аенда үтәү срокларын боздык. Шуңа күрә заказларның бәясен дә яңадан санадык (килешү буенча без пени түләргә тиеш). Кайберләренә заказ белән бергә кечкенә генә бүләкләр тапшырдык. Бер клиентыбыз, сөйләшенгән срокка өлгертә алмавыбызга карамастан, тагын бер заказ белән килде, әлбәттә, аңа яхшы гына ташлама ясадык. Шундый барлык очракларны җентекләп анализлап чыктык, җиренә җиткереп, тәртипкә китереп бетердек.

ТӘХЕТ ВАРИСЫ

– Сезнең бизнесыгыз декрет ялы вакытында башланган. Эшмәкәрлек өчен иң җиңел вакыт дип әйтеп булмый. Хәзер кызыгызга алты яшь. Аны тәрбияләү белән беррәттән эшне дә алып бару – боларны ничек үзара яраштырасыз?

– Өч смена эшләп.

– Ә йокларга вакыт каламы?

– Көнгә алты сәгать йоклыйм. Үземне шуңа көйләдем: эшләвен ялларсыз эшлим, әмма елга дүрт мәртәбә ял оештырам. Гадәттә, гаилә белән бер атнага яки атна ярымга кая да булса китәбез. Эшне анда үзебез белән алмыйбыз. Әмма бу «тулаем яллар» аралыгында мин дә, ирем дә ялсыз-нисез эшлибез. Ирем үзем кебек үк – эш аты.

– Ә ирегез тәүлек буе диярлек буш булмаган хатынына ничек түзә?

– Үзе шундый булгач, ул мине аңлый. Ул башка өлкәдә эшли, без аның белән кисешмибез.

Мин үз эшемне яратам, чын-чынлап мавыгып эшлим. Беренче елны без 40 миллион акча эшләдек, ә быел, менә, 250 миллионга чыктык. Дөрес, керем ягыннан бу әллә ни зур суммалар түгел. Чөнки җитештерү бизнеска булган кертемнәргә бәйле рәвештә үсә. Мин бик теләп станоклар сатып алам. Хәзер без цифрлы программа белән идарә ителә торган, ягъни чираттагы ЧПУ станоклары сайлыйбыз. «Гильотина»ны да Казанда алабыз, белүемчә, мондый нәрсәләр бездә әле беркемдә дә юк. Шулай итеп, финансларны кеше ресурсларына кушсаң, персоналны кайгыртсаң, ахыр чиктә, болар барысы да үсешкә китерә.

– Ялларсыз эшлисез, алты сәгать йоклыйсыз, елга дүрт мәртәбә ял итәсез... Кызыгызның, үскәч, сезнең бизнесны дәвам итүен телисезме?

– Баштарак, әйе, моны бик теләдем, Камилла үсәр дә минем эшне дәвам итәр дип уйладым. Әмма хәзер аңлыйм: аның үз кызыксынулары булырга мөмкин. Мин аларны ихтирам белән кабул итәрмен дип ышанам. Бу – аның сайлау хокукы, ничек хәл итсә, шулай булыр. Әлбәттә, минем эшемне дәвам итсә, бу зур шатлык булачак. Әмма әле белеп булмый, минем үземнең аны ул үсеп җиткәнче «тартып барырга» хәлем җитәрме? Дөресен генә әйткәндә, шулкадәр арыган, җеп өзәрлек тә хәл калмаган вакытлар була... Өйгә кайтып керәм дә, күз яше белән иремә: «Булды, җитте, бүтән хәлем калмады», - дим. Ә аннары кәгазь алам да барлык проблемаларны язып чыгам, дүрт ел эчендә ниләр эшләгәнне, нәрсәләргә ирешкәнне тер-

ким, ни кичергәнне, кичкәнне искә алам. Һәм... алга таба җиңеп булмастай тоелган мәсьәләне хәл итәргә яңа көч-егәр табам.

– Сез, мөгаен, мәктәптә отличница булгансыздыр, әйеме?

– Әйе. Нәкъ үзе. Һәм бу миңа бик нык комачаулый.

БИЗНЕС ПЛЮС СЕГМЕНТЫ

– Отличницалар һәрчак премиум-класска йөз тотамы? Әллә җиңелрәк һәм гадирәк нәрсәләрдән дә башлыймы?

– Беренчедән, барлык башлангычларда да мин үземә һәрчак иң югары планканы куям, компромиссларга барырга да күнекмәгән. Икенчедән, бу гадәткә мине халыкара аудиторлык компаниясендәге эшем өйрәтте. Без Россия һәм Татарстанның иң эре компанияләре белән эшли идек, шулай булгач, бездән һәрвакыт иң сыйфатлы нәтиҗә таләп иттеләр.

Минем өчен бизнес сегменты әһәмиятле: бизнес һәм бизнес плюс. Һәм нәкъ менә Италия керамикасы белән эшләү. Бездә, Казанда, мондый дәрәҗәдәге мебель җитештерүне оештыра алуым белән чын мәгънәсендә горурланам.

Безнең компания бик күп күргәзмәләрдә катнаша. Казанда гына түгел, ә Мәскәүдә, Россия күләмендә. Күптән түгел генә Гостиный дворда узган ARTDOM 2024 Халыкара мебель, интерьер мәсьәләләре һәм сәнгать күргәзмәсендә катнаштык.

Шуннан соң безне Мәскәү дизайн һәм интерьер атнасына чакырдылар. Баксаң, катнашучыларны анализлаган комиссия без күрсәткән «Пирамида» өстәлен флагманнарча эшләнмә дип тапкан икән. Һәм бу өстәл, күргәзмә башланганчы, ай дәвамында бөтен Мәскәү буйлап билбордларда эленеп торды. Кызыл мәйдан янында Манеж ачылганда да иң олы алтактада аның сурәте иде.

Сентябрь аенда Мәскәүдә Made in Russia Expo күргәзмәсендә катнашабыз, ә киләсе елда, февральдә, янә ARTDOM чакыра, «Крокус Экспо»да зур стенд булырга тиеш... Мин әле моны ничек эшлисебезне белмим. Скарлетт О'Хара әйтмешли, «бу хакта иртәгә уйлармын»...

– Скарлетт О'Хара әйтмешли?

– Әйе. «Унесённые ветром» мәктәптә укыганда иң яраткан китабым иде. Институтта чакта да бер өч тапкыр укып чыкканмындыр...

Кыскасы, Мәскәү күргәзмәләрендә катнашканда, безнең стенд янына Россиянең эре мебель компаниясе вәкилләре килә дә, Казаннан булуыбызны белгәч, бик нык гаҗәпләнә. Чөнки бездә йорт җиһазы базарлары әллә ни үсеш алмаган. Нигездә, Ульяновск һәм Чиләбе өлкәсен искә алалар... Минем бик тә Казанда югары сыйфатлы мебель җитештереп булуына ышандырасым, безгә игътибарны җәлеп итәсем килә. Казан безнең белән горурлансын!

– CARIN CASA мебелен кайда күреп һәм горурланып була соң?

– Сентябрь азагында без Казанда зур шоурум ачабыз. Касаткин урамы, 23 йорт, адресы буенча – «Альтура» Торак комплексында.

– Сезнең мебель бәяләре шулай ук «бизнес плюсмы»?

– Бер миллионлык Италия өстәле сезне илһамландырмадымы?

– Ярый әле сатып алмагансыз, дип уйладым.

– Әйе. Безнең өстәлләр яхшырак. Һәм күпкә арзанрак та. Бәяләргә килгәндә, бер тарих сөйләп үтим әле. Бездән еш кына мәскәүлеләр заказ ала. Ә алар нигездә эшкә чумган, вакыты аз кешеләр. Гадәттә, мебельне сайлап бирә торган дизайнерлар аша гына эш итәләр: менә өстәл, менә адрес, кара да хәл ит, тиз генә барысын да оештыр. Еш кына шундый хәлләр дә була: клиентлар килә, мебельне тиз-тиз генә сайлый, баштарак хәтта бәяләр турында да сорап тормый. Ә аннары, безнең бәяләрне белеп алгач, заказ ясаган хуҗалар, дизайнерларына шалтыратып, ачуланып җикеренәләр: «Ни өчен мин калган җиһазларны биш мәртәбә кыйммәтрәк бәягә алдым? Ник мине баштан ук монда сатып алырга җибәрмәдең? Ник мин Италия өчен биш тапкыр күбрәк акча түлим дә аны бер елдан соң гына көтеп алам, ә монда кулай бәягә реаль срокларда шундый ук яхшы сыйфатлы продукция алып була икән...»

ЭШ КЕШЕЛӘРЕНЕҢ ГАИЛӘ БӘХЕТЕ

– Гаиләдә бер-берсе белән аңлашып ике эш кешесе яши, дидегез. Тәүлекнең 24 сәгатен һәм атнаның 7 көнен эшләүгә карамастан, сез әле бала тәрбияләргә дә өлгерәсез. Ничек берберегезгә түзәсез һәм качып китмисез, сөйләгез әле безгә?

– Рәхәтләнеп сөйлим. Әйе, без сирәк бергә булабыз, әмма берәгәйле. Безнең максатларыбыз бер төрле, кызыксынуларыбыз. Үзара сөйләшер сүзебез бетми. Кичләрен өйгә кайтканда, мин иремә көннең ничек узганын сөйләргә хыялланып кайтам. Аның сөйләгәнен дә кинәнеп тыңлыйм. Без тәэсирләр белән бүлешәбез, бу һәрвакыт кызыклы һәм рәхәт. Без бер телдә сөйләшәбез, бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз. Ун ел буе бергә яшәгәннән соң, хәтта бер төрле уйлыйбыз да. Әле күптән түгел генә Казан - Шанхай рейсын ачалар икән дип каяндыр укыдым. Саша белән бу юлы кайда ял итәрбез икән дип уйлап йөри идек. Кытай турында башка да килгәне булмады. Һәм менә ул яңалык чыгу белән, мин аңа «Телеграм»да язам: «Саша, безгә Шанхайга барырга кирәк дип уйлыйм, миңа да мебель буенча ничек эшләгәннәрен карап кайту шәп булыр». Ә ул миңа «Вотсап»ка язып ята: «Карале, безгә Шанхайга барырга, бәлки? Аннан тагын берәр кая – анысын карарбыз...» Сорыйм үзеннән: «Син «Телеграм»га кердеңме?» «Юк», – ди. «Кер әле!» – дим. Шуннан соң яза: «Ну, нәрсә диим инде? 10 ел бергә яшибез бит».

Тагын нәрсәме? Бер-беребезне хөрмәт итәбез, иң мөһиме шул. Проблемалар килеп чыкса, шунда ук өстәл артына утырып, аларны ничек хәл итеп булуын уйлыйбыз.

– Теге өстәлме?

– Әйе! Нәкъ шул! Барысы да шул өстәлдән башланды. Утырабыз, сөйләшәбез, тәмле ашыйбыз, хәл итү юлларын эзлибез. Ул өстәл безгә бөтен мәсьәләләрдә дә булыша.

– Сентябрь азагында Казанда зур шоурум ачабыз. Касаткин урамында, 23 йортта, «Альтура» Торак комплексында. Оксана Шейх студиясе дизайн-проекты.

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность
Реклама 16+

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Цифр тормышыбызның гадәти өлкәләрен **ничек** үзгәртә

Казанны **нинди** куллар кочаклар

Җирле матурлыклар **кай** ягы белән сокландыра

ИҖАДИ ЦИФР ВАКЫТЫ

ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР МӘДӘНИЯТ БЕЛӘН НИЧЕК ЯРАША

Евгения Чеснокова

Инде традициягә әверелгән Kazan Digital Week-2024 Халыкара форумы Татарстан башкаласында 9–11 сентябрьдә узды. Бөтен дөньядан цифрлы технологияләр, программа тәэминаты, югары технологияле продукция җитештерүчеләр һәм кулланучылар цифрның көндәлек тормышыбызны ничек үзгәртүе, яңа технологияләрнең нинди уңайлылыклар тудыруы һәм таләпләр куюы хакында фикер алышты.

Фото: tatar-inform.ru, kazandigitalweek.com

Бүген бөтен нәрсә цифрга күчә. Форум алдыннан без Казан дәүләт мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева белән XXI гасыр технологияләренең мәдәни үрнәкләргә ничек йогынты ясавы турында сөйләштек.

– Роза Шәйхәйдәровна, сезнең югары уку йортыгыз да Kazan Digital Week форумында катнаштымы?

– Әлбәттә, Казан дәүләт мәдәният институты – форумны оештыручыларның берсе, мин анда эш төркеме рәисе урынбасары булып торам.

Форумда безнең уку йорты «Мәдәнияттә цифрлы технологияләр» юнәлеше эшен оештыра. Секция эше кысаларында креатив индустрияләр үсешенең яңа траекторияләре, фәнгә һәм иҗатка инвестицияләр кертү проблемалары, Россия университетларын трансформацияләү мөмкинлекләре һәм таләпләре, шулай ук илнең технологик суверенитетын тәэмин итүдә яшь тикшеренүчеләрнең роле турында фикер алышалар.

Мәдәният институты түгәрәк өстәлләрдә, техник визитларда, дискуссияләрдә, мастер-классларда турыдан-туры катнаша. Күргәзмә экспозициясе кысаларында без мәдәният өлкәсендәге яңа цифрлы карарларны, стартаплар конкурсларында җиңгән һәм хакатоннарда катнашкан студентларыбызның эшләнмәләрен күрсәтәбез.

Югары уку йортыбызның әйдәп баручы экспертлары һәм укытучылары лекцияләр укый. Аларның чыгышларында яктыртылган темалар, аерым алганда, заманча сәнгать әсәрләрен алга этәрүнең цифрлы практикасына, мультимедиа продуктларын эшләүдә ясалма интеллектның роленә кагыла...

Һәм, әлбәттә, без форумны ачу һәм ябу тантаналарын, шулай ук катнашучылар һәм кунаклар өчен бәйрәм концертын әзерләдек.

Студентларыбыз тагын форумда волонтерлар буларак бик актив катнаша һәм, һичшиксез, һөнәри компетенцияләр формалаштыруда бай тәҗрибә туплый.



– Шунысы кызык: хакатоннарда сезнең студентлар нинди проектлар тәкъдим итә?

– Мәсәлән, алар Идел буе халыклары AR-музейның уникаль экспозициясен эшләүдә катнаштылар (AR-өстәлмә чынбарлык технологиясе – ред.). Аның идеясе узган елгы Kazan Digital Week форумында туды.

Музейда аутентик көнкүреш әйберләре белән җиһазландырылган XIX гасыр авыл йорты экспозициясе торгызылган. AR-технологияләрне куллану экскурсиягә килүчеләргә бу артефактларны «җанландырырга», алар белән өстәлмә чынбарлыкта ярашырга мөмкинлек бирә.

Сүз уңаеннан, форум кысаларында кунаклар Казан мәдәният институты Инжиниринг үзәгенең Өстәлмә чынбарлык музее экспозициясе белән танышты, цифрлы технологияләр ярдәмендә Идел буе халыклары мәдәнияте турында ишетте.

Идел буе халыкларына багышланган AR-музейның уникаль экспозицияләре белән танышу.

– Цифрлы технологияләрнең гомумән мәдәниятќә йогынтысы турында сөйләшик. Бу юнәлештә нинди яңа мөмкинлекләр күрәсез?

– Мин технологияләр үсеше безгә мәдәниятне дә үстерергә мөмкинлек бирә, дип әйтер идем. Цифр еш кына мәдәни чынбарлыкны яхшырак белергә һәм аңларга ярдәм итә. Әйтик, өстәлмә чынбарлык технологиясенә таянып, шул ук AR-музей эшләгәндә детальләргә игътибар бирү студентларга аларны дөресрәк итеп ясарга, аларның милли тәңгәллеген сакларга мөмкинлек бирде. Ә традицион мәдәниятне саклап калу, аны киләчәк буыннарга җиткерү – бүген безнең төп бурычларның берсе.

– Цифр еш кына мәдәни чынбарлыкны яхшырак белергә һәм аңларга ярдәм итә. Әйтик, өстәлмә чынбарлык технологиясенә таянып, шул ук AR-музей эшләгәндә детальләргә игътибар бирү студентларга аларны дөресрәк итеп ясарга, аларның милли тәңгәллеген сакларга мөмкинлек бирде. Ә традицион мәдәниятне саклап калу, аны киләчәк буыннарга җиткерү – бүген безнең төп бурычларның берсе.

Технологияләр гомумән мәдәниятне сакларга яхшы ярдәм итә. Әйтик, без авыллар буйлап фольклор экспедицияләренә чыгабыз, халык традицияләрен саклаучыларның чыгышларын карыйбыз һәм тыңлыйбыз, боларның барысын да заманча аудио- һәм видеогаджетларга яздырабыз. Халык иҗатын гасырларга теркәп барабыз.

Ә мәдәни дөньяның һәркем файдалана алырлык булуы? Карагыз: Россия Мәдәният министрлыгының цифрлы платформаларында бүген бөтен илдән музей экспозицияләре, спектакльләр һәм концерт программалары куелган, һәм Россиянең теләсә кайсы ноктасында теләгән һәркем моны күрә ала. Әгәр дә сине нәрсәдер аеруча кызыксындырган икән, син моны тере килеш карау өчен кая барырга тиешлегеңне беләсең инде. Бу офыкларны бик киңәйтә.

– Ләкин монда җитди таләп тә бар: әгәр ул барысын да онлайн карый ала икән, кешегә өйдән чыгарга кирәкми...

– Әмма сан берничек тә тере аралашуны алмаштыра алмаячак, ә реаль чынбарлыкның җете буяуларын смартфон экраныннан гына

Казан мәдәният институты студентларының чыгышы – форум программасының алыштыргысыз өлеше.

бәяләп булмый. Һәм цифрлаштыру гасырында мәдәният эшлеклеләренең бурычы – тамашачы/укучы/тыңлаучы өчен яңа технологик мөмкинлекләрне һәм кешелекнең тере бағланышларын берләштерә торган звенога әверелү. Шулай булгач, без, теге яки бу күләмдә мәдәният өлкәсендә эшләүчеләр, бүген бик зур җаваплылык тоябыз.

Һәм төрле куркулар ни өчен миңа уйлап чыгарылган кебек тоелуы турында да әйтим: цифр бит мәдәнияттә күптән бар инде. Телевидение, радио, музыка аппаратурасы – болар барысы да технологияләр бит, арлар ярдәмендә мәдәният бөтенләй башка дәрәҗәгә күтәрелде. Һәм барыбер телевидение дә, кино да театрны кысрыклап чыгармады бит!

– Сезнең бүгенге студентларыгыз – цифрлы чорда үсүче буын. Алар белән эшләү авырмы? Алар, мәсәлән, хәзерге модага ияреп, курс эшләрен язганда GPT чатларын кулланалармы?

– Ел саен мин безгә нинди талантлы абитуриентлар килүен күрәм. Һәм алар цифрлы контент белән классик мәдәниятне бик яхшы яраштыра белә. Әлбәттә, мин укытучы буларак студентларның кайбер биремнәрне ясалма интеллект ярдәмендә башкарырга тырышуларын күрәм. Бу очракларда күп нәрсә педагогка бәйле. Без дә яшь чакта, укыганда хәйлә корырга һәм өй эшләрен җиңеләйтү ысулларын табарга тырыша идек. Ләкин яхшы укытучы һәрвакыт мондый омтылышны сизәчәк һәм ни өчен моны эшләмәскә кирәклеген аңлата алачак. Һәм, әлбәттә, бүгенге укытучы, яшьләрдән калышмыйча, яңа чынбарлыкта ориентлаша белер өчен даими рәвештә үзлегеннән белем алу белән шөгыльләнергә тиеш.

– Мин үземнең студентларым белән горурланам. Алар үз миссияләрен аңлый: халык мәдәниятен алга сөрү, тарихны белү, традицион кыйммәтләрне саклау. Без цифрлы технологияләрне традицион мәдәнияткә дөрес интеграцияли белүче яңа буын мәдәният хезмәткәрләрен әзерлибез, дип әйтергә була.

Ә гомумән алганда, без бит югары уку йортында зур тәрбия эше дә алып барабыз. Мин үземнең студентларым белән горурланам. Алар үз миссияләрен аңлый: халык мәдәниятен алга сөрү, тарихны белү, традицион кыйммәтләрне саклау. Без цифрлы технологияләрне традицион мәдәнияткә дөрес интеграцияли белүче яңа буын мәдәният хезмәткәрләрен әзерлибез, дип әйтергә була.

Казан мәдәният институты студентлары хакатонда.

КАЗАННЫ НИНДИ КУЛЛАР КОЧАКЛАР?

Дмитрий Сивков

Монументаль эшләре белән бөтен дөньяга билгеле Италия сынчысы, Татарстан мәркәзе белән илһамланып, чираттагы шедеврын тудырырга җыена.

ҮЗ СУКМАГЫҢ

Лоренцо Куинн белән очрашкач, табигать бөек шәхесләрнең балаларында ял итәргә ният корса да, моның сәбәбе бер генә була алуына инанасың: ата-аналары талантының колачыннан ялыккан булса гына. Әмма бу очракта һич алай түгел. Ике мәртәбә Оскар иясе, Голливудның атаклы актёры Энтони Куинн улы Лоренцо, әтисе канаты астында торып, инде әйбәт итеп салынган сукмактан гына да рәхәтләнеп атлый алыр иде, югыйсә.

Хәер, иң башта шулай иткән дә булган ул. Әмма тора-бара яшь егет барыбер үз сукмагын эзли башлый һәм таба да. Хәзерге вакытта күренекле Италия сынчысының эшләре дөнья галереяларында куела, коллекционерлар аларны үзләрендә булдырырга омтыла. Бу эшләр дистәләгән илнең урамнарын бизәп тора, аларны Рим Папасы үзе изгеләндерә...

МОНУМЕНТАЛЬ СӘНГАТЬНЕҢ ГЕОГРАФИЯСЕ КИҢӘЯ

Инде хәзер Россия, шул исәптән Казанга да бәйле рәвештә, Италия сынчысының монументаль сәнгате тагын да киңрәк колач алачак. Бу иҗади берләшүгә беренче адымнар 2024 елның 29 августында ясалды булса кирәк. Татарстанда беренче тапкыр ES Gallery иҗат мәйданында Лоренцо Куинн иҗатына багышланган күргәзмә эшли башлады.

Лоренцо әфәнде мәртәбәле вакыйганы үзе дә калдырмады – дөньядагы хәзерге хәлләргә карамастан, ачылышка килеп төште. Килер

Автор фотолары

ЭШЛӘРЕМНЕҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ КЕШЕГӘ АҢЛАЕШЛЫ БУЛА АЛУЫНА ЗУР ИГЪТИБАР БИРӘМ. КЕШЕ ҖӘМӘГАТЬ КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ КУЕЛГАН МИНЕМ ЭШЕМНЕ АҢЛАП КАРАРГА ТИЕШ ДИП УЙЛЫЙМ. МОҢА БАРЫ ТИК ТОЙГЫЛАР АША ГЫНА ИРЕШЕП БУЛА.

өчен рухлануы да шуннан булгандыр, бәлки. Чөнки, әйтүенчә, безнең барыбызны да нәкъ менә төп кеше ихтыяҗлары берләштереп тора. Асылда, аның эшләре әнә шул хакта.

КУЛЛАРНЫҢ УНИВЕРСАЛЬ ТЕЛЕ

Куинн беренче чиратта кеше кулларын гәүдәләндерүе белән билгеле. Ул аларны бөек көч һәм куәт билгесе дип саный.

– Минем эшләремне дөнья буйлап күргәзмәләргә куялар, шуңа да аларның һәр мәдәнияткә ихтирамлы мөнәсәбәттә булуы әһәмиятле. Кулларны бик еш файдаланам, чөнки алар универсаль телгә ия. Сынчы тудырган кулларга карап, аларның кайсы раса вәкиленә каравын белү мөмкин түгел. Картинада моны төс чагылдыра, ә менә сында – юк. Һәм бу үзеннән-үзе берләштерү көченә ия, – дип сөйләде Лоренцо күргәзмә ачылышында.

ШӘҺӘР БАШЛЫГЫНЫҢ ХЫЯЛЛАРЫ

Күргәзмәнең үзенә килсәк, биредә монументаль һәйкәлләрнең фотографияләре һәм өч скульптура тәкъдим ителгән. Аларны оештыручыларга үзебезнең Казан коллекционерлары биргән. Югыйсә, әлеге күркәм вакыйга булмый да калыр иде, чөнки хәзерге вакытта Европадан транспортлау һәм чик тикшерүе, таможня мәсьәләсендә катлаулылыклар җитәрлек.

Моның республикабыз мәдәни тормышында узгынчы гына вакыйга булмавына һәм алга таба нинди дә булса иҗади проектка йөз тотуына шулай ук дәлил бар: вернисажда Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова һәм шәһәребез мэры Илсур Метшин – икесе дә булды. Шәһәр башлыгы сынчыга мөрәҗәгать иткәндә, бу тоемлауларның нигезе барлыгын да исбатлады:

– Казан сезнең куллар тудырган объектлар белән бизәлергә тиеш. Бу – хыял. Без кунагыбыз шикелле мәтрлар янәшәсендә нәрсәгәдер өйрәнергә, омтылырга, ирешергә әзер. Лоренцо, яраткан шәһәребез сезне әле моңа кадәр булмаган иҗади ачышларга илһамландырыр, дип ышанып калабыз. Мин исә, бу хыял тормышка ашсын өчен, кулымнан килгән бар нәрсәне дә эшләргә әзермен.

ТОЙГЫЛАР ТУДЫРУЧЫ

Үзенең булачак эше хакында «Татарстан» журналына Лоренцо Куинн менә нәрсәләр сөйләде.

– Ни өчен сез күбрәк монументаль сәнгатькә йөз тотасыз?

– Ул миңа күпкә нечкәрәк, нәзберегрәк тоела, минем мәңгелек кыйммәтләр белән чын тойгыларга булган сусавымны канәгатьләндерә. Җәмәгать киңлекләрендә сыннары куела торган сынчылар, гадәттә, сәнгатьне бәяли белүчеләр өчен эшләми, ә гомумән – һәркем өчен дә. Шуңа мин эшләремнең теләсә кайсы кешегә аңлаешлы була алуына зур игътибар бирәм. Кеше килгән урынында минем эшне аңлап карарга тиеш дип уйлыйм. Моңа ничек ирешеп була соң? Бары тик тойгылар яссылыгында гына. Сездә ясалган баннерда мине «тойгылар тудыручы» дип атаганнар, бу сүзләр күңелемә искиткеч хуш килде.

– Сез үз иҗатыгызда ишарәләр теленә еш мөрәҗәгать итәсез, ул тәрҗемәсез дә аңлашыла торган универсаль тел дип санайсыз. Казан сезнең өчен нинди ишарә белән ассоциация тудырды? Булачак эшегездә нәрсә чагылыш табарга мөмкин? Мэр чыгышыннан соң, безнең шәһәрне иҗатыгыз белән сөендерәсез икәнен инде анык аңладык.

– Мин әле мондагы киңлеккә чумарга өлгермәдем, шуңа башымда нинди дә булса образ формалашуына юл куймыйм. Моңа әле вакыт та булмады. Махсус тартып китерелгән һәм ясалма уйлап табылган образлар кабул итү, тоемлау өчен зур комачаулык тудыра ала. Шулай да Казан өчен кызыклы булырдай бер идея инде бөреләнеп килә. Идея биредә зур игътибар бирелә торган өлкәгә карый – күрми торган кешеләрне укыту, өйрәтү, аларга ярдәм итү.

– Проектка керешкәнче, сез иң башта аңа поэма багышлыйсыз дип беләбез. Казан турында инде нииндидер юллар тудымы?

– Шәһәр, әйе, ниндидер тойгылар уятты. Ул – тарих һәм мәдәният үзәгендә, аның аша күпләгән бөек кешеләр узган һәм, әлбәттә инде, үз эзләрен калдырган. Сезнең мәркәздә, заманча тел белән әйтсәк, мәдәниятләр белән диннәрдән үзенә бертөрле, кабатланмас микс формалашкан. Монда Көнчыгыш та бар, Көнбатыш та, мөселман традицияләре дә, христианлык та... Болар барысы да үзара гармониядә яши, шигъри юлларга камертонны әнә шушы үзенчәлек бирер, ахрысы.

– Димәк, Казан сезне илһамландырды дип, инде хәзер үк әйтергә була?

– Әлбәттә!

Ә без, үз чиратыбызда, Лоренцога шәһәребез өчен тудырган иҗади эшендә илһам теләп калабыз. Чын мәгънәсендә уникаль сәнгать әсәре тусын иде, дип тә өстәп куйыйк. Казаныбыз моңа лаек, остасы да туры килеп тора.

«ИДЕЛ СУКМАГЫ»: ИҢ МӨҺИМЕ – БАШЛАРГА...

Сафа Гәрәев

Билгә кадәр үлән, болынның башны әйләндергеч хуш исләре һәм иксез-чиксез киңлек. Мин – «Идел сукмагы»нда, аның да иң башында, Чувашстан белән Татарстан чигендә. Акылга сыймаслык хыялга беренче адымнарны ясыйм: ниятем – сукмакны башыннан алып азагына кадәр узу. 350 километрны! Идел яры буйлап, Ульяновск өлкәсе чигенә чаклы. Йә, ничек сезгә мондый сәяхәт?

Беренче адым – җиңел түгел. Куе үлән арасыннан сукмакның башын табарга тырышам. Әмма мин басып торган урыннан – Парижга, Мәскәүгә, йә булмаса Нью-Йоркка күпме чакрым икәнен күрсәтә торган күрсәткечләр күренми. Мәзәкләвем генә, иң кирәклесе дә, ягъни «Идел сукмагы, нуленче километр» дигәне дә юк әле. «Зөя утрау-шәһәренә – 14 километр» дип ачыклык кертә торган язу да күзгә чалынмый... Икенче яктан карасаң, «Идел сукмагы»н салучылар аның үзенчәлеге дә шунда диләр: сукмак буйлап сәяхәтне теләсә кайсы ноктадан башларга була. Янәсе, бу актив ял итүнең иң кызыклы «фишка»ларыннан берсе. Шулай булгач, рәхим итегез, рәхәтен татыгыз бу «фишка»ның, дияргә генә кала!

Иң зур ярдәмче – «Идел сукмагы»ның офлайн-картасы. Аны смартфонга йөкләтеп аласың да карыйсың: Улитино авылыннан ерак түгел шау чәчәктә утырган болын ул – синең сәяхәтеңнең нәкъ менә нуленче километры икән. Дөрес, ничек кенә эзләсәм дә, куе үлән арасыннан мин ул сукмакны барыбер тапмадым. Шулай да кәефемне төшермим: болын исләре белән табигать хозурлыгы шунда ук безне, гадәти шәһәр бәндәләрен, эйфориягә чумдыра...

ГАЛӘММЕ? ЮК ЛА, КАРСТ!

Ә алда... якындагы гына куаклар челтәре аша гаҗәеп манзара ачыла: берәм-берәм тезелешкән күлләр җемелдәп тора. Картада аларны йолдызлар белән билгеләп чыкканнар, чөнки табигать һәйкәле исәпләнәләр. Менә беренчесе, картадан исемен эзләп карыйм – Собакино дип тамгаланган, алга таба – Провальное дигәне... Күл буенда туктап, ял итеп, хәл җыеп алырга да менә дигән мөмкинлек.

«Табигать һәйкәле», өйдәгечә, җанга рәхәтлек вә тынычлык бирә. Ыгы-зыгы, җәнҗаллар, зур сәясәт, проблемалар – барысы да каядыр еракта кала, әйтерсең, икенче планетада. Биредә – тынлык, камышлар, суда талгын гына дулкын чайпала... һәм тирә-юньдә бер генә җан иясе дә юк.

Берсен-берсе күзгә сыман кабатлаган, аралары нибары берничә адымны гына тәшкил

Фото: автор фотолары, Айдар Мөшәрәпов, Динә Әскәрова

иткән бу күлләр чылбыры фантазияне уйнатып җибәрә. Ә бәлки, болар кайчандыр галәмнән мәтәлеп килеп төшкән метеорит эзләредер? Чит планета вәкилләре һөҗүме нәтиҗәседер? Күлләр шулардан калган алагаем чоңгылларны тутырып утырадыр?

Кызганыч, фән боларның барысын да инкарь итә. Эт атамасын йөрткән күл дә, белешмәлекләргә ышансаң, карсттан яралган. Сулыкларның шулай чылбырлап урнашуы – мәкерле карстның җир өслеге белән ни кыла алуына аермачык күрсәткеч. Су аны акрынлап юып килгән-килгән дә, җир кинәт убылып төшкән. Чоңгыллар эченә мөлдерәп дулкын тулган. Шулай итеп, игезәктәй күлләр туган. Хәзер бу урыннар махсус саклана.

Сулыклар янында озаграк торсаң, хәвеф янамый микән дип тә шикләнә башлыйсың. Карстлы күлләрне ясауга табигать йөз елларга кадәр сузылган озын-озак вакытын сарыф иткәнне белсәң дә. Хәзер алар – элеккеге чорларның катаклизмнарын хәтерләтеп торучы истәлекләр, бернинди хәтәр белән дә янамый торган ядкәрләр.

Форсаттан файдаланып, җирле балыкчылар белән корган әңгәмәләрдән өземтә дә китерәм:

– Бәлки, сез хаклыдыр да, – дип, фәлсәфәгә бирелә агайлар. – Әмма, алай булгач, ник соң 2022 елда тагын яңа чоңгыл пәйда булды? Тикторган җирдән, кыр уртасында, кинәт аяк астыннан җир убылып китте. Убылган урында өч катлы йорт кадәрле чоңгыл хасил булды, диаметры утыз метрлап булыр...

Кызганыч, күлләр тирәсендә бернинди мәгълүмат тактасы да юк. Югыйсә, урыны – инде аңлагансыздыр – игътибарга һичшиксез лаек.

ШӘҺӘРЛӘР ҺӘМ ТАУЛАР

Алга таба юлыбыз – Карамалы тауларына таба. Күллләрдән кыска гына «марш-бросок» ясап, болыннан күтәреләсең дә таң калып торасың. Астагы манзараның матурлыгы! Бик еракта, тиз генә барып җитмәс арада булса да, кул сузымында гына шикелле тоелган Идел җәйрәп ята, аннан карашны алып булмый! Ә каршы якта, шулай ук уч төбендәге кебек, Яшел Үзән ялтырый. Бер читтәрәк – мариларның Волжск манзарасы. Сулдарак – Чувашстан. Берьюлы өч республиканы күреп була торган башка берәр күзәтү мәйданын беләсезме сез?

Бу манзарага хозурланып торган арада Идел өстендә очар коштай тирбәлүче парапланеристны абайлап алам: Карамалы таулары – ирекле очышларны үз итүчеләр өчен иң рәхәт урын. Әмма минем сәяхәт әлегә андый очышларны планга кертүне кирәк дип тапмый.

Акрынлап кына Идел яры буйлап чираттагы билгеле урынга юл алам – Щусев кәшәнәсенә. Ул Романовлар тимер юл күпере янында урнашкан. Күпернең үзенә кадәр әле өч километр ара булса да, моннан бик якын булып күренә. Ә тиз-тиз атлый башласаң, бер кырык минутлап вакыт китәр иде...

Юлым Түбән Карамалы бистәсе аша үтә. Авыл урамнарыннан бераз адашып йөргәч, ниһаять, каршымда балкып торган шпильне күрәм. Соңгы каршылык – биек, куе булып үсеп утырган чүп үләннәре. Алар артында – зифа колонналары, Питер Адмиралтействосы өстендәгене хәтерләткән биек шпиле, бизәкле хачы белән күзне җәлеп иткән өч яруслы кәшәнә...

Бу манзарага хозурланып торган арада Идел өстендә очар коштай тирбәлүче парапланеристны абайлап алам: Карамалы таулары – ирекле очышларны үз итүчеләр өчен иң рәхәт урын.



Менә ул – Щусев кәшәнәсе; зифа колонналар, өч ярус, биек шпиль, бизәкле хач...

бер сәеррәк әйбер дә очрый юлда – керә торган җирдәге постаментта калкып торган корылма.

Карап торам-торам да кинәт аңлап алам: «сәеррәк корылма» дигәнем – чын раритет ич! Бу Идел аша төзелгән иң беренче Романовлар тимер юл күперенең хәзерге буыннар өчен сакланып калган корыч аралыгы, ягъни детале. XX йөз башы инженерлык даһилыгының бер өлгесе, дисәк тә, һич ялгышмыйбыз. Әмма аны минем кебек узгынчы туристлар «танып алырга» сәләтлеме – менә монысы сорау, әлбәттә. Аз гына мәгълүмат язылган такта торса, шәп буласы – тимер раритет янында да, Щусев кәшәнәсе каршында да. Соңгысы мәдәни мирас объекты саналса да, белүчеләр саны күптер дип уйламыйм...

Алга таба юл алганчы, Романовлар тимер юл күперенә янә бер күз төшерәм. Моннан ул шулкадәр якын күренә. Үз вазыйфасын үтәгән корыч аралыкларын егерме ел элек алыштырдылар аның, әмма 100 ел эчендә ул шулай да әллә ни үзгәрмәде. Белмәсәгез, белегез: күпер дә – мәдәни мирас объекты. Адым саен – мирас та мирас монда, асылда.

ТРОЦКИЙДАН СӘЛАМ

Кәшәнәдән соң сукмак Түбән Карамалы буйлап Зөя утрау-шәһәренә алып төшеп китә.

ЩУСЕВ КӘШӘНӘСЕ. ТУАР ӨЧЕН – БЕР ГАСЫР

Беренче тәэсир: бинаның кыяфәтендә Казан вокзалыннан һәм әле тагын Кызыл мәйдандагы мавзолейдан да нидер бар... Сәер.

Хәер, нәрсәсе сәер булсын, кәшәнәне Алексей Щусев – башкаланың Казан вокзалын һәм Ленин мавзолеен төзегән архитектор проекты буенча торгызганнар ләбаса. Бәлки, шуңа да бу кәшәнә Россия империясе дәверендә төзелгән башка бер генә гыйбадәтханәне дә кабатламый торгандыр.

Әле ул, җитмәсә, рекордлар китабына кертелергә дә лаек икән. Юк, юк, архитектура формалары өчен түгел, ә төзелү датасы буенча. Аңа 1913 елда, династиянең 300 еллыгы уңае белән һәм Романовлар тимер юл күпере ачылу көненә тәгаенләп, тантаналы рәвештә нигез салына. 1914 елда кәшәнәнең беренче ярусы торгызыла, ә аннан сугыш, инкыйлаблар кайный башлый... Йөз елдан соң гына гыйбадәтханәгә кабат алыналар. 2017 елда аны төзеп бетерергә карар кылына. Йөз ел буе төзелгән тагын нинди кәшәнәне беләсез сез, йә? Төзеп бетергәндә, әйтергә кирәк, Щусев сызымнарыннан читкә тайпылмыйлар...

Кәшәнәгә илтә торган, вакыт җилләре җимереп ташлаган баскычның тупас ташына басып атлыйм – аңардан борынгылык бөркелеп тора. Штукатуркасы кубып, уалып торган диварлар белән колонналар менә, киресенчә, заманчалыгы белән җәлеп итә. Минем шикелле, нәрсәнең ни икәнен белеп бетермәгәнрәк адәмгә тагын



Вакыт җилләре җимереп ташлаган баскычның тупас ташыннан борынгылык бөркелеп тора.

Свияжск тимер юл станциясе яныннан узабыз. Ул безнең тарихта аерым урынны биләп тора. 1918 елда монда Лев Троцкий җитәкчелегендәге Кызыл Армия штабы урнашкан була. Дөресен генә әйткәндә, нәкъ менә шушы ноктада Гражданнар сугышының хәлиткеч борылышы була да инде. «Революциянең киләчәк язмышы Казан белән Свияжск арасында бәргәләнгән мәлләр ул, – дип яза Троцкий. – Иделдән кала, чигенер урын юк... Агитация, оештыру эшләре, революцион үрнәк һәм репрессияләр нәтиҗәсендә, берничә атна эчендә тиешле борылышка ирешелде. Тотрыксыз, таралырга гына торган халык массасыннан чын мәгънәсендә армия оешты».

Йөз ел эчендә булган иң әһәмиятле вакыйгаларны теркәп калдырган истәлекле стеланы укыйм – ул станция янында урнашкан. Асылда, бу – нәни генә юл күрсәткече, бар да анык, кыска һәм төгәл язылган. Троцкий штабы турында да бар мәгълүмат, Түбән Карамалының кайчан нигезләнүе турында да, 1942 елда шушыннан атаклы Идел рокадасы башлануы турында да. Сталинградка илтүче тимер юл үз вакытында рекордлы срокларда төзелә һәм Сталинград сугышының чишелешен хәл итә.

Станциядәге истәлекле стела – мәгълүмати маркерларның үрнәге, дисәк тә була. Идел сукмагының иң әһәмиятле урыннарында андый такталар бер дә комачауламас иде. Кызганыч, мин юлымда аларны очратмадым...

БЕРЕНЧЕ АДЫМ СОҢГЫСЫ ТҮГЕЛ

Ул арада сукмак алга дәшә – Зөя утрау-шәһәренә. Карамалы борылышыннан соң ук, иксезчиксез сулыклар белән каймаланган болыннар күз алдына килеп баса. Үләннәр кайнап тора. Вак сулыклар, күлләр һәм инешләр – адым саен... Маршрутның соңгы километрлары гүяки Амазонка елгасы бассейны аша сузыла, ләкин безнекендә, шөкер, елгалар елан белән мыжлап тормый да, үтеп булмаслык джунглилар аркылы ятмый. Ниһаять, алдыбызда Зөя пәйда була. Минем маршрутның азаккы ноктасы. Беренче нәтиҗәләр чыгарыр урын.

Шулай итеп, беренче нәтиҗә. Сукмакның башыннан алып Зөя утрау-шәһәренә кадәрле 14 километрны, чыннан да, җәяүләп узарга кирәк. Түккән көчең дә, вакытың да үкенерлек түгел. Арыйсың, билгеле, уңайсызлыклар да хәлне ала, әмма күз алдыңда ачылган манзаралар – моны берни белән дә чагыштырып һәм алыштырып булмый. Идел ярлары, карст күлләре, Щусев кәшәнәсе... – нибары дүрт сәгать эчендә никадәрле тойгы-кичерешләр.

Икенче нәтиҗә. Узган юл арасы – ул әле, асылда, формалашып өлгергән сукмак түгел, ә нибары эскиз. Маршрутның башы, аның озынлыгы, ориентирлар, мәгълүматны туплаган төп «ачкыч-нокталар»... – тиешле күрсәткечләрдән башка, тулыканлы туристик сукмак турында сүз алып бару иртәрәк булыр. Шулай ук икенче бер таләпне дә искә алмыйча ярамый: туристик

маршрутта иң кирәкле әйберләр куелган ял итү урыннары булырга тиеш. Самара өлкәсендә безнекеннән соң соңрак пәйда булган җәяүле сукмакта, сүз уңаеннан, боларның инде барысы да бар.

Шулай итеп, беренче мәртәбә узучы буларак юлыккан кыенлыкларны исәптә тотып, «Идел сукмагы»ның перспективалары, киләчәге хакында уйланам. Ә ул киләчәк, маршрутның кабатланмас йөзе булган шикелле, якты һәм матур булыр, дип ышанасы килә. Менә, сукмак башланып киткән җирдә истәлекле билгесе тора, анда бөтен кирәкле мәгълүмат теркәлгән. Шунда ук, старт ноктасында, сәяхәтченең кабатланмас регистрация номерын да алып була. Үз өлешеңне үткәннән соң, аны үтүең турында документаль рәвештә раслау килә. Компьютер программасы маршрутка чыгучылар узган километрларны җентекләп терки, исәпли бара, сукмакны тулаем үтеп чыккан затларга Мактау таныклыгы белән истәлекле бүләк тапшырыла. Ә бәлки, хәтта Бөек Болгарга призлы тур да... Әгәр мондый төр хуплау билгеләре белән бүләкләр күздә тотылса, «Идел сукмагы»ннан узарга омтылучылар саны бермә-бер артыр иде, миңа калса.

Хәер, монысы – бары тик минем фантазия генә. Әлегә мин ирешкән төп казаныш – «Идел сукмагы»ның башлангыч чакрымнары. Финишка инде әллә ни күп тә калмый, саный башласаң, бары тик – 336 километр гына! Нишлибез, дәвам итәбезме?

«ИДЕЛ СУКМАГЫ» –Татарстан территориясе буйлап уза торган, Чувашстан чигеннән Ульяновск өлкәсе чигенә кадәр сузылган җәяүле туристик маршрут. Сукмакның төп трегы озынлыгы – 284 километр. Кайбер маршрутларның әйләнмәле булуын һәм радиаль рәвешен исәпкә алып санасак, якынча 350 километрга җитә. «Идел сукмагы» үз эченә 100 дән артык тарихи һәм мәдәни мирас объектын ала, шулай ук – 26 махсус саклана торган табигать территориясен дә.
Сукмак буйлап сәяхәтне һәркем теләгән ноктасыннан башлый ала. Нинди озынлыктагы маршрутның үзенә кулай буласын да, никадәр юл узасын да һәркем үзе сайлый.

АВЫЛЧА ЯЛ

Руфия Фазылова

Шәһәр баласы өчен авыл ул – ял итү, ягъни төш вакытына кадәр йоклау, аннан торып, табигатькә хозурлану, дәү әнисе пешергән тәмле ризыкларны ашау... «Без авылга кайтырга җыенабыз әле», – дигәч, аларның йөзе яктырып китә. «Вәт сезгә рәхәт: чиста һава сулыйсыз, табигый ризык ашыйсыз», – ди алар. Бу вакытта син серле генә елмаясың, чөнки күз алдыңа бөтенләй икенче картина килеп баса.

Минем өчен авыл ул – иртәдән кичкә кадәр эш. Иң гаҗәбе һәм кызыгы – ул гомергә шулай кала икән. Авылдан киткәнгә егерме елдан артса да, һаман эшкә дип кайтабыз.

ЕЛГА БЕР... ӨЙ ЮУ

Җәен авылга ешрак кайтыла, башта бәрәңге утыртасы бар, аннан өясе, шуннан печән өсте башлана... Кыскасы, бер ял да «бушка» узмый. Ә минә отпуск, ягъни озын ялларның – үз планы. Чираттагы ялга да шулай исемлек белән кайттым.

Авылда электән килгән гадәт бар – өй юу. Күбрәк ул язын эшләнә. Тик без соңгы елларда җәй уртасында гына юабыз, чөнки көннәр эссе тора. Ә бу урын-җирне, киемнәрне чыгарып киптерү өчен бер дигән форсат. Тырыша торгач, бер атна ялның өч көне шушы мәшәкатьләр белән узып китте. Өй юу ул сиңа шәһәр фатирын сөртеп чыгару гына түгел. Башта агач бүрәнәләрнең һәрберсен мунчала белән ышкыйсың, аннан соң чүпрәк белән сөртәсең. Ә иң авыры – түшәмен юу. Гел өскә күтәреп эшләгәнгә күрә, куллар бик нык ара.

Тукта, ничектер гел зарлану кебегрәк бу. Өй юуның үз күңеллелекләре дә бар, әлбәттә. Беренчедән сиңа мулдан табын әзерлиләр. Өй юучыларны шулай элек-электән сыйлаганнар. Әни миңа да тәмле камыр ашлары пешергән иде. Икенчедән, сиңа дип атап ягылган мунча. Эш бетүгә, башта парлы мунчага китәсең. Шунда җимешле чәйләр эчә-эчә хәл аласың. Өченчедән, өй юган көнне син сабый бала кебек йоклыйсың. Ни өчен дигәндә, агач бүрәнәләр сафланып киткән була, өйгә гайре бер татлы ис тарала. Андый ис елга бер генә, нәкъ менә өй юганда гына барлыкка килә. Татлы йокының тагын бер сәбәбе, әлбәттә, ару да. Көне буе тыз-быз йөргәнгә, урынга ятуга, эреп кенә китәсең.

КЫШКА ЗАПАС

Хуш, өй юу мәшәкатьләре бетте. Тик әле челтәр, чаршауларны үтүкләп куяр өчен тагын ярты көн кирәк. Ә ул арада әти керде:

– Бакчада кыярлар өлгергән, картаеп ята инде, кызым. Тозлап алмыйсыңмы?

Әти моны аеруча бер гаҗизлек белән әйтте: аның хезмәте бит. Җәй буе тырышып үстергән кыяр, помидорың әрәм булып ятса, сүз дә юк, борчыла башлыйсың. Гомергә шулай. Шуның

Фото: Лилиана Вәлитова

өчен дә кышка банка ябу гадәте бездә һаман да яши. Кайбер елны базда бәрәңге куярга да урын калмый. Әле бит кайнатмалар да бар. Соңгысы – әни җилкәсендә, җиләк-җимеш өчен ул җаваплы.

Банка ябу эше күңелемә бик хуш килә. Хәер, ашарга да яратам. Җәен авылда япкан банкаларны кыш буе ашыйбыз. Банка ябу сезоны июль аенда кыяр тозлау белән башланса, октябрь аенда помидордан төрле салатлар ясау белән төгәлләнә.

Кыскасы, ялның дүртенче көне банка ябу эшләре белән узды. Әти теплицадан берничә помидор да алып кереп бирде: яшеллекызыллы банкаларны капкач ягына әйләндереп куйдым. Эх, рәсемдәге кебек бит!

БАЛАЧАККА КАЙТУ...

Авыл иртә уяна. Ул гомергә шулай иде. Иң беренче сине әтәч уята (җәен тәрәзәләр ачык, барысы да ишетелеп тора). Әти белән әни аяк өстендә булгач, җиделәр тулып киткәч син дә торасың. Әлеге дә баягы, һәр көннең үз планы:

– Кызым, бүген шул кура җиләген җыеп кайнатыйк инде! Вак булса да, кура җиләге күп быел.

– Ярар, әни...

Бик эсселәр башланганчы, урамдагы эшләрне төгәлләргә ашыгасың, шул исәптән кура җиләге җыюны да.

Нигездә, авылда, халык уникедән сәгать икеләргә кадәр бакчага чыкмый тора. Кемдер өендә черем итеп алырга мөмкин, кемдер тәмләп чәен эчә. Ә безнекеләр өчен ул газета-журналлар уку вакыты. Әти, диванга кырын ятып, газетаны кычкырып укый, әни исә кроссворд чишә. Һәм бу күренеш көн дә кабатлана. Бер атна авылда яшәү дәверендә моңа шулкадәрле ияләндем, балачакка кайткандай булдым...

Көндезге икеләр тулып киткәч, әни чәй кайната. Бу инде кичке эшкә чыгар алдыннан шулай бер җыелып чәйләп алу.

– Мин хәзер үгезгә печән чабып киләм. Син, кызым, чебиләрне ашат, – ди әти, миңа борылып.

– Ярар, әти...

«КИЧ УТЫРЫРГА ЧЫК!»

Туган авылым – Апас районы, Олы Бакырчы. Зур авыл. Капиталь төзекләндерү уздырылган ике катлы мәдәният йорты, төп белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы бар. Юлларга асфальт яки таш җәелгән. Бердәнбер проблема – яшьләр юк. Һәм бу нык сизелә. Без үскәндә

урам тулы халык иде. Хәзер ара-тирә генә кеше узып китә. Кичләрен аеруча аптырыйсың – авыл тып-тыныч, капка төпләре дә буш. Шулай да без, элеккеге гадәт буенча, кич утырырга чыктык. Рәхмәт, күршем Рушания апа алып чыкты:

– Инде китәр вакытың җитә, һаман бер кич утырмаган. Бүген әбизәтелне чык.

Чынлап та, узган ел көн саен диярлек кич утырдык. Быел әллә вакыт булмады, әллә теләк шунда. Кыскасы, Рушания апа белән капка төбендә күрештек. Безне күреп, сул якТагы күрше Рифат абый да чыкты.

– Ай-яй, өйдә нәрсә генә эшләп ятасыз? – дип шелтәләп алды ул.

Әнә шулай өчәүләп кызык хәлләр сөйләшеп, көнбагыш ашап, шактый утырдык. Урамнан узучылар да туктап ала. Авыл кешесенең сөйләме кызык инде: «Чебиләреңне суйдыңмы?.. Балалар кайткан иде, ике бакча печәнне керттек... Эх, яңгыр юк бит, яңгыр. Бәрәңгеләр күтәрелеп китәр иде... Наилләр җиләккә барганнар, Шайтан күлендә еланнар күп икән. Ул якка бара күрмәгез...»

Әйе, авылның үз борчуы, үз шатлыгы. Монда риясызлык, монда иркенлек, монда гадилек...

БҮГЕН – КОНЦЕРТ

Шулай итеп шимбә дә килеп җитте. Мәдәният йортында бүген концерт була, яшьләр концерт куя. Минем кызлар да катнаша. Мәдәният йорты җитәкчебез Ландыш Моталлапова, авыл балалары белән кайтучыларны бергә җыеп, концерт әзерләде. Шуның өчен дә бу кичкә план алдан ук әзер иде.

Иң беренче шуны әйтим: авыл баласы өчен клуб сәхнәсе ул – музыка мәктәбе дә, театр түгәрәге дә, бию секциясе дә. Һәм ул канат куючы, синең сәләтеңне ачарга, аны үстерергә ярдәм итүче урын да. Без шулай үстек. Шуның өчен авылның мәдәният йорты күңелгә бик якын.

Бу урында бер фикер белән бүлешәсем килә: балалар куйган концертларга еш йөрим, чөнки игезәк кызларыбыз музыка мәктәбендә укый. Һәм, анда баргач, гел бер нәрсә күзәтәм: балаларның йөзендә курку. Роботлар кебек чыгалар да, уен коралында уйнап, җырлап кереп китәләр. Аның сәбәбе бик гади: музыка мәктәбендә укытучы аларны техник яктан дөрес уйнарга, ноталарны дөрес җырларга өйрәтә. Хата ясасаң, бетте баш. Һәм концерт вакытында балаларның максаты бер генә: дөрес уйнарга, дөрес җырларга. Читтән караганда, бик күңелсез күренеш бу, җитмәсә, минем кебек музыкаль белеме булмаган кешегә. Миңа дисә, әллә ничә хата ясасын, тик баланың йөзендә - нур, күзендә очкын булсын.

Ә менә Олы Бакырчыда узган концертта балалар чәчрәп торды. Ирексездән, аларга кушылып җырладык, кул чаптык. Үз кызларыма да ис китте: үзлекләреннән инглизчә җыр өйрәнделәр, скрипкада әллә кайчан уйнаган көйләрен искә төшерделәр. (Гадәттә, укытучысыз өч нота да уйнамыйлар иде.) Ә монда барысын да үзләре хәл итте. Һәм һәр бала мөмкин кадәр шулай үз сәләтен күрсәтте. Шуның өчен дә концерт җылы, самими килеп чыкты. Әлбәттә, профессиональ яктан ул җырбиюләргә сораулар бардыр, тик бу очракта баланың сәхнәдә ачылуы кыйммәтрәк, минемчә.

– Бу балалар үзара шулкадәр дуслашты, барысы бергә җыелып бетмичә, клуб эченә дә кермәделәр, – диде концерттан соң Ландыш апа.

...Физик яктан нык арылса да, рухи яктан син авылда ял итәсең. Һәм туган нигездә күпме озаграк торасың, шуның кадәр киткәндә авыррак була. Туган авылның аңлатып булмый торган бер тарту көче бар. Быелгы җәйге ялымда моңа янә бер кат инандым.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Гаилә хәзинәләре турында сөйләшү **кайда** булды

Куркулар **кайдан** килә

Милли премиядә **нинди** китапларга өстенлек бирелә

Шәмәк авылы **нинди** уй-ниятләр белән яши

ТИРӘНГӘ КҮМӘРГӘ ЯРАМАГАН ХӘЗИНӘ

Россия ислам университеты мөгаллимәсе Оксана Бирюкова кешелекне саклый торган бердәнбер чын мәгънәсендә үтемле чара – гаилә һәм безнең кешеләргә Көнбатыш «гамәлләренең» ни дәрәҗәдә ят булуы турында.

КҮМӘРГӘ ЯРАМЫЙ ТОРГАН ХӘЗИНӘ

«Ә нәрсә ул – гаилә кыйммәтләре? – дип сорады миннән шулай берсендә өченче сыйныф укучысы. – Ул нәрсә, гаиләнең хәзинәсеме әллә?»

«Ә бит чынлап та шулай, – дип, кинәт яңгыраган сорауга гаҗәпләндем мин, – ярату, кадерләү, якын кешеләрнең бер-берсен хуплавы, ярдәмләшүе. Бу – хәзинә һәм аны берничек тә тирәнгә күмәргә ярамый, ә җылысын, яктысын һәрдаим, бигрәк тә тормыштагы иң моңсу-күңелсез чакларда тоярга кирәк».

ФӘННИ КӨЙЛӘНЕШ

Мин быел 20 августта студентларым белән ел да уздырыла торган «Болгар мәдәният диалогы: замана яшьләре кыйммәтләре системасында гаилә» VII Халыкара җәйге мәктәбенә бардым. Барыбызда да – «фәнни көйләнеш»: безгә тематик чыгышлар ясарга кирәк иде. **География күзлегеннән караганда, бу – бик тә мәртәбәле чара.** Быел мәйдан үзенә искиткеч күп, кызыклы спикерларны җыйган иде. Алар Судан, Һиндстан, Палестина, Йәмән илләреннән килгән. Шәһәрләр дә бик күп: Дербент, Владикавказ, Бишкәк, Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан һәм, әлбәттә инде, Болгар үзе. Дин әһелләре, мөфтиләр, ислам уку йортлары ректорлары, этнографлар, сәясәт белгечләре, студент яшьләр оешмалары вәкилләре – зур ихтирам уята торган дәрәҗә.

ЧЫН ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ НИГЕЗЛӘНГӘН

Традицион диннәрдә гаилә һәм аның чын кыйммәтләре турындагы фикерләрнең охшашлыгы, туры килүе хакында күп сөйләнде, шулай ук гаиләнең, ихтимал, кешелекне, аның үсешен саклап калырга сәләтле бердәнбер чара булуы хакында да. Бездә яшәүче кешеләргә Көнбатыш «гамәлләре» килешми – боларны да исәпкә алырга кирәк: икесе дә бер җенестән булган парлар, ягъни ата-ана 1 һәм ата-ана 2 дигән бүленешләр, өч яшеннән баланы җенесен сайларга өндәүләр.

ИРТӘГӘНЕ ХӘЗЕРГЕБЕЗ ХӘЛ ИТӘ

Яңа заман килә, диде спикерларның берсе. Хәзер кешелек яшәешенең яңа кануннарын формалаштырырга омтыла, ул бүген нинди кыйммәтләрне сайлауга карап, кешелекнең иртәгәге көне – киләчәк язмышы да хәл ителәчәк. Соңгы утыз ел эчендә җәмгыять, ничек кенә кызганыч булмасын, безгә ата-бабалалар калдырган бик күп кыйммәтләрне җуйды. Яшьләрнең, мисал өчен, бер шәһәрдә Мәңгелек утка куеп сосиска кыздыруы – әнә шул өзеклек нәтиҗәсе. Бүгенге көндә гаилә – җәмгыять аның тирәлегендә төзеләчәк иң кыйммәтле үзәк ул. Икенче бер спикер әйткәнчә, «шәхси берәмлек җәмгыять бөтенлеген корырга ярдәм итәчәк».

КИБЕРИСЛАМ ҺӘМ ЯШЬЛӘР

Күренеп тора: бүген иң зирәк акыллы, белемле кешеләр җәмгыятькә кыйммәтле мирасын, байлыкларын саклап калырга ничек ярдәм итәргә икән дип уйлана. Бу мәсьәләдә кешелек искиткеч оешып бердәмләште.

Мәсьәлә башкада – әлеге мирасны саклар һәм тиешенчә куллана белер өчен үтемле юлларны ничек табарга? Болгар җәйге мәктәбендә гамәли тәҗрибә белән дә җитәрлек уртаклаштылар. Мисал өчен, РФА Уфа федераль тикшерену үзәгенең Р.Г. Гузеев исемендәге Этнология тикшеренүләре институты дин белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Зилә Хәбибуллина гадәти булмаган бер темага тукталды – «Киберислам һәм яшьләр: диннең цифрлашуы шартларында традицияләрне яңадан күздән кичерү».

Фото: Александр Ефремов

Бер яктан караганда, Хаҗ сәфәренә виртуаль рәвештә бару яки онлайн гына дуага заказ бирү – болар ислам кануниятенә сыймый һәм ярашмый шикелле, ә икенче яктан сорау туа: алай булгач, цифрлашу мөмкинлекләрен ничек дөрес итеп файдаланырга соң? Бу, асылда, яшьләрне җәлеп итү һәм дингә тарту, үзара элемтәләрне ныгыту өчен искиткеч куәтле ресурс. Уйланырга урын бар. Интернет белән мессенджерлар гаять әһәмиятле кыйммәтләрне җиткерергә ярдәм итә, аларны дөрес итеп кулланырга өйрәнергә генә кирәк – моның шулай булуы хакында Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе Диния нәзарәтенең яшүсмерләр мохитендә осталык буенча ярдәмчесе Мәрьям Кожевникова да ассызыклады. «Яшүсмер дөньясы» онлайн-мәйданчыгы мисалында. Мәйданчыкның бурычы (ул интерактив телеграм-канал) – ата-аналарга балаларны тәрбияләү мәсьәләсендә ярдәм итү. Бала тәрбияләгәндә һәм үстергәндә ата-аналарга җиңел генә булмый бит, сораулар бихисап: белгечләр бирә ала торган мәгълүматны каян эзләп табарга, үз балаларың белән элемтәне ничек югалтмаска, бигрәк тә алар катлаулы үсмерлек чорына кергәндә?

ГАИЛӘНЕ – «РОССИЯ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕ НИГЕЗЛӘРЕ»НӘ

Гуманитар фәннәр Дәүләт академик университетының юридик факультеты дәүләт һәм хокук кафедрасы мөдире, юридик фәннәр кандидаты Юлия Ерохина безгә **«Россия дәүләтчелеге нигезләре» дисциплинасын укытканда уку программасына гаилә кыйммәтләрен өйрәтү темасын ничек кертеп җибәреп булуы хакында сөйләде.** Соңыннан катнашучылар өчен мастер-класс та уздырды. Хәтта рәсем ясау аша да балаларга, шул исәптән олыларга да гаилә кыйммәтләре турында бик күп файдалы мәгълүмат бирергә мөмкин булуын исбатлады ул.

Россия Ислам университеты студенты Эльза Минашева аерым үрнәкләр мисалында ММЧ аша акыллы, игелекле һәм мәңгелек кыйммәтләрне яшьләргә ничек таратырга мөмкин булуын раслады. Яшьләр гаилә турында тыңларга, ишетергә, кабул итәргә әзер, диде ул.

КИТАПЛАР – ЯРДӘМГӘ

Мин үзем бүгенге көндә без иҗат иткән китаплар аша ана булуның горурлыгы һәм гаилә коруның әһәмияте турында сөйләргә булдым. Яшьләр асылда китапларны күп укый, аларга «ярдәм итә алырдай» китап кына кирәк. Без андыйны тәкъдим итә алабызмы?

Боларның барысы да – файдалы эшләр, алар кирәкле һәм үз вазыйфасын үти. Моны чыгышлар раслады. Инде алга таба дәвам итәр өчен вакытны дөрес исәпләргә һәм дикъкатебезне генә җуймаска кирәк.

Казанга без әчке бер рәхәтлек тойгысы белән кайттык: фәнни тикшеренүләр, тәҗрибә уртаклашу бик күп кызыклы мөмкинлекләр барлыгын күрсәтте. Һәркем үзе турында уйлады, башка шәһәрләрдән килүчеләр белән аралашып, нәрсә эшли алуы хакында фараз кылды. Чынлап та, без һәммәбез җәмгыять биш елдан соң яхшырак булсын өчен, үз өлешебезне кертә алабыз. Гаилә елында гына түгел, ә ел саен. Ә бу бит киләчәкне билгели.

КУРКУ НӘСЕЛДӘН КҮЧӘ

ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы эзләү-коткару хезмәтенең беренче психологы, үз практикасын булдырган белгеч Гүзәл Маринина бүгенге шартларда психологик киеренкелекләр, стресс һәм борчуларны ничек җиңү хакында фикер йөртә һәм «үзеңне синең өчен яратырга» өйрәтә.

ТРИГГЕР КАЙЧАН ЭШЛИ БАШЛЫЙ

– Миңа ирләре, уллары һәм ир туганнары махсус хәрби операция зонасында булган хатыннар, аналар, апа-сеңелләр еш мөрәҗәгать итә. Алар минем яныма үзләрен гаепле тоеп һәм курку хисеннән интегеп килә. Яраткан ир-атларын сугышка озаткач, алар яшәүдән туктаган кебек була: үз хисләрен тыеп, эчкә бикләп, гел кайгылы хәбәр көтеп яши башлый. Бу да – бәйлелекнең бер төре. Аңа анда начар икән, мондый авыр вакытта минем дә шатланырга, театрга йөрергә, матур киенергә хакым юк һ.б. дип фикер йөртә башлыйлар. Алар үзләрен сугыштагы хәлләр өчен рухи яктан җаваплы саный башлый, якыннарын пулялар астына үзләре кертеп җибәргәндәй борчыла. Кайберәүләр тирән депрессиягә бирелә, икенчеләр асоциальгә әйләнә – балалары, якыннарына каныга. Безнең сугыш, оккупация, блокада кичергән әби-бабаларыбыздан ДНК геннары дәрәҗәсендә күчкән нәсел травмасы хәрәкәткә китерелә. Галимнәр әлеге күренешне «эпигенетик нәселдәнлек» дип атый. Тискәре мәгълүмат әйләнә-тирәдә киеренке халәт туганчы безнең эчтә яшеренеп утыра да, аннары триггерны эшләтеп җибәрә: паника, якын кешеләр һәлак булудан курку башлана. Кайвакыт минем яныма сугышта беркеме дә булмаган, якыннарын югалтмаган хатын-кызлар да килә, әмма аларның курку хисе шулкадәр көчле ки, ул аларны яшәү шатлыгыннан мәхрүм итә.

«БАРЫСЫ ДА БЕТТЕ!»

– Әлеге травма әйләнә-тирә чынбарлыктагы бөтен негативны күрергә мәҗбүр иткәндәй була. Бүгенгедәй хәтерлим, мобилизация башланган көнне «Барысы да бетте» дип курыккан хатын-кыз белән эшләргә туры килде. Сөйләшү барышында аның әнисенең кайчандыр оккупациягә эләгүе ачыкланды. 7-8 яшьлек кызны колонкага су алырга җибәрәләр. Чиләкләрен тутыра гына, бомбалар ява башлый, бала куркудан алны-артны карамый йөгерә, аның артынан бомбалар шартлый бара. Шок хәлендә кыз бик биек койманы сикереп кенә үтә. Әлеге эчке травма һәм шок аның аң төпкелендә «язылып» калгандай була, курку нәселдән нәселгә тапшырыла һәм беренче тискәре вазгыятьтә үк башын күтәрә. Мондый кешеләр белән эшләгәннән соң, еш кына алар озак йокыдан уянгандай була, тынычлана, киләчәккә өмет белән карый башлый.

ТРАВМА АВАЗЫ

– Кайберәүләр мондый кешеләргә яңалыклар карамаска кирәк, дигән фикердә. Әмма тыеп кына бернәрсәне дә үзгәртеп булмый. Травма бар икән, аның авазы да бар, шуңа йә социаль челтәрләрдә начар яңалыклар күзгә ташлана, йә фаҗига кичергән кешеләр очрый. Мондый мәгълүматны даими табу ихтыяҗы туа. Әмма бермәлне түземлек төкәнә. Миңа кайвакыт үзен соң чиккә кадәр тилмерткән кешеләрдән мондый хәбәрләр килеп ирешә: «Ярдәм ит, зинһар, башка түзәр хәлем юк», – дип яза алар.

Нәтиҗәнең уңай булуына ышанучыларга дәвалану булыша. Әмма күп кеше психологларга ышанмый, җәмгыятьнең бер өлеше психологияне эзотерика һәм магия белән бутый. Психология дә төрле була, мин аның каты авыртудан сихәтләндерә, яшәүгә өмет уята торганы яклы. 24 ел буе психолог булып эшлим, шуның 20 елында классик ысулларны кулландым һәм авыруларның күпмедер вакыт үткәч кабат шул ук проблемалар белән килүенә бик борчыла идем. Һәр психологның үз стратегиясе бар. Мәсәлән, кечә бер ханым яза, минем киңәшләрдән соң үткән алты ай эчендәге үзгә-

Фото: Александр Ефремов. Иллюстрация: Джон Кенн Мортенсен «Фобии»

решләре хакында сөйли. Аның ире – абьюзер, әбисе – теләсә нәрсәгә бәйләнүчән тынгысыз карчык. Бу ханым мең кадәр ике ел буе төрле психологларга йөргән, файдасы гына тимәгән. Сөйләштек, аңлаштык, проблеманың асылын ачыкладык. Шуннан соң ире аңа, син үзгәрдең бит әле, әйдә аңлашыйк, дип үзе сөйләшергә тәкъдим иткән, гаилә сакланып калган. Әбисенә дә каршы әйтә алган. Моны көтмәгән карчык хәтта сүзсез калган.

КИЛӘЧӘК ТОРМЫШКА ВЕКТОР

– Үзеңдәге курку хисен үзең генә баса алмыйсың. Әмма бөтен катлаулы халәтләрнең нигезендә нәкъ менә шул курку ята, психик чирләрнең 90%ы, төрле бәйлелекләрнең 90%ы – эчке травма ул. Аннан котылу өчен, кеше эчә, наркотик куллана, комарлы уеннар белән мавыга башлый. Моннан 22 ел элек тренингка ВИЧ-инфекцияле ике наркоман улы булган хатын-кыз килгән иде. Үзенә сөйләргә чират җиткән саен күзе яшьләнә дә: «Мин сөйләмәсәм ярыймы?» – ди. Ике тапкыр шулай булды, аннары гына ачылып китте, сөйли алыр хәлгә җитте. Тормышы үзгәрә башлады, ике улында да тотрыклы ремиссия сакланып, икесе дә гаилә корды. Ә бит ул чакта, 22 ел элек, кешегә туйганчы елау һәм туйганчы сөйләү мөмкинлеге генә бирергә кирәк иде. Һәм – киләчәк тормышка вектор билгеләргә.

ГОМЕРЛЕК КОТКАРУЧЫ

– Мин гомерем буе – коткаручы. Балачактан сеңлем белән коточкыч шартларда яшәдек – әти-әниебез эчкече иде, шунлыктан икебез дә бик иртә өлкәнәйдек. Мондый эчке травма белән яшәве бик кыен булганга, психолог һөнәрен сайладым, башта үземә, аннары инде башкаларга да эчке гармонияне сакларга булыша башладым.

Ә ничек сакларга соң аны? Моның өчен башта сәбәбен ачыкларга кирәк. Яңа гына булган стресс халәтләрендә травмага «әйтү хокукы» бирү зарур, ягъни кешегә эчен бушату, беркем дә комачауламаслык урын табып, туйганчы кычкыру файдалы. Әгәр моны стресстан соңгы 48 сәгать эчендә эшләмәсәң,



травма эчкә китәчәк, депрессиягә, чирләүгә китерәчәк. «Бу куркыныч түгел», «барысы да үтәр» дигән юату сүзләреннән бер файда да юк, алар әрнүне тәнгә сеңдерәчәк кенә. Сүз уңаеннан, травмалардан котылу өчен сулыш, бию, рәсем ясау практикалары бик нәтиҗәле.

Рәсем тренингы ысулы да бар. Бер бит кәгазь алып, шунда үзеңнең стрессны сурәтләргә кирәк. Аннары ул «картинаны» ертып ташлап, позитив рәсем ясала. Әгәр рәсем киндер яки картонда акрил буяулар белән ясалса, аның өстеннән яңасын, тормышыбызда үзебез күрергә теләгән картинаны сурәтләү сорала. Бу бик гади һәм еллар буе сыналган техника. Мин дә аны үз эшемдә еш файдаланам.

ЯРАТЫРГА КИРӘК!

– Еш кына яшьләр өлкән буыннан зарланыр өчен килә. Шундый кешеләр бар: аларның балалары эчкече дә, наркоман да түгел, беркем дә чирләми дә, үлмәгән дә, сугышка да китмәгән, әмма алар һәрвакыт психоз халәтендә була. Һәм шулкадәр җенләнәләр ки, аларга каршы бер сүз әйтергә дә ярамый, бөтен гаиләне куркытып торалар. Ничек булышырга? Берничек тә. Өлкән яшьтәге кешеләрне, кем ничек кенә тырышмасын, барыбер үзгәртеп булмый. «Мәхәббәт» хисен кабызып, аларны ничек бар шулай яратырга кирәк. Бу очракта яратудан башка бернәрсә дә булышмаячак. Мәсәлән, этисез үскән хатын-кыз холкын берничек тә үзгәртеп булмый инде. Чөнки ата кеше кызына өч нәрсә өчен җаваплы: үзен аңлау һәм тану – бер, үзенең нинди булуын кабул итү – ике, саклау-яклау һәм тәэмин итү – өч. Әгәр этисез үсә икән, кеше үзен яклаучысыз хис итә, әйләнә-тирәдәгеләрне дошман итеп тоя. Моның ничек чагылыш алуын аңлыйсызмы? Шунлыктан, мәңге канәгатьсез булган моңа охшаш язмышлы әни-дәү әни-каенана-әбиләрне, бернигә дә карамый, бары тик яратырга гына кирәк.

БҮГЕН ҺӘМ ШУШЫНДА ЯШӘ

– Үзеңне дә яратырга кирәк. Коуч-блогерлар күзлегеннән түгел, психология күзлегеннән караганда үзеңне ярату ул дүрт төрле була. Беренчесе – «үземне үзем өчен яратам» (бары тик үзләре теләгән нәрсәне генә эшләүче эгоистлар). Икенчесе – «сине үзем өчен яратам» – эгоизмның тагын бер төре, моңа ачык мисаллар китерик: ана кеше үз омтылышларын бала аша гамәлгә ашырмакчы була, хатын ирен үзе теләгәнчә үзгәртә. Өченчесе – «сине синең өчен яратам» (үземә зыян китереп, башка кешене кайгыртам). Дүртенчесе, ягъни иң конструктив төр – «үземне синең өчен яратам». Безнең шәхесебез – рух, җан һәм тән берлеге ул. Әгәр без үзебезне кайгыртканда боларның өчесен дә колачласак, бербөтенгә әйләнәбез. Янәшәдәгеләр дә безнең яхшы якка үзгәрүне шунда ук сизеп ала. Бары тик уңышлы, тормыштан канәгать кешеләр генә башкаларга ярдәм итә ала.

Борынгыдан мәгълүм бер киңәш белән йомгаклыйм. Безгә бу кайчандыр тәгәлләнәчәк, һәм шул чакта..., дип көтеп яшәүдән туктарга кирәк. Тормыш – бүген һәм шушында ул.



ЗУР ПРЕМИЯ: МИЛЛИ КОЛОРИТ ҺӘМ ЖАНРЛАР ПОЛИФОНИЯСЕ

Луиза Янсуар

«Большая книга» Милли әдәби премиясе ел саен үзенең башта Зур исемлеге, ягъни лонг-листы белән, аннары инде Финалистлар исемлеге белән интригада тота. 2014 елдагы исемлекләрдә чын мәгънәсендә игътибарны җәлеп иткән, әсәрләре белән ләззәтләндереп өлгергән авторлар булды. Озакламый премияне тапшырыр өчен җыелырлар, ә без 19 нчы мәртәбә финалга чыккан әсәрләр арасыннан аеруча үзенчәлекләренә кыскача гына тукталып узыйк.

2024 елда премиягә Россиянең 73 шәһәреннән 346 авторның әсәре тәкъдим ителгән (Архангельскидан алып – Грозныйга, Калининградтан алып Петропавловск-Камчатскига кадәр). Быелгы премия географиясе дә киң вә иркен – 12 ил. Номинаторлар – 64 Россия нәшрияты, 19 төбәк язучылар берләшмәсе, 13 әдәби журнал. 62 язучы әсәрен, автор буларак, үзлегеннән тәкъдим иткән. Шуларның 22 се – кулъязмада.
Премия 2005 елдан рус телендә иҗат ителгән иң яхшы проза әсәренә бирелә. 2023 елгы лауреатлар – Евгений Водолазкин, Юрий Буйда, Алексей Сальников.

2024 елның озын исемлегендә бик тә кызыклы исемнәр бар иде. Безгә яхшы таныш авторлар да, яңарак кына күренә башлаганнар да, шулай ук – әле китап сөючеләргә моңарчы бөтенләй таныш түгелләр дә.

Барлыгы – 50 автор һәм аның әсәре. Алар – Россиянең 13 төбәгеннән һәм 7 илдән: Белоруссия, Израиль, Испания, Казахстан, Кыргызстан, Норвегия һәм Франция.

Финалистлар исемлегенә яки кыска исемлеккә килгәндә, узган елдагы кебек үк, ул озын килеп чыкты, бу оксюморон өчен безне кичерә күрегез, зинһар. Ике тенденция өстенлек итте – иң яхшыларын гына сайлап алыргамы, әллә хәзерге рус әдәбияты мәйданында эшли торган көчле авторларның киңрәк палитрасын күрсәтергәме безгә? Икенче тенденция җиңеп чыкты, мин моңа үзем бик тә шат: өметле күренгән яшьләрне, башлап язучыларны да, төшереп калдырып әрәм иткәнче, исемен яңгыратып калырга, киң массага күрсәтергә. Вакыт һәрберсен үз урынына куя ул.

Дмитрий Данилов, экспертлар советы рәисе

Быелгы сезонны әдәби даирәләрдә, «Диккенсча итеп әйтсәк, «Зур өметләр» дәвере» дип атыйлар. Инде азау ярган, исемнәре ничәмә дистә еллар буе китап киштәләреннән төшмәгән чын осталар, титуллы «ветераннар» белән беррәттән дебютантларның да көчле булуына басым ясый экспертлар.

Быелгы экспертлар советына Евгений Абдуллаев, Евгения Декина, Алексей Андреев, Афанасий Мамедов, Валерия Пустовая кебек язучылар һәм әдәби тәнкыйтьчеләр керә. Экспертлар советы рәисе – язучы Дмитрий Данилов.

Болардан тыш, быелгы озын исемлектә мондый кызыклы авторлар һәм әсәрләр дә бар иде: Сергей Авакян-Ржевский «Дорога Сурена», Иван Бевз «Чем мы занимались, пока вы учили нас жить», Даниэль Бергер «Кофе с перцем», Даша Благова «Течения», Максим Замшев «Вольнодумцы», Максим Гуреев «Андрей Битов: Мираж сюжета», Марина Завада, Юрий Куликов «Цвет и тени Беллы Ахмадуллиной», Павел Крусанов «Игры на свежем воздухе», Мария Лебедева «Там темно», Анна Лужбина «Юркие люди», Екатерина Манойло «Ветер уносит мёртвые листья», Анна

Фотолар: bigbook.ru, ast.ru, goodfon.ru сайтларыннан алынды

Маркина «Кукольня», Лев Наумов «Итальянские маршруты Андрея Тарковского», Олег Нехаев «Астафьев: Праведник из Овсянки», Сергей Носов «Фирс Фортинбрас», Виктор Пелевин «Путешествие в Элевсин», Хелена Побяржина «Другие ноты», Валерий Попов «Выдумщик», Антон Секисов «Комната Вагинова», Светлана Тюльбашева «Лес», Александра Шалашова «Камни поют», Юлия Яковлева «Поэты и джентльмены» һ.б.

Инде авторлар белән китапларга килик. Шәхсән минем үземнең фаворитларым арасында беренче позицияләрдә торучы – Надя Алексеева һәм аның дебют романы «Полунощница». Без аны алдагы саннарның берсендә киштәбездә тәкъдим дә иткән идек.

Бу юлы күбрәк милли колоритлы, Зур премиянең «рус телле агымына» төрле милләтләр менталитетын, туфрак-җирлеген, караш фокусын алып кергән язучыларга туктап узасы килә. Йә булмаса – тарихи-мәдәни барышка милли полифонияне дә күздә тотып, якын килгән авторларга. Һәм – жанрлар ярышына йөз тоучыларга.

2024 ЕЛГЫ ЗУР ПРЕМИЯ ФИНАЛИСТЛАРЫ

- Василий Аксёнов. «Флегонт, Февруса и другие» җыентыгы
- Надя Алексеева. «Полунощница» романы
- Владимир Березкин. «Уранотипия» романы
- Дарья Бобылёва. «Магазин работает до наступления тьмы»
- Яна Вагнер. «Тоннель» романы
- Алексей Варламов. «Одсун» романы
- Андрей Волос. «Облака перемен»
- Денис Драгунский. «Подлинная жизнь Дениса Кораблёва»
- Наталья Илишкина. «Улан Далай» романы
- Захар Прилепин. «Собаки и другие люди» хикәяләр җыентыгы
- Михаил Тарковский. «42-й до востребования» истәлекләр китабы
- Михаил Шемякин. «Моя жизнь: до изгнания» автобиография китабы
- Мршавко Штапич. «Устойчивое развитие» романы
- Глеб Шульпяков. «Батюшков не болен» биографиясе

1. АЛЕКСЕЙ ВАРЛАМОВ. «ОДСУН»



Алексей Варламов исеме әдәбият сөючеләргә яхшы таныш. Ул үзе бу романын «славянча» дип атый. Асылда, әсәрдә милләтләр һәм этник башлангычлар укмашып, бер-берсе белән керешеп беткән, төп ике линия бара – чех-немец белән рус-украин сызыклары.

Әсәрнең герое 2010 нчы еллар азагында Чехиягә әдәбият буенча лекцияләр укырга килә дә Судеттагы немецлар йортында үткәнгә сәяхәт итә. Судет вакыйгалары, әлеге йортның сере һәм фаҗигасе аны баштанаяк йолып ала, рефлексиягә бирелергә мәҗбүр итә. Икенче Бөтендөнья сугышы кайтавазы һәм илләр арасында хәзер барган конфликтлар, кан коеш, кыскасы, Зур сәясәт белән Зур тарихның ничек итеп «кечкенә кеше»не үз чоңгылына йолып алып бөтерүе, ә кайчак хәтта харап итүе дә турында бу роман.

Китапка орлыкның әле яшүсмер елларында ук салынуын да ассызыклый язучы – 80 нче еллар азагында «Артек» пионерлагеренда бер үсмер кыздан АЭС авариясе һәм үлем каплап киткән Припять шәһәре турында белеп, сүзсез калуын, тетрәнгәнен искә ала. Нәкъ менә шул кыз, еллар буена күңелендә йөреп, романның героинясы Катя прототибына әверелә дә.

Сүз уңаеннан, «Одсун» яңа гына «Ел китабы»нда «Ел прозасы» исеменә лаек булды.

> МИН ИЛЛӘР АРАСЫНДА НИ БУЛГАНЫ ТУРЫНДА ӘЙТЕРГӘ АЛЫНМЫЙМ, БАРЫ ИКЕ ТӨРЛЕ ПАСПОРТЛЫ КЕШЕНЕҢ ЯЗМЫШЫН, ТАРИХ ЗИЛЗИЛӘСЕНӘ ЭЛӘККӘН МӘХӘББӘТ ФАҖИГАСЕН ГЕНӘ ЯКТЫРТАМ.
>
> **Алексей Варламов**

2. НАТАЛЬЯ ИЛИШКИНА. «УЛАН ДАЛАЙ»

«ЖАҢҺР» КАЛМЫК ЭПОСЫНА ТАЯНЫП ӘСӘР ЯЗАРГА ҖЫЕНУЫМНЫ БЕЛГӘЧ, КАЛМЫКЛАРНЫҢ ТӨП ФОЛЬКЛОРЧЫСЫ ТАМАРА БАСАНГОВА МИНЕ КИРЕ УЙЛАРГА ӨНДИ БАШЛАДЫ. «БЕЗНЕҢ САКРАЛЬ ЭПОСНЫ ДӨРЕС ЧАГЫЛДЫРМАСАҢ, ҮЗЕҢӘ ДӘ, НӘСЕЛ-ЫРУЫҢА ДА ЗЫЯН КИЛЕРГӘ МӨМКИН», – ДИП КИСӘТЕП КУЙДЫ. БЕРЕНЧЕ УКУЧЫМ – ИРЕМНЕҢ ТУГАННАН ТУГАН АГАСЫ МӘРГӘН ИДЕ, УЛ – ТАРИХЧЫ, МУЗЫКАНТ, ЛАМА ҺӘМ КАЛМЫК. ӘСӘРДӘГЕ «ЭТНИК ДӨРЕСЛЕК»НЕ, ҺӘР АТНАДА ЯЗЫЛГАН ПОРЦИЯНЕ УКЫП, БЕРӘМТЕКЛӘП, ҖЕНТЕКЛӘП ТИКШЕРЕП БАРДЫ.

Наталья Илишкина

Наталья Илишкина белгечлеге буенча – филолог-германист. Һәм аны калмык далаларын айкап чыгарга этәргән бу роман – соңгы еллардагы Россия китап базарында чын мәгънәсендә көтелмәгән экзотика һәм вакыйга булды, дисәм дә, ялгышмам. Аны нәкъ шул экзотик яссылыкта, матур итеп төреп, укучыга тәкъдим иттеләр дә – «Дала сагасы» диеп.

«Улан Далай»ны язар өчен центнер ярымлап китап укуы һәм бик тырышып, бик озаклап тәвәккәлләве турында елмаеп сөйләргә ярата хәзер автор үзе. Әлбәттә, бу романга ул җиңел генә килмәгән. Инде язарга утыргач та янә бер кат уйлаган.

Илишкина безгә дүрт гасыр дәвамында Ак патшага иман китереп, намус белән хезмәт иткән Дон калмыклары турында бәян итә. Берничә буын гаилә тарихы, язмышы аша совет ситемасының күтәрелеш-түнтәрелешләрен дә күздән кичерәбез, хәрби иттарткыч эчендә дә «туралып» чыгабыз, депортация михнәтләрен дә кичәбез. Романның нигезендә – Идел белән Дон арасында, Сал елгасы үзәнлегендә гомер кичергән бузавлар тормыш-көнкүреше, архив документларына нигезләнгән реаль гаиләләр һәм кешеләр кайтавазы.

Бу – олы зилзилә уртасында үз тамырларына чатырдатып ябышып торган «кечкенә халык»ның әрнү авазын, күз яшен киң кешелек дөньясына чыгару да, нәни ком бөртегедәй, тарих чоңгылында югалып калган затларны табып алып, исемнәрен кайтарып, күргән-кичкәннәрен яд итү дә.

3. ДАНИЭЛЬ БЕРГЕР. «КОФЕ С ПЕРЦЕМ»

– ФАРУК, – ДИДЕ ТАНЕЛИ ПЫШЫЛДАП КЫНА. – СИН МИҢА СӨЙЛӘГӘН ХӘЛЛӘР БИК СӘЕР ҺӘМ ШАККАТКЫЧ. ҺӘМ БУ ЗАРЗАНД, ӘЙТҮЕҢӘ КАРАГАНДА, КАРТ МӘГЪРИБ СИХЕРЧЕСЕНӘ БИК ТӘ ОХШАП ТОРА. ГАДИ КЕШЕ ТҮГЕЛДЕР УЛ... АНЫ ОНЫТЫП, БАШКА ИНВЕСТОР ЭЗЛӘП КАРАМЫЙСЫҢМЫ СОҢ, Ә?

– СИН НӘРСӘ?! КЕМ ӘЛЕ ТАГЫН ШУНДЫЙ ШАРТЛАР ТӘКЪДИМ ИТӘЧӘК? БАШКА ИНВЕСТОР КАБАЛАГА КЕРТЕП, БӨТЕН СОКЛАРНЫ СУЫРЫП ЧЫГАРАЧАК. Ә АННАН, ЗАРЗАНД СИХЕРЧЕ БУЛСА, УЛ МИН ПЕШЕРГӘН КОФЕНЫ ЭЧӘ АЛЫР ИДЕМЕНИ?! МИН БИТ АНЫ ПЕШЕРЕП УЧАКТАН АЛГАНДА ҺӘРЧАК ДОГАМНЫ УКЫЙМ.

– ЧЫНЛАП ТА, ФАРУК. Ә БИТ ИБЛИС БЕЛӘН АНЫҢ БАЛАЛАРЫ ДОГАДАН КУРКЫП КАЧА...

ШУЛАЙ ИТЕП, ТАНЕЛИ ТЫНЫЧЛАНДЫ. БЕЗ ӘЛЕ КАРАҢГЫЛЫККА КАРАП, АНЫҢ НӘРСӘ КИТЕРӘЧӘГЕН АҢЛАРГА ТЕЛӘГӘНДӘЙ, ТАГЫН БЕРАЗ УТЫРДЫК ТА ЙОКЫГА ТАЛДЫК. Ә ТАҢ БЕЛӘН МИНЕМ ТОРМЫШЫМ БАШТАНАЯК ҮЗГӘРДЕ.

Нәшрият үзенең аннотациясендә бу китапны «канда дәрт уятырга сәләтле кайнар Көнчыгыш романы» дип тәкъдим итә. Асылда романны Кыргызстанда туып үскән, әлеге көндә дә шунда яшәүче яшь автор – Даниэль Бергер иҗат иткән һәм нәшриятка тапшырган. Бу яшь язучының иҗат юлы күпмедер дәрәҗәдә Дагыстан прозаигы, бүгенге көндә күпсанлы китап күргәзмәләре белән фестивальләре фавориты Ислам Ханипаевныкына охшаш: документаль һәм уен киносы төшерүче режиссёр, продюсер. Моңа кадәр «О нечисти и не только» китабы белән дебют ясаган иде, хәзер аның буенча сериал төшерелә, дигән хәбәрләр йөри.

Даниэль Бергерның беренче китабы турында шактый саллы һәм җитди фикерләр әйтелде, бу әсәренә дә игътибар шактый мулдан. Дөресен генә әйткәндә, ул инде үзенең бер роман авторы гына түгеллеген исбат итте.

Көнчыгыш экиятләре белән риваятьләрен виртуозларча катнаштырып, аны Төркиянең үткәндәге һәм хәзерге тарихи елъязмасы белән укмаштырып, чыннан да, «борычлы» әсәр тәкъдим итә ул укучысына. Романның төп каһарманы Фарук – талантлы шеф, ул озак еллар дәвамында күпсанлы укучыларга остаз булган кеше. Һәм менә көннәрдән бер көнне ярык тагарак алдында диярлек калган Фарук кечкенә генә кофейня ачарга карар кыла, аның бу башлангычына һәйбәт кенә инвестор табыла.



4. СВЕТЛАНА ТЮЛЬБАШЕВА. «ЛЕС»

> ЧЫНЛАП ТОРЫП НИ БУЛГАНЫ БАРЫ ТИК КИТАПНЫҢ СОҢГЫ БИТЛӘРЕНӘ ТАБА ГЫНА АЧЫКЛАНА БАШЛЫЙ. МИНЕМ НИ БЕЛӘН ТӘМАМЛАНАСЫНА ФАРАЗЫМ БЕРНИЧӘ ТӨРЛЕ ИДЕ: БЕРСЕ ДӘ ЧЫН БУЛЫП ЧЫКМАДЫ. ТЮЛЬБАШЕВА ИНТРИГАНЫ ИСКИТКЕЧ КОРГАН, ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ НОКТАДАН КАРЫЙ ТОРГАН ТӨЕНЛӘНЕШ ҺӘМ ЧИШЕЛЕШ ТАПКАН
>
> **Букмейттагы укучылар форумыннан**

Әлеге роман, басылып чыгуга, актив укыла һәм төрле фикерләр тудыра торган дебютка әверелде. Әлбәттә, саллы әдәби тәнкыйтьчеләрнең җылы мөнәсәбәте дә үз ролен үтәде. Галина Юзефович романны заман хоррорлары арасында соңгы еларда бик яхшы күзгә ташлана торган әсәр, дип атады.

Эш әле шунда да: хоррор өчен кызыклы урыннар итеп соңгы елларда торган саен ешрак Россия «глубинкасы» яисә милли, этник җирлекле урыннар алына. «Лес» бу җәһәттән шулай ук колоритлы, атмосфералы.

Ике дус кызның Карелиягә чыгып китүеннән башлана ул. Нишләп әле юк, ди, Мәскәүдә – чыдап булмаслык бөркүлек, чатнама эссе, нәкъ менә урман һавасын сулар һәм җанга ял табар чак, дип карар кыла алар. Һәм, әлбәттә инде, жанр таләпләре буенча, бу сәяхәт тоташ бер шомлы лабиринтка әверелә: озак та үтми, кызлар вакыт төшенчәсен бөтенләй оныта, ә күзләренә чынбарлыкта күренергә тиеш булмаган нәрсәләр күренә башлый. Һәм менә алар, сихерләнгән боҗраны үтеп чыгалар да, архаик дөньяга эләгәләр.

Боларга параллель рәвештә икенче тарих та бара – Карелиянең урман эчендәге авылына сәеррәк бер гаилә килеп урнаша: тугыз яшьләр тирәсендәге бер малай, этисе, апасы, агасы һәм әбисе. Авыл кешеләре нәрсәдер буласын шунда ук сизенеп ала.

Архаик һәм хтоник дөньяларга чакыру соңгы араларда язучыларда шактый популяр булса да, кызыклы фокус табу – һәркемгә дә бирелми. «Лес» әсәрендә ул – бар, саспенс белән бергә, үзенә йолып ала, киеренкелекне тота. Һәм бер тында укып чыкканыңны сизми дә каласың.

5. ДАРЬЯ БОБЫЛЁВА. «МАГАЗИН РАБОТАЕТ ДО НАСТУПЛЕНИЯ ТЬМЫ»

Соңгы елларда «Букмейт» китап сериалларын чыгару буенча рекорд куя, дияргә мөмкин. Хоррор жанрында үзенчәлекле романнары белән билгеле Дарья Бобылёваның «Магазин работает до наступления темноты» әсәрен дә шулай – атна саен яңа эпизодлап тәкъдим иттеләр. Алай гына да түгел, хәтта 2 сезонга бүлеп. Аудиоверсиясен Бобылёва үзе укыды, саундтрекны «Хадн дадн» төркеме язды.

Сюжет буенча, Мәскәүдәге бер гадәти ишегалдында антиквар кибет эшли. Гап-гади «лавочка» – шуннан артык бернәрсәсе дә юк. Әмма утыз яшьлек блогер Славик анда сәер хәлләр булуына шикләнә башлый. Чынлап та, алга таба без заманында бик теләп адашып йөргән Лукьяненко «Дозор»ларына кереп эләккәндәй булабыз: кемнең – кеше, ә кемнең юк икәнен тиз генә аеруы... шактый четерекле эш.

Дарья Бобылёва әйтүенчә, ул романны үзенең букинистик кибеттә эшләгән тәҗрибәсенә нигезләнеп язган. «Чын мәгънәсендә сюр үзәге иде ул», – дип искә ала хәзер әлеге дә баягы кибетне.

2 нче сезонда беренчесен буеннан-буена тоткан интрига чишелә: моның кайсы дөнья икәне дә беленә, аның ничек корылуына шәрех тә бирелә, кибеттәге «затлар»ның кемнәр булуын да абайлыйбыз. Мультигаләмнәрдәге кагыйдәләрне дә анык үзләштерәбез: биредә «кыйпылчыклар», ягъни «катламнар» арасыннан йөри белергә өйрәнергә, тиешле ишекләрне табып, алардан шуып узарга һәм бары тик ышанычлы чатларга гына чыгарга киңәш ителә.

Минем үземә кичекмәстән кино вариантын уйларга һәм тормышка ашырырга кирәк кебек тоела.

> БОБЫЛЁВА РОМАНЫ – 1920 НЧЕ ЕЛЛАРДАГЫ АМЕРИКА ЖАНРЫ PULP FICTION ТРАДИЦИЯЛӘРЕН БЕЗНЕҢ ҖИРЛЕКТӘ ЯҢАРТУ УЛ. СҮЗ УҢАЕННАН, НӘКЪ МЕНӘ ШУШЫ ЖАНРДАН ЗУР ӘДӘБИЯТКА ИРЕКЛЕ СӘЯХӘТКӘ ЗАМАНЫНДА ЛАВКРАФТ, БЛОХ, ГОВАРД, КАТТНЕР ЧЫГЫП КИТӘ.
>
> **Кирилл Ямщиков, әдәби тәнкыйтьче**

ШӘМӘК: КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ!

Фото: Лилиана Вәлитова

Шәмәк

Менә ул – Апас районының Шәмәк авылы. Халык сөйләве буенча, бу җирләргә нигез салган Шәмәк бабай бик елгыр, җитез булган. Эш шунда ки, Шәмәк авылының туфрагы уңдырышлы. Ул җирләргә күпләр кызыккан. Шуның өчен дә йөгерү ярышы уздырганнар. Ә Шәмәк бабай барысына караганда да тапкыррак булган: ярышка чыккач, арттарак калганга күрә, финишка җиткәндә башындагы бүреген алгарак аткан. Янәсе, ул инде килеп җиткән. Нәтиҗәдә, әлеге урынга төпләнергә рөхсәт алган.

Бу хәлләргә берничә йөз ел вакыт узган. Ә Шәмәк бабайның оныклары һаман да үткенлеген җуймаган.

Руфия Фазылова

МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ – АВЫЛ КҮРКЕ

Шәмәк кечкенә авыл: бүген биредә 95 кеше яши, 50 йорт бар. Беренче булып аның табигате әсир итә: авылны икегә бүлеп, зур булмаган елга ага. Тагын әле монда атаклы Шәмәк күле бар. Аның тирә-ягы төзекләндерелгән, үзе чистартылган. Патшалар заманында ук күлнең дәрәҗәсе зур булган. Авыл янында берничә чокыр бар. Аларга халык матур исемнәр кушкан: Урта чокыр, Атау чокыры һәм Кирәмәт чокыры. Бу тауларның серле бер көче турында хәтта риваятьләр дә йөргән. Узган гасыр башында Шәмәк – Тәтеш, ә соңрак Буа районына да кереп ала. 1964 елның 4 мартыннан ул Апас районы авыллары рәтенә керә.

Шәмәк күленең дәрәҗәсе зур булган.

Мәдәният учагы узган елның декабрендә ачылган.

Инде Шәмәкнең бүгенгесенә килик. Кызганыч, авылда белем йорты юк, 2012 елда башлангыч мәктәпнең ишегенә йозак эленә. Балалар бүген күрше Урта Балтай авылына йөреп укый. Социаль объектлардан клуб, ФАП, кибет бар. Соңгысы шактый вакыт ябылып та торган. Әмма аерым кешеләрнең тырышлыгы белән кибет янә ишекләрен ачкан. Шәмәктә шулай ук «Рамазан» мәчете бар, авылга кергәч тә, еректан ук балкып каршы ала ул. Аллаһ йорты 1994 елда сафка баскан.

Авыл клубына аерым тукталасы килә, чөнки шәмәклеләр өчен аның әһәмияте бик зур. Мәдәният учагы узган елның декабрендә ачылган. Аңа кадәр җирле халык иске, агач бинага йөреп күңел ачкан. Илле урынга исәпләнгән заманча клубны «Авыл клублары» республика программасы нигезендә эшләгәннәр. 150 квадрат метр мәйданлы бина үз эченә музей һәм китапханәне дә алган. Әле тагын өстәп янкорма салынып ята. Анысы фойе булачак икән.

Клубта иң гаҗәпләндергәне музей бүлмәсе булды. Монда борынгы экспонатларга караганда заманчалары күбрәк. Авылның оешу вакытлары, төрле гасырларда күпме кеше яшәгән – барысы да заманча такталарга зур итеп язып куелган. Балалар өчен җәнлекләр турында аерым почмак та бар. Тагын бик затлы экспозиция – электрон такта. Аңа бармак белән генә орынып, Шәмәк турында бөтен мөһим мәгълүматны белеп була. Авыл тарихын, атаклы кешеләре хакындагы мәгълүматны, хәтта өлкән кешеләр сөйләгән видеоистәлекләрне дә ишетергә мөмкин.

Клубта иң гаҗәпләндергәне музей бүлмәсе булды.



Затлы экспозиция – электрон такта.

– Әлеге музейны авылдашыбыз Марат Нуриев бүләк итеп ясатты, – диде Шәмәк клубы җитәкчесе Алинә Вафина. – Музей бүлмәбез чынлап та сокланырлык. Килгән кешеләр дә гаҗәпләнеп китә. Марат Гадбелхәевичкә бик зур рәхмәт, клубка янкорманы да үз акчасына эшләтә. Гомумән, Шәмәкне үстерүдә, аны төзек итүдә аның өлеше бик зур. Әле ярый ул бар, дип сөенәбез. Клуб каршында Җиңү бакчабыз бар, анда 450 төп алмагач үсә. Өр-яңа обелиск тора. Барысын да Марат Габделхәевич эшләтте.

Без Шәмәктә көнне клуб мөдире телгә алган Җиңү бакчасында зур чара булды: авылда яшәүче үрнәк гаиләләрне зурладылар. Башта аларга затлы бүләкләр тапшырылды. (Иганәчеләре әлеге дә баягы Марат Нуриев иде.) Аннан исә районның төрле авылларында яшәүче җырлы-моңлы гаиләләр чыгыш ясады.

– Туган авылда калганыгыз, Шәмәкне яшәрткәнегез, яшәткәнегез өчен бик зур рәхмәт сезгә, авылдашлар, – диде Россия Дәүләт Думасы депутаты, «Апас якташлар җәмгыяте» җитәкчесе Марат Нуриев. – Атна саен туган авылыма кайтам. Монда гына рәхәтләнеп ял итәм. Ничек тә йортлар санын киметмәскә инде. Ә иң зур теләгем – Шәмәгебездә сабыйлар күбрәк тусын иде.

ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН ТАБИБЫ

Чарада бүләкләнүче парларның берсе – Рәхмәтуллиннар. Бу зыялы гаилә беренче күрүдә үк игътибарны җәлеп итте. Ирле-хатынлы Айрат белән Эльмираның бергә яшәүләренә быел утыз ел тула икән. Ике кыз тәрбияләп үстергәннәр. Рәхмәтуллиннар безне өйләренә чакырды.

Гаилә башлыгы Айрат әфәнде 2019 елда Татарстанның атказанган табибы исеменә лаек булган. Бүгенге көндә ул күрше Урта Балтай табиблык амбулаториясен җитәкли. Заманында КДМУның стоматология факультетын тәмамлап, туган районына эшкә кайткан булган.

– Башта мин Апаста теш табибы булып та эшләдем, – диде Айрат Рәхмәтуллин. – Терапевтлар җитми дип, мине яңадан ГИДУВка укырга җибәрделәр. Янә ике ел шунда белем алдым. Шулай итеп, теш табибыннан терапевтка әйләндем. Медицина өлкәсендә утыз елдан артык эшлим. Төрле чаклар булгандыр, әмма һөнәремне бик яратам.

– Ә шәһәрдә калу теләге булмадымы? – дим авылның атказанган табибына.

– Андый мөмкинлек тә бар иде. Медицина институтында укыганда ук Казанның бер поликлиникасында эшләдем, кешеләргә тешләр куйдым. Без яшь чакта авыллар гөрләп тора иде бит. Урта Балтай колхозының ул чагындагы җитәкчесе Мәхмүт Сәләхов яшьләрне авылда калдыру өчен бик тырышты. Хәтта мәктәп тәмамлагач, кулга аттестат та бирдермәде, малайлар тракторда бер ел эшләде, кызлар сыер сау-

Җиңү бакчасында зур чара булды: авылда яшәүче үрнәк гаиләләрне зурладылар.

Рәхмәтуллиннар – авылның зыялы гаиләсе.

ды. Дөрес, теләге булганнар барыбер шәһәргә китеп төпләнде. Ә без менә калдык. Гаиләдә өч бала үстек – ике кыз, бер малай. Кызлар төп нигездә калмый инде, аңлашыла. Шуның өчен дә эти-әни янына мин кайттым. Эльмира да каршы килмәде, төп йортка килен булып килде. Әни белән бик матур яшәделәр. Кызганыч, әниебез мәрхүм инде. Ә менә этиебез, Аллага шөкер, сафта. Акылы да әйбәт, сәламәтлеге дә зарланырлык түгел.

Чынлап та, Әсгать ага Рәхмәтуллин һаман да егәрлеген югалтмаган. Алла боерса, үзенә 90 яшь тула икән. Гомер буе колхозда хезмәт куйган: механизатордан башлап, бригадирга кадәр җиткән. Әсгать абый авыл турында шактый истәлекләре белән уртаклашты:

– Безнең авыл халкы нигездә игенчелек белән шөгыльләнгән. Беренче колхоз 1930 нчы елда оешкан, башта «1 Май» исемен йөрткән. XX гасыр башында Шәмәктә 270 йорт булган. 1908 елда 1212 кеше яшәгәнлеге мәгълүм. 1921 елгы ачлыкта халык күпләп кырылган. Аннан тагын олы фаҗига – Бөек Ватан сугышы. Сугышка кадәр Шәмәктә 743 кеше яшәгән, 1949 елда 592 кеше калган.

Әсгать абый 1935 елда туган бала. Әтисенең сугышка киткән көнен дә, өйдәге бердәнбер сыерга печән чабуларын да бик яхшы хәтерли ул. Аннан бигрәк, күңелендә куркыныч төш кебек тагын бер истәлек саклана.

1942 ел... Авылда ир-атлар юк дәрәҗәсендә. Күрше-тирә авыл мәчетләренең манаралары күптән киселгән. Ә Шәмәкнеке тора. Кача-поса бабайлар анда кереп намаз укып чыга. Менә бер көнне Иске Йомралы авылыннан берничә ир-ат килә. Күз ачып йомганчы мәчет манарасын кисеп тә төшерәләр. Ак яулыклы әбиләр, үз эченнән генә елый-елый, дога кыла: «Кичер, Раббыбыз, мәчетне саклап кала алмадык...» Күзләренә ак-кара күренмәгән теге ир-атлар, тиз арада ике катлы агач мәчет бинасын сүтеп, трактор арбасына төяп, район үзәге Апаска алып китәләр. Ялгыз хатын-кызлар, нарасый балаларын кочаклап, канлы яшь түгеп кала...

АВЫЛ ЯШӘРТӘ

Шәмәктә сөйкемле, җор телле бабайлар да, әбиләр дә яши булып чыкты. Шуларның берсе – Хатирә апа Шаһивәлиева. 82 яшен тутырган, ялгызы яши ул. Җәмәгате күптән мәрхүм булган. Бер улын да җирләргә туры килгән. Бөтен таянычы – Казанда яшәүче кызы һәм Мәскәүдәге улы.

– Кызым атна саен кайта, – диде Хатирә апа. – Оныкларым да бик акыллы, дәү әни дип кенә торалар. Төркиядә яшәүче кызымның кызы минем рецептларны җыеп китап чыгарды. Ул чакта өйгә бер төркем кешеләр кайтты. Баскан токмачлы аш, кыстыбый, юка – ни генә пешермәдем. Барысын да фото, видеога төшереп бардылар. Арып беттем. Тик балалар хакы дип, бер дә сер бирмәдем. Китапны өч телдә – татарча, инглизчә, русча чыгардылар. Бик матур,

– Төркиядә яшәүче кызымның кызы минем рецептларны җыеп китап чыгарды, – ди Хатирә апа.

зәвыклы итеп бастырганнар, менә сез дә карагыз әле...

Чынлап та, «Хатирә апа рецептлары» китабы затлы килеп чыккан. Сыйфатлы кәгазьдә, төсле фотолар белән. Менә ул дәү әнине ярату ничек була!

Хатирә апа профессиональ пешекче түгел. Ләкин гомер буе аш-суга оста булган. Башта ул колхозда эшләгән. Ә аннан соң 39 ел (!) Шәмәктә почта таратткан.

– Башта мин колхоз почтальоны булдым, ягъни хезмәт хакын колхоз түләде, – дип дәвам итте әңгәмәдәшем. – 1,25 хезмәт көне исәбеннән түләделәр. Заманына күрә начар акча түгел иде. Дөрес, аның эше дә авыр булды. Атнасына бер көн ял итәсең, көн дә почта таратырга кирәк. Ул чагында халык күп итеп газета-журнал алдыра, өстәвенә никадәр хат килә. Кайбер көннәрне сумканы кузгатып та булмый! Көн саен Урта Балтай белән Шәмәк арасын (ә бу дүрт чакрым дигән сүз!) җәяү барырга-кайтырга кирәк. Лаеклы ялга чыкканчы шулай эшләдем. Бүгенге тормышыма шөкер итәм, барысы да бар. Исәнлек кенә булсын.

Шәмәктә шуңа игътибар иттем: кешеләре матур, сөйкемле сөякләре бар. Люция апа Габдрахманованы да Җиңү бакчасында узган концертта күреп алдым. Безнең татар ханымнарына хас пөхтәлек, ыспайлык бар үзендә. «Кәҗәләр дә асрыйбыз, кунакка килегез», – диде ул.

Аның янына да бардык, әлбәттә. Люция апа гомере буе Мәскәүдә яшәгән икән. 2021 елда җәмәгате Руслан белән туган нигезенә кайтып төпләнгән. Кәҗә, сарык, күп итеп кош-корт тоталар. Бакчалары да зур гына.

– Ковид башлангач, авырудан куркып, авылга кайтып яшәргә булдык, – диде Люция апа. – Инде шуннан китәсе килмәде. Хәзер балалар янына Мәскәүгә барып кына кайтабыз. Ничек ул калада гомер буе яшәлгән икән, дим. Авылда шундый рәхәт, тыныч, иркен. Киңәшем шул: картайгач булса да, кеше туган авылына кайтып яшәсен.

Люция апа да, Руслан абый да – намазда. Зурлап Мәүлид кичәсе уздырырга җыеналар иде. Авылга күченгәч, табигый ризык кына ашарга өйрәнгәннәр. Хәтта индоуткаларны да үзләре бастырып чыгарган.

– Кош ите сәламәтлек өчен файдалы, ә кәҗә сөте аннан да яхшырак, – дип, Руслан абый ихаталарын күрсәтеп йөрде. – Чын ит, сөт, күкәй ашап, сәламәтлек яхшырып китте. Егетләр кебек йөгереп йөрим. Люция дә, әнә, кызлар кебек!

Люция Габдрахманова җәмәгате Руслан белән туган нигезенә кайтып төпләнгән.

– Элеккеге колхозның тракторлар паркын тулысынча яңадан ясадык. Хәтта советлар чорындагы кебек лозунглар да язып элдек, – ди җитәкче.

– Бик тиздән он тарттыру тегермәне дә эшли башлаячак, – диде Алмаз Нуриев.

«ЭШ ҖИТӘРЛЕК...»

Авылларга баргач та беренче сорау: эш урыннары бармы? Баксаң, узган ел биредә «Шәмәк» КФХ хуҗалыгы оешкан. Бүген авылның алты-җиде ир-аты шунда эшли. Әлеге крестьян-фермерлык хуҗалыгы иген, башка культуралар үстерү белән шөгыльләнә. Алга таба нәселле үгезләр үрчетү нияте дә бар икән.

– Бүген 1800 гектар җиребез бар, – диде «Шәмәк» хуҗалыгы җитәкчесе Алмаз Нуриев. – Бөтен төр техниканы да сатып алдык, барысы да заманча. Шәмәк кешеләре тулысынча пай җирләрен безгә биреп бетерде. Хәзер менә күрше авыллар белән эшлибез. Ләкин яшермим, зур агрохолдинг чәчүлек җирләрен бирергә ашыкмый. Югыйсә, без закон нигезендә эшлибез. Уңышларыбыз да начар түгел, быел гектарыннан 40 центнер иген алдык.

Фермерлык хуҗалыгының ихаталарын карап чыктык: кем әйтмешли, шаккатыра. Заманча иген киптерү, чистарту цехы гына ни тора! Барысы да автоматлашкан. Йөк машинасы кырдан игенне алып кайтып сала да эш бетте: коры, чиста иген икенче торбалардан килеп чыга.

– Бик тиздән он тарттыру тегермәне дә эшли башлаячак, – диде Алмаз Нуриев. – Игенне ашламасыз гына үстерергә ниятлибез, ягъни ул экологик яктан чиста продукт булачак.

– Ашламасыз гына игеннең уңышы түбән була, диләр, ә бу фермерлар өчен икътисади яктан отышсыз чыга, – дим яшь фермерга.

– Әйе, килешәм. Ләкин бүген халык сыйфатлы ризыкка өстенлек бирә. Югары сыйфатлы Шәмәк онына сорау зур булырга тиеш. Хәер, вакыт күрсәтер.

Алмаз Казанда туып үскән егет. Казан дәүләт архитектура төзелеш институтын тәмамлаган. Шул юнәлештә эшләгән дә. Һич уйламаганда, авыл хуҗалыгы тармагына кереп киткән.

– Әлбәттә, эшне эти белән бергә башладык, – дип дәвам итте ул. – Фермерлык эше турында күптән сөйләшеп йөри идек. Шәһәрдә яшәсәк тә, гаилә белән атна саен авылга кайтып йөрдек. Энем Айдар да, үзем дә авыл эшен яхшы беләбез. Безнең бабай да колхозда механизатор, бригадир булган. Ул эшләгән элеккеге колхозның трактор паркын тулысынча яңадан ясадык. Хәтта советлар чорындагы кебек лозунглар да язып элдек.

– Техникага кеше җитәме? – дим.

– Әйе, Шәмәк ир-атлары эшли. Бер техникадан төшәләр, икенчесенә утыралар. Хезмәт хаклары начар түгел, сезон вакытында 100 мең сумнан артык алалар. Ә кышын 25 мең сум хезмәт хакы түләп барабыз.

Алмаз Нуриев әлегә Казан белән авыл арасын таптый. Киләчәктә гаиләсе белән кайтырга, төпләнергә дә нияте бар.

– Шәмәктә мәктәп тә юк, балаларыгыз кайда укыр? – дим, һаман да бик ышанмыйча.

Шәмәктә яңа ясалган асылмалы күпер.

– Район үзәге Апаска – егерме чакрым. Казанда да балаларны йөртеп укыталар бит. Аның бер авырлыгын күрмим.

Әлбәттә, яшь фермерның болай уйлавы бүгенге көн өчен гайре бер хәл кебегрәк. Авыл балалары барысы да диярлек шәһәргә киткән заманда шәһәрдән авыга кайту – чыннан да гаҗәп. Бирсен Ходай. Мондый егетләр безгә бик кирәк!

«Шәмәк» хуҗалыгында эшләүче Радик Галләмов исә туган авылында калган сирәк яшьләрнең берсе. Җәмәгате Гөлүсә белән өч бала тәрбиялиләр: бер кыз, ике малай. Ә гаиләдә иң өлкән кеше – Нәҗия апа. Радик кебекләр турында алтын куллы, диләр. Төрле техника төзәтә (махсуслашкан гаражы бар), тимердән капка-коймалар да ясый. Әйтәм бит, алтын куллы. Иң кызыгы – унбер класс белеме бар. (Машина, трактор йөртү таныклыгына укыган, әлбәттә). Барысына да үзлегеннән өйрәнгән.

– Техника белән кызыксынуым кечкенәдән килә, – диде Радик. – Авыл баласы бар эшне белеп үсә, үзем дә кызыксынучан идем. Ә укырга мөмкинлек тә, теләк тә булмагандыр. Аңа карап, кешедән ким яшәмибез. (Көлә.)

...Шәмәктән күтәренке кәеф белән кайттык. Ни өчен дигәндә, кешеләре ачык. Соңгы берничә елда гына да җиде йорт салынган. Тагын шуңа игътибар иттек: кая гына сугылма, Марат Габделхәевич булышты, диләр. Таяныр кешесе булган авыллар бәхетле шул. (Буа районы Тинчәле авылы, Чүпрәле районы Кече Чынлы авылына баргач та, шундый уйлар белән кайткан идек.) Бер генә теләк – Шәмәк алга таба да шулай көяләнсен, үссен.

Радик Галләмов – туган авылында калган сирәк яшьләрнең берсе.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Шәмәк – бик борынгы авыл. Тарихи чыганакларга караганда, 900 еллар элек чамасы оешкан булырга тиеш. Авыл тарихына багышлап китап та дөнья күрде. Анда да шулай дип әйтелә. Буләр ханның җиденче буын оныгы Шәмәк булган. Нәкъ менә ул бу җирләргә беренче булып нигез салган дип карала. 1095 елда туган булырга тиеш. Монда кырык-кырык биш яшьләрендә килгән, имеш. Димәк, безнең авылга, ким дигәндә, 860 ел килеп чыга.

Тарих бит ул шундый әйбер: төгәл елларны әйтү кыен. Бәлки егерме яшендә үк килеп төпләнгәндер. Ничек кенә булмасын, Шәмәгебез – чал тарихлы авыл.

Әсгать Рәхмәтуллин, Шәмәк авылы аксакалы.

ОРКЕСТР СОЛИСТЛАРЫ ҺӘМ АНСАМБЛЬЛӘРЕ ПАРАДЫ (12+)

Парадта яхшы музыкадан һәм оста башкаручылардан ләззәт алырга мөмкинме? Әлбәттә! Бигрәк тә бу Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының XXXI сезоны ачылу уңаеннан үткәрелә торган «Оркестр солистлары һәм ансамбльләре парады» да булса. Сез монда Джордж Гершвинның атаклы «Блюз стилендәге рапсодиясен», шулай ук чит ил һәм үз классикларыбызның башка җәүһәрләрен тыңлап ләззәтләнерсез. Программага тагын хәзерге заман композиторларының оригиналь әсәрләре, халык җыр-биюләренең эшкәртмәләре, чит ил һәм үзебезнең эстрада да кертелгән. Парадта катнашучылар арасында баянчылар ансамбле, «Лепта» ансамбле, кечкенә думбралар унисоны, тынлы һәм бәрмә уен кораллары ансамбльләре, прима балалайкалар унисоны, бас думбралары ансамбле дә бар... Махсус кунак – Мәскәү дәүләт академия филармониясе солисты, Бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты Николай Кузнецов (фортепиано).

26 сентябрь, 18:30 сәг.
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе. Казан, Павлюхин ур., 73



ЮГАРЫ ИЛЛЮЗИЯ СӘНГАТЕ (6+)

Дәүләт Эрмитажы тупланмасындагы 250 дән артыграк предмет (рәсем сәнгате, графика, скульптура, бизәнү әйберләре, фарфор, тукымалар, җиһазлар) рәссам яки һөнәрченең осталыгы белән генә түгел, аның... иллюзия тудыра белү сәләте белән дә таң калдыра. Сүз сәнгатьтәге «алдавычлар» хакында бара – сынлы сәнгать чаралары ярдәмендә иҗат ителгән предметлар чын натура эффекты тудырырга сәләтле булып чыга. Гаҗәеп эффект бу: яссы әйберләр – күләмле, якыны ерак булып тоела... «Үз күзеңә ышанма» күргәзмәсендә «алдавычлар»ның төрле төрләре белән танышырга мөмкин. Мәсәлән, тромплёй – күләм иллюзиясен тудыра торган әсәрләр. Яисә материаллар имитациясе – агач, таш, металлга охшаган үзләре, әмма чынлыкта алар түгел. Яки предметлар имитациясе – башка предмет формасын ала торган объектлар. Күргәзмә ялган һәм чын объектларны чагыштыруга нигезләнә. Тамашачы, кызыклы сценарийга эләгеп, алдавыч предметларны тану буенча мавыктыргыч уенга җәлеп ителә. Теләсә кайсы пьесадагы кебек үк, сюжетның билгеле бер үсеше күздә тотыла: тамашачы объектны күрә, аны чын дип кабул итә, аннары үзен алдауларын аңлый һәм кызыксынуы тагын да арта.

Көн саен 10:00 сәгатьтән 18:00 гә кадәр.
Җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр
Дүшәмбе – ял көне. «Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, kamalteatr.ru, tatfil.ru

КАРТЛЫКТА ДА, ШАТЛЫКТА ДА (16+)

«Ай, былбылым!» – шәһәр картлар йортында яшәүчеләрнең моңсу да, көлкеле дә тормышын тасвирлый торган комедия. Спектакль геройлары гомер көзендә төрле сәбәпләр аркасында картлар йортына эләгә. Әмма алар үзләренең биредәге тормышын һич кенә дә гомернең «соңгы тукталышы» дип кабул итми. Күнегелгән гадәти тормыш белән яшәүләрен дәвам итәләр. Хәтта Гөлҗәннәт белән Фикус кавышырга да ниятлиләр. Тик кара күзлекле Рәхимҗан пәйда булгач кына, вакыйгалар башка төс ала.

26 сентябрь, 18:30 сәг.; 10 октябрь, 18:30 сәг.
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма
һәм комедия театры. Казан, Горький ур., 13

ИМПЕРАТОР ФАТИРЛЫ ЙОРТ (0+)

Казан Кирмәнендәге губернатор йортын ни өчен элеккеге хан сарае урынында ук салганнар? Аның төзүчесе кем? Хакимлек итүче Романовлар династиясе резиденцияләреннән берсе саналган император фатиры нинди булган? Бу һәм башка сорауларга җавапны «Император яшәгән фатир булган йорт» күргәзмәсендә табарга мөмкин. Биредә губернатор сараендагы борынгы җиһазларга хозурланырга, археология раритетларын һәм хәтта XVI гасыр тәңкәләре хәзинәсен күрергә була. Экспозициянең бер өлеше Казан ханлыгы чорындагы хан сараена һәм XVI–XVII гасырлардагы патша даирәсенә багышланган. Хәзер исә губернатор сараенда Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясе урнашкан.

Көн саен 10:00 сәгатьтән 18:00 гә кадәр.
Җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр
Дүшәмбе – ял көне. Татарстан Республикасы
һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

БЕР ГАСЫРГА СОҢАРГАН КҮРГӘЗМӘ (6+)

Кызык: моннан йөз ел элек әзерләнгән күргәзмә хәзер генә дөнья күргән. Мәскәү, Петербург, Казандагы авангард һәм реалистик рәсем сәнгате осталарының өч йөзләп эше хакында сүз бара. Авторларның исемнәре генә дә ни тора! Николай Фешин, Василий Кандинский, Александр Родченко, Варвара Степанова, Ольга Розанова... Өченче кучмә сәнгать күргәзмәсе өчен сайлап алынган картиналар, графика һәм сыннарны 1921 елда Вятка губернасы шәһәрләрендә күрсәтергә карар кылына. Экспонатлар арбаларда күчерелә, Яранскига гына килеп җитә алалар, аннары юлсызлык һәм акча булмау сәбәпле туктап калалар. Картиналар турында искә төшерүче дә булмый, һәм XX гасыр азагына кадәр алар Вятка губернасы музейларының запасникларында саклана... Бүгенге экспозициядә совет чоры сәнгатенең башлангыч чорын тәшкил иткән күренекле шәхесләрнең Вятка сәнгать музее, Яранск төбәкне өйрәнү музее, Слободской төбәкне өйрәнү музее, шулай ук Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм хосусый тупланмаларда сакланган ике йөздән артыграк әсәре күрсәтелә.

Көн саен 10:00 сәгатьтән 18:00 гә кадәр.
Җомга – 11:00 дән 20:00 гә кадәр
Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр заллары
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

КАМАЛ ТЕАТРЫ. МӘСКӘҮ ГАСТРОЛЬЛӘРЕ (16+)

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры илебез башкаласында тамашачылар хозурына үзенең иң яхшы алты спектаклен тәкъдим итә. Казан труппасы Кече театрның тарихи сәхнәсендә – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр», «Бию пәрие», «Санаулы кичләр», «Зәңгәр шәл», ә Зур Ордынкадагы сәхнәсендә «Күзгә кайтаваз» һәм «Ситса туй» спектакльләрен күрсәтә.

10-15 сентябрь
Кече театрның тарихи сәхнәсе Мәскәү,
Театр тыкрыгы, 1 нче йорт
Зур Ордынкадагы сәхнә
Мәскәү, Зур Ордынка ур., 69 нчы йорт

Ай кәефе: Бәйгә

ИҢ ЯХШЫ ФОЛЬКЛОР АНСАМБЛЬЛӘРЕ КАЗАНДА КУНАКТА

«Татарстан» 103 еллык гомере эчендә нинди генә бәйгеләр уздырмаган. Әмма монысы, һич арттырусыз, күңел җылысы бөркелеп торган ямьле бәйрәмнәрнең берсе булгандыр, мөгаен!

...Әэш болайрак башланды. Республикабыз шәһәрләре вә авыллары буйлап сәяхәт иткәндә, кайда гына барып төшсәк тә, безне фольклор ансамбле каршы ала иде. Әйтерсең, нәкъ менә шушы ансамбльләр төбәкнең җаны! Алар бар бәйрәмнәрне, өмәләрне, юбилейларны «тотып» тора – авылдашларын да, кунакларны да үзләреннән таралган нур белән өретеп җибәрә, диярсең. Гадәттә, андый коллективларны мәдәният йортларында авылның актив апалары оештыра. «Ә тагын нишләргә пенсиядә?!» – дип чатнатып җавап бирә алар һәм җырлы-биюле җыеннарны җанландыруны үз кулларына ала. Шул рәвешле халык фольклор коллективлары пәйда була да инде – рус, татар, удмурт, чуваш, мордва, керәшен, мари һ.б. Татарстаныбызда 115 тән артык милләт вәкиле яши, ә аларның барысының да – үз традицияләре, җырлары, биюләре, йолалары һәм, әлбәттә, оештыру сәләте ташып торган үз апа-абыйлары, әби-бабайлары.

Шуңа без бәйге оештырырга булдык: «Татарстан» журналы социаль челтәрләренә язылучылар 2 ай рәттән республикабызның халык коллективларын карадылар һәм тыңладылар. Шуннан соң инде protatarstan.ru сайтында тавыш бирүне оештырдык.

Бәйгедә Татарстанның 30 дан артык фоль - клор коллективы катнашты. Иң күп тавыш җыйган 5 җиңүче коллектив 6 сентябрьдә Казанга гаҗәеп матур костюмнарын киеп килеп төштеләр һәм «Татмедиа» бинасы каршындагы скверда чын тамаша ясадылар! Концертны карарга тирә-юньнән халык җыелды.

Безнең өчен җырладылар һәм биеделәр:

– **Сарман районыннан «Чишмә» фольклор ансамбле коллективы** – «Иң яхшы татар фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче;

– **Чистай шәһәренең Рус җыры театры халык коллективы** – «Иң яхшы рус фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче;

– **Кайбыч районыннан «Тәңкәләр» фольклор ансамбле коллективы** – «Иң яхшы керәшен фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче;

– **Чирмешән районыннан «Лемзёр» фольклор ансамбле коллективы** – «Иң яхшы мордва фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче;

– **Кама Тамагыннан «Сандугач» фольклор ансамбле коллективы** – «Иң иҗади фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче. Т

Фото: Александр Ефремов

ДИПЛОМ
СЫРА

Любовь Смирнова, Чистай шәһәренең Рус җыры театры халык коллективы:

– Бәйрәм өчен зур рәхмәт! Искиткеч кәеф һәм хис-кичерешләр өчен – бигрәк тә! Бөтен нәрсә шундый уйлап оештырылган! Безне колач җәеп, туганнардай якын күреп кабул иттегез. Журнал редакциясе, аның баш мөхәррире Татьяна Вафина белән берлектә (сүз уңаеннан – нәселләре Чистай җирлегеннән булып чыкты, болар – атаклы сәүдәгәр Челышовлар!) безне бик яхшы итеп сәламләде, бүләкләр өләште. Без дә, үз чиратыбызда, олы рәхмәтләребезне белдерәбез – ансамбль һәм һәрберебез исеменнән дә! Бу матур бәйрәмне алып баручы Руфия Фазыловага аерым рәхмәтләребез – шулкадәр куандырдыгыз һәм ямьләдегез бәйрәмне! «Татмедиа» бинасы каршында көне буе Шатлык, Игелеклелек һәм Халык җыры тантана итте!

Илүзә Фәррахова, Сарман районы «Чишмә» ансамбле:

– Без бәйрәмнән онытылмас тәэсирләр белән кайттык. Бар да шундый югары дәрәҗәдә оештырылган иде! Әле хәзер дә, искә ала-ала, шул бәйрәмне сөйләшәбез, кичерешләр – җитәрлек. Киләсе бәйгегә кадәр хәтта! Бик зур рәхмәт сезгә!

Мәйсәрә Гомәрова, Кама Тамагы районы «Сандугач» ансамбле:

– Казанга барырга җыенганыбызны белгәч безгә: «Кая барасыз тагын?! Бәрәңге ала торган чак! Ә сез бәйрәм итеп йөрисез...» – диючеләр дә булды. Шуңа да карамастан, Казанга җыенып чыгып киттек. Һәм, беләсезме, баруыбызга шатланып туя алмыйбыз! Рәхәтләнеп җырлап-биеп, ял итеп кайттык! Ярый әле җибәрәсе килмәүчеләрне тыңламаганбыз... Сала кешесе калага болай да тиктән генә җыенып чыгып китми, болай ансамбль кадәр ансамбль белән – бигрәк тә! «Татарстан» журналы редакциясенә чын күңелдән рәхмәт белдерәбез!

Марина Рабина, Чирмешән районы «Лемзёр» ансамбле:

– Көтмәгәндә-уйламаганда безгә «Татарстан»ның иң шәп фольклор ансамбле» бәйгесендә катнашу насыйп булды. Бик куандык моңа! Сүз белән генә әйтеп бетерә торган түгел... Шулкадәр күп яхшы эмоцияләр алдык! Сез, оештыручылар, чын молодецлар!

Инна Драндрова, Кайбыч районы «Тәңкәләр» ансамбле:

– Инде өйгә кайтып барганда, барыбыз да бертавыштан: «Нинди гаҗәеп бәйрәмдә булдык без! Ә нинди бүләкләр бирделәр! Ничек сыйладылар!» – диештек. Чынлап та, бар да искиткеч булды – бөтен редакция коллективына, хезмәткәрләргә зур рәхмәтебезне белдерәбез, иҗади уңышлар, сәламәтлек телибез!

Тәтеш районының Олы Әтрәч авылында яшәүче оста гармунчы Васил Юнысов – «Татарстан» журналының күптәнге дусты. Аңардан башка авыл-районнарында бер генә бәйрәм дә узмый. Казанда да булмый ансыз хәтта! Бәйгедә җиңүчеләр, Васил абый тирәсенә җыелышып, кичкә кадәр җырлады-биеде – урамда да, редакциядә дә, лифт янында да, баскычларда да. Кыскасы, «Татмедиа» бинасы ул көнне җырмоңнан гөрләп торды!

Бөтен җиңүчеләр дә «Азбука сыра» ЖЧҖ һәм Tatarscarf тан үзенчәлекле күркәм бүләкләр алды.

Ансамбльләргә илһам өстәргә Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова да килде.

«Риваять» этник ансамбле.

Эстрада җырчысы Илсур Шәйдуллин.

«Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков бәйгедә катнашучыларны җиңүе белән дә, Татарстанның төп журналына элэгүләре белән дә котлады.

Эстрада җырчысы Лилия Сафина.

Сарман районыннан «Чишмә» фольклор ансамбле коллективы – «Иң яхшы татар фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче

Чистай шәһәренең Рус җыры театры халык коллективы – «Иң яхшы рус фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче.

Кайбыч районыннан «Тәңкәләр» фольклор ансамбле коллективы – «Иң яхшы керәшен фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче.

Чирмешән районыннан «Лемзёр» фольклор ансамбле коллективы – «Иң яхшы мордва фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче.

Кама Тамагыннан «Сандугач» фольклор ансамбле коллективы – «Иң иҗади фольклор ансамбле» номинациясендә җиңүче.